

Фәнис
Яруллин

# КҮҢЕЛ ЯКТЫСЫ



ШИГЫРЬЛӘР, ПОЭМА

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Я 74

**Яруллин Фәнис**

Я 74 Күңел яктысы. Шигырьләр, поэма.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 384 б.

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фәнис Яруллинның бу китабына, нигездә, лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды. Аларда үткән көннәрнең сулышы бүгенге вакыйгалар кайнарлыгы белән кушылып, тормышыбызның асылы үзенчәлекле образлар аша чагыла.

ISBN 5-298-01224-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2003

# *Син*

*Син – мәңгелек учак,*
*Син – мәңгелек чәчкә;*
*Әй Мәхәббәт, әйтче,*
*Син соң ничә яшьтә?*

* * *

Бу дөньяның бар кызыгы —
Кызлар икән.
Кызлар бетте — кызык бетте.
Күзләр җиткән.
Ә күзләрнең керфегендә
Бозлар икән,
Йөрәк инде гомер буе
Сызлар микән?!

* * *

Кар йомарлап аттым
Бер кызга:
Әверелде кызым
Йолдызга.

Хәзер инде аткан
Карларым
Үтә алмый күкләр
Катламын.

Үз башыма алар
Коела.
Ә йолдызым нурда
Коена.

*1999*

## *Бүләк итә алам*

Ялына алмыйм, Табигатем горур —
Тугангамы таулы якларда.
Бара алмыйм — ара артык ерак,
Арып егылыр акбүз атлар да!

Араларда яткан җәйләр, кышлар
Тау-тау булып юлга өелгән.
Минем хисләр мәгърур
шул тауларның
Өсләренә учлап сибелгән.

Таш өстендә үскән алсу чәчәк —
Йөрәгемнән тамган тамчы ул.
Җаның кушса, ал син аны өзеп —
Мәхәббәтнең гүзәл таҗы ул.

Ялына алмыйм, табына да алмыйм,
Мин бит инде хәзер мең яшьтә.
Бүләк итә алам сиңа бары
Таш өстендә үскән бер чәчкә.

*1999*

## *Кояшка җитми кулым*

Шикәрләр булып эреден,
Күңел күлемә төшеп.
Йә, әйт инде: судан балны
Аерып алыйм ничек?

Кушылдың, яңа төс булып,
Җанымның балкышына.
Ул балкышта буталышкан
Шатлык та, сагышым да.

Сүз белән көй кушылгандай
Иң борынгы җырларда,
Хисләр бетте чәбәләнеп —
Булмый сүтеп урарга...

Күзләремнең карасына
Яктылык булып тулдың.
Ул яктылыкны капларга,
Кояшка җитми кулым.

*1999*

* * *

Күзнең бер күңелсез көнендә,
Болытлар йөзгәндә күгемдә,
Җаннарга бәргәндә салкын җил,
Вазада үлгәндә соңгы гөл —

Кинәттән һәммәсе үзгәрде,
Якты нур балкытты йөзләрне,
Ачылды күкләрнең капкасы,
Күренде җәннәтләр бакчасы.

Үрелдем тыелган алмага,
Яфрагын яптым мин ярага.
Җимешен телемдә эреттем,
Уйларым болытка селектем.

Актылар-киттеләр уйларым,
Эчтем мин саф кәүсәр суларын.
Дымы да кипмәде иреннең,
Мин инде сусап та өлгердем.

*1999*

## *Үзенә йотып иң зур хәбәрен...*

Күп иде, күп сиңа әйтер сүзләр...
Ул сүзләрнең кайнар ташкыны
Тыннарымны минем кыса иде,
Чыгам-чыгам диеп, ашкынып.

Канат ярган кошны чыгармыйча
Саклап тоткан кебек ояда,
Йөрттем-йөрттем дә мин сүзләремне,
Ыргыттым бер ташлы кыяга.

Шул чагында ташлар ярылды да,
Чишмә бәреп чыкты ургылып.
Дулкыннары чапты синең арттан,
Әллә нинди ярсу җыр булып.

Син юындың әнә шул чишмәдә,
Суын эчтең ятып түшеңә.
Сиздең шунда: тамырларың буйлап
Ут йөгерде синең эчеңә.

Йөрәгеңә күчкән бу утларның
Аңламадың ләкин сәбәбен.
Акты-китте чишмә үзән буйлап,
Үзенә йотып иң зур хәбәрен.

*1999*

## *Вәгъдә бирми генә*

Зинһар, миңа син вәгъдәләр бирмә,
Бигрәк беркатлы бәндә мин.
Ышанам да биргән вәгъдәләргә,
Каламын бик авыр хәлдә мин.

Бәргәләнә җаным, ни булды дип,
Хәвефле бит бигрәк заманы.
Уйларымнан мең кат күпер салып,
Тоташтырам ике араны.

Төннәр җитсә — юлга йолдыз сибәм,
Калмагаең, димен, адашып.
Көндезләрен күккә кояш эләм,
Маякларым тора алмашып.

Көтәм-көтәм, көн-төннәрне этеп,
Ашыктырып вакыт агышын.
Йөрәгемне кагам зур чаң итеп,
Ишетер, дип чакыру тавышын.

Беркөн килеп, кимсетелгән өмет
Түзә алмас мондый газапка —
Кошлар юлы буйлап китеп барыр,
Кире кайтмас җиргә, еракка.

Билгесезлек, көтү газаплары
Тәмуг газабына тиң икән.
Килә калсаң — күңелем ачык сиңа,
Вәгъдә бирми генә кил, көтәм.

*1999*

## *Кызыл кар яуган булыр*

Син миңа килерсең әле
Ут сорап учагыңа.
Утлы утыннарны күпләп
Төярмен кочагыңа.
Кабынырсың шунда үзең дә,
Ялкынга уралырсың.
Тәкәбберлегеңне җуеп,
Кочакта югалырсың.
Горурлыгың төтен булып
Кушылыр ак болытка.
Алып китәр ак болытлар
Аны ерак офыкка.
Калырбыз назлар илендә
Икәүдән-икәү генә.
Анда салкын кышлар булмас,
Булыр яз да җәй генә.
Сөюдән бераз айныгач,
Каннар сүрелә төшкәч,
Күзләргә бездән башка да
Дөнья күренә төшкәч,
Карарбыз да тирә-якка —
Күңелләр хәйран булыр:
Җәйге ап-ак чәчәкләргә
Кызыл кар яуган булыр.

*1999*

# *Күләгә*

Күләгәң дә синең актыр кебек,
Күңелемә шулай тоела.
Юккамыни синең күләгәңдә
Ап-ак ромашкалар коена.

Күзге аша төшкән кояш кебек
Гөлдән-гөлгә күчә күләгәң.
Күләгәң дә ләкин күп вакытны
Ерак йөри минем тирәдән.

Сыйпап куйсам ап-ак гөлләр таҗын,
Тәннәремә йөгерә җылылык.
Йөрим-йөрим күләгәңне куып,
Чәчәк аклыгында коенып.

Күләгәне тотып булмый, беләм,
Ләкин йөрәк һаман өметтә.
Шушы өмет һич тынгылык бирми,
Йөгертә дә мине йөгертә.

Беркөн килеп шушы күләгәңнең
Өсләренә, ахры, авармын.
Авармын да, соңгы балкыш булып,
Аклыгыңа кушылып янармын.

*1999*

# *Болан кызы*

Кайсы урманнардан килдең,
Әй кыргый болан кызы? —
Кулга ияләштерергә
Сузыйм ипиме, тозмы?

Күзләреңдә сагаю бар,
Йә, әйт, нәрсә өркетә?
Юлыктыңмы карурманда
Әллә явыз бөркеткә?

Ышанычың яулар өчен
Табыйм соң нинди чара?
Кулларымда мылтыгым юк,
Ипи-тоз гына — кара!

Курыкма син, болан кызы,
Күңелем изге ниятта.
Ышык табарсың үзеңә
Карурмандай йөрәктә.

*1999*

# *Бер чәчәк алачакмын*

Бикләп, суга аттылармы
Йөрәгеңнең ачкычын?
Әллә биек кыяларга
Урлап качтымы лачын?

Яки язгы бозлар белән
Актымы ул еракка?
Очкан кошлар ташладымы
Янып торган учакка?

Эзлим, эзлим, таба алмыйм,
Чабып чыгам юлларга.
Ялкыннарда өтеләм дә
Чумам тирән суларга.

Эзлим биек кыялардан —
Бөркет ояларыннан.
Кыялар да киртә түгел
Минем хыялларыма.

Күңелем сизә, бу ачкычны
Барыбер табачакмын.
Җиде биккә бикләнсә дә
Йозагың ачачакмын.
Ачып кереп, гөлбакчаңнан
Бер чәчәк алачакмын.
Алачакмын!

*1999*

## *Адашты башкайларым*

Янадыр йөзкәйләрең,
Карадыр күзкәйләрең;
Үтеп китсәң, йөрәгемдә
Каладыр эзкәйләрең.

Нечкәдер билкәйләрең,
Зифадыр буйкайларың.
Карашыңнан диңгез булып
Чайкала уйкайларым.

Горурдыр башкайларың,
Кыйгачтыр кашкайларың.
Кашкайларың арасында
Адашты башкайларым.

*1999*

## *Тоткын йөрәк*

«Юк!» — диеп тә
                    әйткәнең юк,
Һәм «әйе» дә димәдең.
Шул ике сүз арасында
Эленеп калды йөрәгем.

Йолдызларга атылырмы,
Очармы ул упкынга —
Синең хөкем-җавап кирәк
Бу бичара тоткынга.

*1999*

## *Һәм шаккаттым...*

Бүген сине йөрәгемнән
Алып аттым
Һәм шаккаттым:
Җирләр тетрәмәде,
Күкләр күкрәмәде,
Кояш каралмады,
Йөрәк канамады.
Ә мин, юләр, күпме вакыт
Куркып йөрдем.
Йөрәгемне кулым белән
Тотып йөрдем.
Бәрелеп китсә —
Канар, дидем.
Очкын төшсә —
Янар, дидем.
Сулар үргә
Агар, дидем.
Таулар өскә
Авар, дидем...
Бүген сине йөрәгемнән
Йолкып аттым
Һәм шаккаттым:
Таулар тетрәмәде,
Дөнья үзгәрмәде —
Узды бар да тып-тын.
Калды бары күңелемдә
Бер уч бушлык,
Бер уч сагыш
Һәм таралмас бер моң.

*1999*

## *Коеныйм бер серле күлеңдә*

Җибәр мине күңелең бакчасына,
Капкаларың ач та киереп.
Миним әле мәрмәр тауларыңа,
Чишмәләрең эчим иелеп.

Алмаларың биетим учларымда,
Чияләрең эретим телемдә.
Ак төнбоек чәчәкләрен җыеп
Коеныйм бер серле күлеңдә.

Ярларыңа чыгып яллар итим,
Ак мәрмәргә салыйм башымны.
Рөхсәт ит, син, беркем ачалмаган
Яңа утрауларны ачуны.

Җибәр мине күңелең бакчасына —
Матурлык һәм аклык иленә.
Үтим барлык яшерен сукмаклардан,
Сокланып һәр гүзәл гөленә.

*1999*

## *Йә, нәрсә дип әйтим?*

Кинәт китеп бардың да син,
Шәһәр калды ятим.
Ятим калган шәһәремә
Инде ни дип әйтим?

Юатырлык сүзләр тапмыйм
Үксез урамнарны.
Елап чыга төннәр буе
Мартның бураннары.

Яз да килә алмый калды,
Ярты юлда туктап.
Ичмасам, язларны китер —
Яулыгыңны болгап.

Синсез дә, язсыз да калгач
Шәһәребез ятим.
Тәрәзәмне җилләр шакый,
Йә, нәрсә дип әйтим?

*1999*

## *Мине яратмаган кызга*

Беләм, мине яратмадың
Һәм яратмассың бер дә.
Тик белеп тор: яратмавың
Калачак бит шигырьдә.

Синең мине сөймәвеңне
Бар дөньяга фаш итәм.
Әйтсеннәр әле: бу кызый
Бигрәк юләр баш икән.

Моның өчен гафу итмәс
Тарих сине һичкайчан.
Киләчәк турында бераз
Уйлар идең, ичмасам.

Әллә бу хатаңны үзең
Җитмисеңме төшенеп?
Син җитмәсәң дә төшенеп,
Төшенер бит кешелек.

Мине яратмыйча, кызый,
Җыйма дөнья каргышын.
Уйлан да соңга калганчы
Төзәт тизрәк ялгышың.

*1999*

* * *

Кояш чыга, кояш бата
Ике кашың арасында.
Мәхәббәтнең сере ята
Күзләреңнең карасында.

Таң нурлары җем-җем итә
Битләреңнең алмасында.
Карыймын да шул нурларга,
Коенам шатлык дәрьясында.

Иренең — чәчәк, шул чәчәккә
Чыклар булып кунар идем.
Әкрен-әкрен шунда сеңеп,
Мәңге юкка чыгар идем.

*1999*

* * *

Һаваларда очкан кошларның
Җиле кагылып үтте гөлләргә.
Талпынышып куйды бу гөлләр,
Иярмәкче булып җилләргә.

Кошлар үтте — басылды җилләр,
Моңсуланып калдылар гөлләр.
Гөлләр арасында мин идем,
Кошлар арасында син идең!

*1998*

## *Кулъяулык*

Кулъяулык бүләк иттең син,
Чигелеше хикмәтле:
Гөлләренең яфраклары
Хәтерләтә йөрәкне.

Әйттең шунда оялып кына,
Ошармы-юкмы, диден.
Кулъяулык бирүләр хәзер
Модадан чыкты, диден.

Рәхмәт, дустым, бүләгеңдә
Күз нурыңның җылысы.
Мәхәббәтнең һичбер вакыт
Чыкмый аның модасы.

*1998*

## *Ычкынырмын димә*

Башта кердең күңелемә,
Аннан кердең шигыремә.
Күңелем — тозак,
Шигырем — йозак.
Инде ычкынырмын димә.

*1998*

## *«Ул» булыр*

Мәхәббәт турында шигырь
Яз әле миңа, дисең.
Сөю үзе иң шәп шигырь,
Әллә шуны белмисең?

Сөй генә син, йөрәгеңнән
Шигырь торыр агылып.
«Ул!» диярсең, битләреңә
Җил китсә дә кагылып.

Кошлар кунса да агачка,
«Ул!» дип йөгереп чыгарсың.
Җырлаганың булмаса да,
Кошка кушылып җырларсың.

Күкрәгеңә шатлык тулыр,
Йөрәгеңә моң тулыр.
Җирдә бүтән кеше калмас,
Бердәнбер тик «Ул» булыр.

Иртә булыр, соң булыр,
Ятсаң-торсаң, «Ул» булыр.
Мәхәббәт турында шигырь
Синең өчен шул булыр.

*1998*

* * *

Изүләрне ачып бара идем,
Давыл бәреп керде куеныма.
Кыстым аның тыгыз билләреннән,
Ул сарылды минем муеныма.

Бөтереләбөтереләочтык
Таныш түгел карурманнар аша.
Күкләр гизеп йөрдек,
Болытларның
Ап-ак мендәренә баса-баса.

Йолдызларны чүеп уйнадык та
Яллар иттек Ай өстенә төшеп.
Җирдәгеләр карап торды безгә:
«Бәхетлеләр була әнә ничек!»

Ул көннән соң күпме гомер үткән,
Күпме йолдыз янып җиргә төшкән.
Куенында давыл юк, димәгез,
Ул бит минем йөрәгемә күчкән.

*1998*

## *Сагынасыңмы?*

Сагын әйдә!
Сагынасыңмы? Сагын әйдә,
Үләрдәй булып сагын.
Көннәрне төннәргә бәйләп
Тизләт күрешү таңын.
Йолдызлардан баскыч тезеп
Эзлә кавышу җаен.

Сагынасыңмы? Сагын әйдә,
Уйлап йөр тагын-тагын.
Шул уйлар өермәсендә
Яшеннәр булып кабын.
Ярсу яшен ташы булып,
Учыма төшәр җаның.

Сагынасыңмы? Сагын әйдә,
Сагынулар саваплы.
Сагына-сагына эзли кеше
Мәхәббәттә җавапны.
Сагынып сыналган сөю
Була талмас канатлы.

Сагынасыңмы? Сагын әйдә,
Сагынуда дәва бар.
Күрә белсәң — күз яшьтән дә
Җем-җем нурлар тамалар.
Тозлы тамчыдан ябыла
Кайчак иң зур яралар.
Сагынасыңмы?
Сагын әйдә!

*1998*

## *Нидер булды*

Безнең әле бу дөньяда
Уртак нәрсәләр бик аз.
Юк хәтта битне җылыткан
Уртак кояшлы бер яз.

Бергә-бергә куллар болгап,
Кошлар да озатмадык.
Әллә кошлар киткән иде,
Әллә без очратмадык.

Күккә карап, бер-беребезгә
Йолдызлар бүлешмәдек.
Оялу тотып тордымы —
Хәтта бер үбешмәдек.

Тик барыбер нидер калды,
Җитмибез аңлап кына.
Йөрибез хәтер кырында
Сукмаклар ялгап кына.

*1998*

* * *

Күзләреңне нигә яшердең соң,
Туйганчы бер карый алмадым.
Каян белим керфек асларында
Яшь бөртеге дөрләп янганын.

Күзләреңне нигә яшердең соң,
Читкә таба бордың карашың?
Каян белим синең йөрәгеңә
Янар таудан утлар кабасын.

Күзләреңне нигә яшердең соң,
Курыктың бит, әйе, курыктың.
Рәхәт түгеллеген беләм, дустым,
Күзләренә карау чынлыкның.

*1998*

## *Аңлый гына алам*

Яна каләм очларында
Кайный-кайный карам.
Утлы җырдан юллар түшәп,
Сиңа таба барам.

Барам, барам, якынаймыйм,
Артык ерак арам.
Йөрәгеңне яулый алмыйм,
Аңлый гына алам.

*1998*

* * *

Һәр агачта утын гына күрсәң,
Ташлар гына күрсәң һәр тауда —
Кереп йөрмә күңелем урманына,
Андыйларга урын юк анда.

Ишетмәссең кошлар сайравын син,
Ишетмәссең тынлык тавышын.
Ишетмәссең бәгырьләргә бәрелеп
Агып яткан чишмә агышын.

Ташлар тәгәрәтер өчен генә
Менеп йөрмә биек тауларга.
Һәр кыяда бөркет оясы бар,
Тия күрмә мәгърур җаннарга.

Утын өчен бүтән урман эзлә,
Таш кирәксә — бүтән таулар тап.
Урманыма минем җырлар үскән,
Тауларыма кояш төшкән чак.

*1998*

## *Мәхәббәт һәм сагыну турында*

Сагынуларны әгәр белмәсәң син,
Көзге урманнарга кер дә бер —
Учыңа җый сары яфракларны,
Сагыну серен алар беләдер.

Алай гына әгәр төшенмәсәң,
Сары яфрак түшәп юлыңа,
Эчкәрәк уз,
Моң чишмәсен табып,
Иренең тидер аның суына.

Шунда синең тамырларың буйлап
Ага башлар кайнар бер агым.
Сары ялкын булып күккә үрләр
Кабыныр да йөрәк учагың.

Шул учакның сары ялкыннары
Кушылыр да шәфәкъ нурына —
Сөйләр сиңа кичке җилләр белән
Мәхәббәт һәм сагыну турында.

*1998*

## *Яңа кар*

Яңа гына яуган ап-ак кар син,
Яктылыгың камаштыра күзне.
Карлар ерып кереп китәр идем,
Куркам ләкин җуярмын дип эзне.
        Әнә кич тә якынлашып килә,
        Эңгер сарган инде керфекләрне.
        Иеләм дә алам учларыма
        Күзне камаштырган бөртекләрне.
Кысам учка, шытырдатып кысам,
Бармакларым батып керә карга.
Эри-эри, карым юкка чыга,
Әверелеп вак-вак тамчыларга.

*1998*

## *Шуны бел*

Әй нечкә бил, нечкә бил,
Нечкә билең кочыйм — кил.
Кочтырмасаң, билкәйләрең
Юанаер — шуны бел.
        Әй матур гөл, матур гөл,
        Иреннәрең үбим бер.
        Үптермәсәң, иренеңнең
        Алсулыгы бетәр — бел.
Әй җәйге җил, җәйге җил,
Битемә бер кагыл — кил.
Бер назлавың да җәл булса,
Егылып үләм — шуны бел!

*1998*

## *Син барлыкны тоеп*

Иреннәрең синең хәтерләтә
Алсуланып пешкән җиләкне.
Пешкән җиләкләргә кагылырга
Кояш кына алган рөхсәтне.
Иңнәреңә төшкән чәчләреңне
Җилләр генә сыйпарга хаклы.
Сөенәмен, сине сөйгән җилләр
Сыйпап китсә минем яңакны.
Билләреңнән кысып кочар өчен
Сорый алмыйм хәтта рөхсәт тә.
Син барлыкны тоеп яшим шулай
Газаплы һәм татлы михнәттә.

*1998*

## * * *

Аллар булам әле бер,
Гөлләр булам әле бер,
Куеннарыңа тулучы
Җилләр булам әле бер.
Утлар булам әле бер,
Сулар булам әле бер.
Мәңгелеккә адаштырган
Юллар булам әле бер.
Тамчы булам әле бер,
Камчы булам әле бер.
Мәхәббәттә мәңге тугры
Сакчы булам әле бер.

*1998*

## *Үкенмим*

Соң очрадың диеп үкенмимен,
Очрадың син бик тә вакытлы.
Эңгер-меңгер төшкән күңелемне
Күз нурларың синең яктыртты.

Сөю килә һәрчак бик вакытлы,
Мәхәббәттә булмый «соң», «иртә».
Бер караштан, назлы бер караштан,
Җимерелеп төшә мең киртә.

Агыла хисләр дулкын-дулкын булып,
Дулкыннарда йөрәк чайкала.
Кайнар дулкыннарда юыла-юыла
Тузанланган җаннар сафлана.

Үкенмимен сине соң таптым дип,
Бәхет кирәк кешегә һәрвакыт.
Гомер нигә, яшәмәсәң әгәр
Газапланып, янып, яратып?!

*1998*

* * *

Син әле кабынмаган ут,
Сине кабызасы бар.
Боз өстенә учак итеп,
Суга агызасы бар.

Син әле язылмаган җыр,
Нотага саласы бар.
Иң югары тавыш белән
Күтәреп аласы бар.

Син ачылмаган бер йолдыз,
Эзлисе, табасы бар.
Эзләп табып, исем кушкач,
Ялтырап янасың бар.

Кабынырсың да янарсың,
Табарсың үз йолдызың.
Мин эзләрмен йолдызлардан
Үзем ачкан Җир кызын.

*1998*

## *Фәнис-Нурсөя кебек*

Үтмәде гомер заяга —
Яндык, сөелдек, сөйдек.
Әйтсеннәр иң кайнарларга —
Яшиләр менә болар да
Фәнис-Нурсөя кебек.

Мәхәббәтнең гөлләреннән
Мәңгелек оя үрдек.
Әйтсеннәр гүзәл парларга —
Яшиләр менә болар да
Фәнис-Нурсөя кебек.

Бардык, бардык,
юллар ярдык,
Үрдән үрләргә мендек.
Әйтсеннәр иң чыдамнарга —
Яшиләр менә болар да
Фәнис-Нурсөя кебек.

Без китәрбез, сөю калыр
Җыр-дастаннарга кереп.
Әйтсеннәр тугры җаннарга —
Яшиләр менә болар да
Фәнис-Нурсөя кебек.

*1998*

## *Безнең ара*

Синең белән минем ара —
Җир белән күк арасы.
Йолдызлардан юллар түшәп
Барасы да барасы.
        Синең белән минем ара —
        Таң һәм шәфәкъ арасы.
        Таң шәфәкъка кушылганчы
        Янасы да янасы.
Безнең ара үткән белән
Киләчәкнең арасы.
Калды бары шул бушлыкка
Күпер генә саласы.

*1998*

## *Мәхәббәт маҗарасы*

Син керсен дип, ишек ачтым —
Җилләр керде.
Җилләр түгел, өерелеп
Җеннәр керде.
        Ишегемне тизрәк кире
        Булдым япмак.
        Тик ишеккә кысылып калды
        Минем бармак.
Синең хактагы уйларым
Чыкты истән.
Сөенеп йөрим: ярый бармак
Калды исән.

*1997*

## *Югарыда гына кал идең*

Тамчы идең, Син бик туңган идең,
Буй җитмәслек җиргә кунган идең.
Сиңа карап соклануым булды,
Синең йөзең нурлар белән тулды.

Уйламыйча һич тә аны-моны:
— Там, там! — диеп,
синңа суздым кулны.
Карашымнан минем эредең,
Учларыма минем сикердең.

Төштең учка. Сүнде нурларың,
Матурлыгың синең урладым.
Их!
Югарыда гына кал идең,
Ымсындырып мәңге ян идең.

*1997*

## * * *

Суындың, дип әйтәсең син,
Беттеме, дисең, утың.
Ничек инде дөрли алсын
Учакта сыңар утын?
Сүнмәсен дисәң бу ялкын —
Һич югы, бер тының өр.
Сулышыңны да кызгансаң,
Учагымнан читтә йөр.

*1997*

* * *

Боз өстендә ике гашыйк
Күптән тора инде басып.
Бер-берсеннән күз алмыйлар,
Сөюләре тора ташып.

Гашыйк кыз һәм гашыйк егет —
Мәңге аерылмас кебек.
Бик тә якын аралары,
Кызарган бит алмалары.

Менә кинәт боз ярылды,
Баскан эзләр аерылды.
Гашыйклар моны тоймады,
Еракта иде уйлары.

Зурайды бозның ярыгы,
Көчәйде суның агымы.
Аерылды бу ике боз —
Ерагайды егет һәм кыз.

Үрелделәр — кул җитмәде,
Йөгерделәр — тын җитмәде.
Бозлар акты диңгезләргә —
Яшьлек эзләрен эзләргә.

*1997*

## *Әллә төш бу, әллә өн булды*

Гөнаһ-мазар булыр димәдем —
Ертып ташлап кара күлмәген,
Ачтым киереп ярсу хис белән
Кара төннең ап-ак күкрәген.

Ике йолдыз чыкты атылып,
Күзне камаштырды яктылык.
Йолдызларга таба үрелдем,
Яктылыкка кереп күмелдем.

Әллә әкият, әллә чын булды,
Күкрәгемә серле нур тулды.
Очтым-очтым күкләр катына
Төннең фәрештәсе артыннан.

Ачык иде күкләр капусы,
Гүзәл иде төннәр яктысы.
Каның уйный, төшсә йөзеңә
Бу яктының тик бер чаткысы.

Әллә нәрсә булды — тилердем,
Йолдыз өсләреннән йөгердем.
Малай идем — очкан чагында,
Егет булып күктә өлгердем.

*1997*

* * *

Сине кемгә тиңлим икән,
Дип торганда —
Бер нәфис гөл үсеп чыкты
Кар-буранда.

Туңмасын дип, гөлгә сулыш
Өрмәк булдым —
Һәм үземнең битләремдә
Ялкын тойдым.

Гөл урынында кар эреде,
Сулар акты.
Йөрәгемне, тук-тук итеп,
Язлар какты.

Калдым ташу уртасында,
Йөзә белмим.
Дулкын аша кулын изи
Нәфис гөлем.

Урынымнан кузгалдыммы —
Батам инде.
Кузгалмасам — кышларыма
Кайтам инде.

*1997*

* * *

«Яратам» дип әйтмичә тор,
Түзә алсаң — түз әле.
Тимәсен япь-яшь сөюгә
Чит-ятларның күзләре.

«Яратам» дип әйтмичә тор,
Кырлар — күз,
урман — колак:
Миңа дигән сүзләреңне
Җилләр китмәсен урлап.

«Яратам» дип әйтмичә тор,
Суксын әле сәгате.
Җиңсен минем горурлыкны
Бу сүзеңнең гайрәте.

«Яратам» дип әйтмичә тор,
Жанда булмаса яшен.
Нишләрбез, әгәр сүндерсә
Аны бер тамчы яшем?!

*1997*

* * *

Сафлыкка шундый нык сусалган,
Зиһеннәр, акыллар чуалган.
Эчимче күзеңнең нурларын,
Яктырсын беразга уйларым.

Шатлыкка шундый нык сусалган,
Үткәннәр рәшәгә уралган.
Эчимче туйганчы шатлыгың,
Йөземә күчмәсме аклыгың.

Сөюгә шундый нык сусалган,
Йөрәккә карурман моң салган.
Таратчы шул моңнар томанын,
Яктырсын мәхәббәт урманым.

Бәхеткә шундый нык сусалган,
Юллары ялкынга уралган.
Табалмыйм, табалмыйм,
табалмыйм —
Юлларның очлары югалган.

*1997*

* * *

Яз килмәсәң, миңа күзләрен кил,
Теләгәндә табыла чарасы;
Күзге бакчадагы соңгы алма
Булыр безнең бәхет алмасы.

Безнең шушы гүзәл алмабызга
Кызыгырлар үткән-сүткәннәр.
Һәм әйтерләр:
                барыбер кавыша икән
Кавышуны чынлап көткәннәр.

Тәгәрәтеп шушы алмабызны,
Иярербез без дә аңарга.
Йә упкынга төшерер ул безне,
Йә күтәрер янартауларга.

Күзләрдә кил, яме, күзләрдә кил,
Күздә пешә бәхет алмасы.
Бәхет алмаларын тәгәрәтеп
Барасы да әле, барасы.

*1997*

## *Көзге яшен*

Көзге яшен, көзге яшен,
Атылдың да сүндең.
Очкының җиргә төшмәде,
Болытларга сеңде.

Яшәдем мин давыл көтеп
Инде ничә көзләр.
Агылып болыт килсә дә,
Күктә булды күзләр.

Көттем сине, көзге яшен,
Өметләнеп, куркып.
Мин аварга әзер идем,
Йөрәгемне тотып.

Ә син күкрәмичә генә
Бер ялтырап сүндең.
Мин бит күкрәүсез көзләргә
Әзер түгел идем,
Әзер түгел идем.

*1997*

* * *

Хатлар язам сиңа,
Каләмемне
Мана-мана төннәр карасына.
Күпер сузам шулай төннәр буе
Йөрәк белән йөрәк арасына.
        Күперемне сузып бетерергә
        Озын төннәр ләкин җитми кала.
        Көн туа да
        Кояш яктысында
        Төнге күперләрем дөрләп яна.
Юллар түшим, кичтән таңга кадәр,
Упкын белән упкын арасына.
Сак-Сок язмышлары язылган шул
Җирдә бик күп адәм баласына.

*1997*

* * *

Язмыш бүләк иткән бер кешемме,
Әллә бары хыял җимешемме,
Белмим инде, миңа син кемдер?
Хыял гына булсаң, әйлән чынга,
Йөзләремә кояш булып кун да
Бер сөендер әле, сөендер.
        Ә бәлки, мин алдап күңелемне,
        Җиңүләргә санап җиңелүне,
        Упкыннарга таба очамдыр?
        Һава өреп сулган җилкәнемә,
        Бәхеткә соң түгел икәненә
        Бер ышандыр әле, ышандыр.

*1997*

## *Оялчан гөл*

Дөнья инде үз хәленә күнеп,
Чумган иде көзләр моңына —
Әллә айдан, әллә йолдызлардан
Сикереп төште бер гөл болынга.

Үз матурлыгыннан оялгандай
Карады ул җиргә тартынып.
Керфек асларыннан саркып чыкты
Әллә нинди серле яктылык.

Бар дөньяны күмде сихри нурга
Шушы гөлнең гүзәл балкышы.
Купты җирдә хисләр зил-зиләсе,
Көзләр белән язлар тартышты.

Бу оялчан гөлне куркытмады
Хәтта көзнең салкын җилләре.
Утырды ул тып-тын гына балкып,
Сокландырып әллә кемнәрне.

Бер карлыгач яз китерми, диләр,
Яз китерде ләкин бер чәчәк.
Күңелем әле бу чәчәкле көзгә
Кабат-кабат урап киләчәк.

Киләчәк тә, хыял белән бизәп,
Аны тагы да матур итәчәк.
Бәхет өчен бик күп кирәкмени? —
Җитә аңа кайчак бер чәчәк.
Бер чәчәк!

*1997*

## *Сәбәп тап*

Язлар әле алда, димә,
Вакыт атын әйдәп чап.
Язларны юлда каршылыйк —
Күрешергә сәбәп тап.

Язлар, җәйләр үткән булыр,
Бер борылып карасак.
Эчик җәйләр хозурлыгын,
Күрешергә чара тап.

Кошлар китәр, казлар китәр,
Көзге вакыт — якут чак.
Якутлар әрәм булмасын,
Күрешергә вакыт тап.

Җәй дә, кыш та,
                яз да, көз дә
Мәхәббәткә әйбәт чак.
Гомерләр зая узмасын,
Күрешергә сәбәп тап.

*1997*

## *Бетте дөнья гамьнәре*

Алмалар өздем учыма
Мәхәббәт бакчасыннан.
Иң зур бүләк алдым гүя
Оҗмахлар патшасыннан.

Ул алмалар яфракларга
Качып үскәннәр иде.
Качып үскәнгә күрәдер,
Тулып пешкәннәр иде.

Алмаларны озак кына
Уйнаттым учларымда.
Дөрләде давыллы хисләр
Йөрәгем учагында.

Әле һаман телләремдә
Ул алманың тәмнәре.
Күңлем
    җәннәт бакчасында —
Бетте дөнья гамьнәре.

*1997*

* * *

Сиңа булган сөюемне
Әйттем кыядагы ташка.
Таш ярылып, чәчәк үсте,
Нур сибелде һәр тарафка.

Әйттем нәни бер чишмәгә —
Әверелде зур елгага.
Ярсу-ярсу дулкыннары
Таралышты бар дөньяга.

Әйттем корыган бер каенга,
Каен шаулап яфрак ярды.
Көзләрен дә саргаймады
Ул каенның яфраклары.

Әйттем аны кара төнгә,
Кояш чыкты ярып күкне.
Әйттем биек мәгъруր тауга,
Ул, иелеп, җирне үпте.

Әйттем тып-тын карурманга —
Әй шаулады, әй җилләде.
Беркөн килеп әйттем сиңа —
Керфегең дә селкенмәде.

*1997*

## *Әй кара каш!*

Күктә йолдыз бар иде,
Синең белән пар иде.
Йолдыз төште атылып,
Кочагыңа тартылып.
        Сокланырга төннәрен
        Якты йолдыз калмады:
        Атылды да сүнде ул,
        Кочагыңда янмады.
Әй кара каш, кара каш,
Йолдыз күрсәң, читкә кач.
Җыелмасын күп булып
Куеныңа кара таш.
Әй кара каш, кара каш!

*1997*

## *Соңгы чәчәк*

Үтте җәйләр, китте кошлар,
Шиңделәр соңгы гөлләр.
Сары яфракларны җиргә
Сибәләр көзге җилләр.
        Кояш та офык читендә
        Күренә сирәк кенә.
        Мәңге шиңмәс чәчәк булып
        Калды тик йөрәк кенә.
Көз салкыны тияр иде
Бу чәчәккә дә күптән,
Мәхәббәт тылсымы аны
Шиңмәслек итеп киткән.

*1996*

## *Кыюсыз парлар*

Ярның бер ягында — син,
Ярның бер ягында — мин.
Елга ага ярсып-ярсып,
Елга тирән, елга киң.

Син дә суга ташланмыйсың,
Мин дә ташланмыйм аңа.
Йөгерәбез яр буенча,
Тик якынаймый ара.

Күпме шулай йөгерербез,
Арып егылырбызмы?
Әллә олы диңгезләргә
Барып кушылырбызмы?

Ә хәзергә чабабыз,
Шуңардан тәм табабыз.
Син бер ярда, мин бер ярда
Аерым учак ягабыз.

*1996*

## *Таш диварлы крепость*

(Баллада)

Әйттең: «Йөрәгем крепость,
Ала алмассың яулап!»
Уклар аттым, туплар аттым,
Булдым крепость алмак.
Вата алмады тупларым,
Нык иде диварларың.
Йөрәк каршында көчсез шул
Тупларың, коралларың.
Ә беркөнне шигырь язып
Тапшырдым бер былбылга.
Сайра, дидем, һәр таң саен
Синең тәрәз турында.
Көннәр үтте, төннәр үтте,
Былбылым сайрап торды.
Җырларның иң матурларын,
Моңлысын сайлап торды.
Һәм ишелеп төште кинәт
Крепость диварларың.
Атты сакчылар бер читкә
Кулдагы коралларын.
Корал җиңә алмаганны
Җиңде җырым, шигырем.
Инде мәңгелеккә ачык
Синең бикле күңелең.
Хәзер анда көн-төн сайрый
Мәхәббәтнең былбылы.
Ишетелә еракларга
Ул былбылның җыр-моңы.

*1995*

## *Калсын җирдә безнең сөю*

Бар бит әле бу дөньяда
Безне сөючеләр дә.
Рәхмәт яусын, күгебезгә
Йолдыз чөючеләргә.
Без, бәлки, кара төннәрдә
Адашкан булыр идек.
Идеалларны аракыга
Алмашкан булыр идек.
Өмет учакларын җилләр
Туздырып китәр иде.
Әйталмаган назларыбыз
Җаннарны өтәр иде.
Йөртер идек куеныбызда
Таш саклап дөньясына,
Яки сикереп төшәр идек
Сагышлар елгасына.
Сөюгә урын юк, диләр,
Безнең бу заманнарда.
Ышанмагыз, ышанмагыз
Сез мондый ялганнарга.
Күкрәктә йөрәк бар чакта,
Сөюгә бетмәс урын.
Күтәрик әле күкләргә
Бөек мәхәббәт җырын.
Очсын ул зәңгәр күкләргә,
Сайрасын былбыл булып.
Калсын җирдә безнең сөю
Мәңгелек бер җыр булып.

*1994*

## *Бул хуҗа!*

Хуҗасыз йорт тизрәк җимерелә,
Бу хакыйкать күптән билгеле.
Озаграк торсын дисәң әгәр,
Буш калдырма күңел-өемне.

Ни беләндер һәрчак тутырып тор,
Хуҗа бары торсын күренеп.
Тәрәз төпләрендә, тышка карап,
Гөлләр үссен өскә үрелеп.

Ак пәрдәләр ачылып ябылсыннар,
Мәче ятсын шунда тупсада.
Тирес өсләрендә тибенеп йөрсен
Берәр аксак тавык булса да.

Һич югында, кара төтен чыксын
Морҗасыннан кайбер көннәрдә.
Дулап-дулап чыккан кара төтен
Азык булыр явыз телләргә.

Сөю, нәфрәт, борчу, мәшәкатьләр,—
Бөтенесе булсын — мин риза.
Туздырмыйча саклап тотар өчен
Өйгә кирәк һәрчак бер хуҗа,
Шул өемдә мәңге бул хуҗа!

*1992*

## *Сызгыру*

Кич җиттеме, өй каршында
Бер яшь егет сызгыра.
Күрәсең, безнең бу йортта
Ул яраткан кыз тора.

Егетнең сызгыруында
Төрле халәт бар сыман:
Бер карыйсың — ялвару күк,
Бер карыйсың — зар сыман.

Чакыра да, үртәлә дә,
Таләп тә итә егет.
Әгәр ул бер көн килмәсә,
Нидер җитмидер кебек.

Тик кыз чыкмый, әллә инде
Бик тәкәббер кыз микән?
Әллә йөрәк урынында
Бер йомарлам боз микән?

Ярый ла егет, түзмичә,
Беркөн китеп бармаса —
Гомер буе кызның үзенә
«Сызгырырга» калмаса.

*1991*

## *Мәхәббәткә ялвару*

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Бик аз кунак булдың бит әле.
Хыял тулы минем йөрәккә
Тагын бер яз бүләк ит әле.

Ә аннары китсәң китәрсең,
Өметләрне киссәң кисәрсең.
Озатырмын үзем кул болгап,
Йөгерерләр гөлләр юл буйлап.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер җәй бүләк ит әле.
Кабызырга сүнгән учакны
Тагын бер җай бүләк ит әле.

Китмә әле, китмә, мәхәббәт,
Тагын бер көз бүләк ит әле.
Бакчамдагы соңгы гөлләрне
Өзәселәр бардыр бит әле.

*1991*

## *Бирмә мине*

Бирмә мине беркемгә дә,
Калканым бул — яуса... ук...
Мәхәббәтне бүлгәләргә
Беркемнең да хакы юк.

Тибрәт сөю бишегендә
Моңлы сазларың белән.
Бәйлә мине йөрәгеңә
Кайнар назларың белән.

Гөлләр булып сокландыр да
Күңелемне хәйран ит.
Күзләремне язлар ит син,
Кышларымны җәйләр ит.

Бирмә мине беркемгә дә,
Бирмә хәтта үлемгә.
Сокландыр гел, ашкындыр гел,
Йолдызлар сип күңелгә.

*1991*

## *Умырзая*

Һәр яз саен күңелем урманында
Умырзая шытып чыга да,
Зәңгәр күккә зәңгәр күзен текәп,
Гаҗәпләнеп карый дөньяга.

Өзүчесен көтә, сабыр гына,
Кар астыннан чыккан тыйнак гөл.
Сискәнә ул агач ботагына
Кагылып куйганда да уйнак җил.

Аяк очларына баса-баса
Күзәтә ул: юкмы бирәрсе?
Шушы матурлыгын бирәрсенә
Бик бирәсе килә, бирәсе.

Көтә-көтә шаулы язлар үтә,
Зәңгәр күзнең бетә нурлары.
Тын аланда үкси умырзая:
«Күрүчеләр мине булмады шул,
Күрүчеләр мине булмады!»

Язлар саен бу хәл кабатлана —
Тамыры һаман исән бу гөлнең.
Җилләр генә бер шаулатып ала
Урманнарын минем күңелнең.

*1991*

## *Кайда ул?*

Кайчандыр, сине сөеп, мин
Күкләргә ашкан идем.
Мәхәббәт сарайларының
Ишеген ачкан идем.

Кайда ул гүзәл сарайлар,
Кайда ул шашкын хисләр?
Кайда ул безнең җаннарны
Бербөтен иткән кичләр?

Кайчандыр, сине сөеп, мин
Назлаган, кочкан идем.
Иң матур гөлләргә синең
Исемеңне кушкан идем.

Кайда ул синең исемгә
Лаеклы гүзәл гөлләр?
Кайда ул чәчәк диңгезен
Бергәләп гизгән көннәр?

Кайчандыр, сине сөеп, мин
Утларга пешкән идем.
Иреннәреңнән сөюнең
Чишмәсен эчкән идем.

Кайда ул утлы чишмәләр,
Кайда ул татлы сулар?
Кайда ул якты хыяллар,
Кайда ул якты уйлар?
Кайда?

*1990*

# *Үлчәү юк*

*Нурсөягә*

Җылылыкны үлчәр өчен
Үлчәү бар,
Олылыкны үлчәр өчен
Үлчәү юк.
Шуңа, ахры, кешедәге
Олылык
Ята күпчак бәяләнми,
Онтылып.

Авырлыкны үлчәр өчен
Үлчәү бар,
Сабырлыкны үлчәр өчен
Үлчәү юк.
Данланса да, мakталса да
Сабырлык,
Сабырлыкның ни даны бар
Калырлык?!

Ныклыкны үлчәр өчен дә
Үлчәү бар,
Тугрылыкны үлчәр өчен
Үлчәү юк.
Шуңа күрә бәрелеп тә
Сугылып,
Күп вакытта җанда үлә
Тугрылык.

Мәрхәмәтне үлчәргә дә
Бизмән юк,
Мәхәббәтне үлчәргә дә
Бизмән юк.
Иң-иң асыл затларның да
Алдына
Әле зурлап гөлчәчәкләр
Тезгән юк.

*1989*

## *Синең яктылык*

Шигырь дәфтәремә бер нур төшә,
Ул, ахрысы, синең яктылык.
Утырамын шигырь язарга мин,
Шушы яктылыкка тартылып.

Коена каләм шушы яктылыкта,
Әверелеп сылу аккошка.
Аккош канатыннан тамчы чәчрәп,
Күл өсләрен күмә балкышка.

Әллә нинди бер ашкыну белән
Сиңа бара җаным тартылып.
Сөю турындагы шигырьләргә
Сеңә бара синең яктылык.

*1990*

# *Алмаштырмыйм*

Алмаштырмыйм синең бер карашыңны
Гомеремнең әллә ничә таңына.
Шул караштан күпме нурлар эчәм мин,
Яктылык бик кирәк чакта җаныма.

Алмаштырмыйм синең бер елмаюны
Гомеремнең әллә ничә язына.
Синең шул бер елмаюың белән дә
Күмеләмен чын мәхәббәт язына.

Алмаштырмыйм синең шатлык яшеңне
Коеп яуган җәйләрнең яңгырына.
Мәңгелек дым бирә бер тамчы яшең
Саф мәхәббәт чәчәгенең тамырына.

Алмаштырмыйм синең бер керфегеңне
Җир шарының иң гүзәл гөлләренә.
Керфегеңә сеңгән нурлар яктысын
Саклап тотам иң кара көннәремә.

*1988*

## *Ике алма*

Шулай сеңеп калган җанга:
Ике учыңда — ике алма.
Алмаларың түп-түгәрәк,
Тора иде нур сибәләп.

Килеп кердең, түргә уздың,
Алмаларың миңа суздың.
Бер алмам — сафлыгым, дидең,
Бер алмам — яшьлегем, дидең.

Алмаларың алдым учка,
Килалмыйча тордым һушка.
Очып китәр кебек иде
Әверелеп алар кошка.

Еллар белән чаптым алга,
Ике учта — ике алма:
Берсе — бетмәс сабырлыгың,
Берсе — сүнмәс матурлыгың.

*1988*

* * *

---

Бер-беребезгә авыр сүзләр әйттек,
Сүзләр түгел, уклар атыштык.
Икебез дә хаклы идек сыман,
Нишләп әле болай ялгыштык?
Кайчандыр бит сөеп кавыштык.

Бер-беребезгә авыр сүзләр әйттек,
Ничек йөрик аны күтәреп?!
Болай да бит тормыш сынаулары
Төшеп тора безгә җитәрлек,
Дәрьяларны диңгез итәрлек.

Бер-беребезгә авыр сүзләр әйттек,
Тыелмады ник соң беребез?
Хәзер инде канлы яраларга
Ни ябарга белми йөрибез,
Алалмыйбыз сүзне кире без.

Бер-беребезгә авыр сүзләр әйттек,
Араларга ник соң җил керттек?
Без бит шулай бер-беребезне түгел,
Олы мәхәббәтне кимсеттек,
Яктылыгын җанның киметтек.

*1986*

# *Минем өчен саклагансың*

Минем өчен саклагансың сафлыгыңны,
Минем өчен саклагансың аклыгыңны:
Аклыгыңны һичбер вакыт каралтмамын,
Миңа булган өметеңне таратмамын.

Минем өчен саклагансың ялкыныңны,
Ялкыныңны — күңелеңдәге алтыныңны.
Ялкыныңны һичбер вакыт сүндермәмен,
Алтыныңа ятлардан кул тидермәмен.

Минем өчен саклагансың гөлләреңне,
Гөлләреңне, ай-йолдызлы төннәреңне.
Гөлләреңне беркемнән дә өздермәмен,
Күңелеңне үземнән һич биздермәмен.

Минем өчен саклагансың таңнарыңны,
Хисләр белән мөлдерәмә җаннарыңны.
Хисләреңнең тамчысын да түктермәмен,
Ятлардан күз яшьләреңне сөрттермәмен.

*1986*

## *Теләмим*

Йөзләремә сарылары йоксын әйдә,
Мин теләмим котылырга сагышымнан.
Сагышымның иң төбендә син ятасың,
Ничек алып ташлыйм сине
язмышымнан?

Кысыр булсын,
гел җимешсез булсын әйдә,
Хыялымны өзмим тормыш тирәгемнән.
Хыялымның иң татлысы синең турыда,
Ничек шуны өзеп атыйм йөрәгемнән?

Бассын кайгы,
чылансыннар күзләр яшьтән,
Ялкын чыкса чыксын
әйдә сулышымнан.
Хәсрәтемнең иң ачысы син, әйе, син,
Ничек алып ташлыйм сине
тормышымнан?

*1986*

* * *

Карадым да кара күзләреңә,
Колак салмый кеше сүзләренә,
Йөгердем мин сагышыма таба,
Баса-баса кайнар эзләреңә.

Шуып төште еллар иңнәремнән,
Татлы сүзләр тамды телләремнән.
Мең матурлык,
мең гүзәллек таптым
Гади генә узган көннәремнән.

Карадым да кара күзләреңә,
Диңгез күрдем мәңге йөзәремә.
Әбелхәят суы сиптеләр күк
Көзге яфрак төсле йөзләремә.

Карадым да кара күзләреңә,
Колак салмый кеше сүзләренә,
Ташландым мин
янып торган утка —
Йөрәк кенә ничек түзәр менә...

*1985*

* * *

Мин сине хыялда тудырдым:
Тәнеңне чык белән юдырдым,
Күзеңдә очкыннар булдырдым,
Иңеңә былбыллар кундырдым.

Билеңне камыштан ясадым,
Түшеңә йолдызлар кададым.
Гөлләрнең уралып үскәнен
Толымнар өчен дип сайладым.

Ап-ак ай урнашты күкрәккә,
Кояшны куйдым мин йөрәккә.
Шәфкатьне күчердем йөзеңә,
Ә чишмә тәмнәрен — сүзеңә.

Искиткеч шәп чыктың.
Булдырдым,
Хыялым кушканны тудырдым.
Тик сине күргәчтен, эшемнең
Бик җансыз,
бик ярлы, бик гади,
Бик төссез икәнен төшендем.

*1985*

* * *

Арттан килеп, минем күзләремне
Капладың да йомшак кулың белән:
— Таныйсыңмы? — диеп пышылдадың,
Муенымны назлап кулың белән.

Сулышларың килеп кагылуга
Өлгерсә дә җанга сөенеч тулып,
Кузгалырга куркып утырдым мин,
Рәхәт әсирлеккә риза булып.

Шушы көннән мин әсирең синең,
Дауламыйм да хәтта иркемне мин.
Шушы көннән томаланды күзем,
Шушы көннән күрмим беркемне мин...

Синең өчен бу бер уен булган,
Аңладым мин моны, әйе, тиздән.
Кулларыңны, ләкин кулларыңны
Алып ташлый алмыйм һаман күздән.

*1984*

## *Бер тәлгәш*

Өй янындагы миләштә
Бер тәлгәш эленеп тора.
Бәсле ботаклар аша ул
Ерактан күренеп тора.

Гүя төн буе бер гашыйк
Сөйгәнен зарыгып көткән...
Һәм миләшнең ботагына
Йөрәген элеп киткән.

*1984*

## * * *

Чаганның
        тик бер яфрагы калган
Иң очында, биек җирендә.
Көзнең аңа буе җитмәгәнме,
Онтылганмы бакча түрендә.

Өзгәләнә яфрак җил искәндә,
Яфракларга кызыга җирдәге —
Гүя сеңелләрен кияүгә биреп,
Ялгыз калган кызның йөрәге.

*1983*

## *Очрашырга тиешбез*

Салават күпереңең без
Икебез ике ягында:
Ашыгырга кирәк безгә,
Кавышырга кирәк безгә
Күперләр бар чагында.

Яшьлек — салават күпере,
Аның гомере кыска.
Ә хәзергә өстә кояш,
Күкләр нурдан тора тоташ,
Тамчылар бии учта.

Дөнья ефәк челтәр әле,
Күк белән җир кушылган.
Юл куймыйча болытларга,
Офыклардан офыкларга
Җепләр сузыйк шушыннан.

Үрлик-үрлик, кала күрмик
Мәңге юлда килеш без;
Күпернең нәкъ уртасында,
Күкнең биек ноктасында
Очрашырга тиешбез.

*1983*

## *Әйтәм, әйтәм*

Бу серемне артык яшерә алмыйм,
Аны яшерү үзе бер газап:
Утлы күмерне соң учка кысып
Саклап буламыни бик озак?!

Күңелем бакчасында алма пеште,
Өзелер дә төшәр беркөнне.
Тулып пешкән алсу алманы соң
Сабагында саклау мөмкинме?!

Ул яшь бөркет канат кагынып тора,
Яба алмыйм аны ояга.
Әйтәм, әйтәм, каеннарга әйтәм,
Әйтәм, әйтәм аккан елгага.

Әйтәм, әйтәм, бар да белсен әйдә,
Түзеп торыр чарам калмады.
Ул сер минем телләремне пешерә,
Битләремне ялкын ялмады.

Әйтәм, әйтәм, артык яшерә алмыйм,
Бар дөньяга үзем таратам:
Ишетәсезме мине, урман-кырлар,
Ишетәсезме мине, елга-сулар —
Мин яратам аны, яратам!

*1983*

# *Сиңа*

*Туган көнеңә*

Күргән саен дөнья гыйбрәтләрен,
Рәхмәтләрем сиңа арта бара.
Көн дә чагылып торган кешелегең
Күңелемне үзенә тарта бара.

Күпләр сине аңлап җиткермиләр,
Бу соң, диләр, нинди тиле йөрәк?
Сине аңлап җиту өчен дә бит
Синең биеклеккә менү кирәк.

Мине генә түгел, сөясең син
Мин табынган олы Шигъриятне,
Мин табынган эшкә табынмасаң,
Аңлар идеңмени бу йөрәкне!

Мин көнләшмим ләкин,
миннән ныграк
Шигъриятне сөйсәң син әгәр дә.
Гел унсигез яшьлек егет булып
Килермен мин сиңа шигырьләрдә.

*1983*

## *Шушы ышаныч*

Синең барлыгыңа,
Синең берлегеңә
Ышана барам ныграк.
Шикләнүләремне,
Икеләнүләремне
Кудым инде ерак.

Шушы ышанычым
Саклап бара мине
Түбән төшүләрдән,
Һәм күтәрә өскә
Ышанычын җуйган
Мескен кешеләрдән.

Шул ышаныч белән,
Шул тынычлык белән
Горур минем җаным.
Кыю басам җиргә,
Адашмыймын бер дә,
Кая гына бармыйм.

Шул ышаныч булгач,
Эчтән шикне кугач,
Яшәүләре рәхәт.
Әйе, син бар җирдә,
Әйе, син бер җирдә —
Илаһи мәхәббәт.

*1981*

* * *

Күптән инде әйтешкән юк
«Яратам» дигән сүзне.
Бу сүзнең матурлыгын без
Онтып бетермибезме?

Ә бит әле кайчан гына
Бу татлы сүзнең көче
Бәхеттән елата иде,
Яктырта иде кичне.

Бу сүзнең канатларында
Күкләргә менә идек.
Еш әйтсәк тә, аның бик нык
Кадерен белә идек.

Бәлки, бу сүз күп тапкырлар
Үлемнән саклагандыр.
Хисләрне яңарткандыр да
Җаннарны сафлагандыр.

Онытмыйк,
                    дустым, онытмыйк
Без бу сүзнең барлыгын.
Аннан башка дөньяларның
Ярлылыгын, тарлыгын
Онытмыйк!

*1981*

## *Сөюче һәм сөелүчеләргә*

Сез бәхетле,
дөнья сезгә керсез һәм саф,
Юктан гына шатланасыз, сөенәсез.
Җилләр йомшак, таңнар якты,
офыклар киң —
Чөнки бит сез сөясез һәм сөеләсез.

Күктә мәңге йолдызлар да
сүнмәс кебек,
Өстегезгә болытлар да килмәс кебек.
Барсына да кул селтисез дә көләсез —
Чөнки сез бит сөясез һәм сөеләсез.

Ышанмыйсыз җирдә явызлык барына,
Ышанмыйсыз җирдә ялгызлык барына.
Җирдә бар да гүзәл, диеп белдерәсез —
Чөнки бит сез сөясез һәм сөеләсез.

Ышанмагыз әйдә, мәңге ышанмагыз,
Мәкер, ялган безнең өчен түгел,
диегез.
Юлдаш итеп матурлыкка ышанычны,
Гомер буе сөегез һәм сөелегез.

*1981*

## *Беләсе иде*

Яшьлеккә кыю булу хас,
Мин дә бик кыю идем.
Синең күзләреңә генә
Карарга кыймый идем.

Яшьлеккә батыр булу хас,
Яшеннәр тота идем.
Сине рәнҗетүдән генә
Мин бик тә курка идем.

Яшьлеккә үткен караш хас,
Күз йомып йөрми идем.
Ләкин синнән башкаларны
Ялгыш та күрми идем.

Яшьлеккә сабырсызлык хас,
Сабырсыз иде җаным.
Әмма капка төбегездә
Аз таңнар аттырмадым.

Яшьлеккә тилелекләр хас,
Мин дә бик тиле идем.
Ләкин яшьлек җимешенә
Кагылмый, тими идем.

Үткәннәргә син дә кайчак
Әйләнеп карыйсыңмы?
Рәхмәт әйтәсеңме миңа,
Әллә соң каргыйсыңмы?

*1980*

* * *

Узган көннәр — өзгән гөлләр икән.
Терелтмәкче булып шул гөлләрне,
Очрашулар, күрешүләр көтеп,
Ярсыттык без тыныч күңелләрне.

Очраштык та чиксез гаҗәпләндек,
Чынбарлыкның карап күзләренә.
Хыялларның хәрабәсе генә
Өелеп калган яшьлек эзләрендә.

Бик озаклап нидер эзләдек без
Шушы хәрабәләр арасыннан —
Тарихчылар хәбәр эзләгәндәй
Үткәннәрнең җимерек каласыннан.

Бу очрашу юкка булды, ахры,
Элеккечә калсын иде бар да.
Мин Таһирың, ә син Зөһрәм булып
Яшәр идек һаман хыялларда.

*1979*

## *Беркем сизмәде*

«Тактага язма
Минем исемне,
Укытучы сизәр
Сөю хисеңне».
Тыңладым сине
Мин күндәм генә.
Исемеңне әйттем
Күңелдән генә.
«Клубта берүк
Утырма янга.
Кешеләр үртәп
Тиярләр җанга».
Тыңладым сүзсез
Сине тагын да.
Утырдым башка
Кызлар янында.
«Җырлап үтмә син
Өебез турыннан.
Гыйшкыңны әнкәй
Сизәр җырыңнан».
Юк, җырламадым
Сезнең урамда,
Мәхәббәтемнән
Шашар булсам да.
Үтте яшьлекнең
Язы-көзләре.
Безнең сөюне
Беркем сизмәде.

*1978*

* * *

Урам буйлап атлап барам,
Учта бер йомарлам кар.
Үз учымда эрегәнче,
Шуны ыргытасым бар.

Кем куенына атыйм аны,
Кем курыкмый суыктан?
Сак булыгыз, иркә кызлар,
Сак булыгыз — ыргытам.

Ыргыттым — сиңа тиде.
Куеның ачык иде.
Шунда эреде карым —
Булдың гомерлек ярым.

*1978*

* * *

Беребез кызып китүчән,
Беребез сабыр, тыныч;
Беребез корыч калкан да,
Беребез булат кылыч.

Тормыш безнең алдыбызга
Куйган катлаулы бурыч;
Калканы да ватылмасын,
Һәм дә сынмасын кылыч.

*1974*

* * *

Әйттең миңа уңганым, дип,
Һәм ышандырдың шуңа;
Чынлап та,
        шул көннән башлап,
Эшләрем китте уңга.

Әйттең миңа акыллым, дип,
Әллә чын, әллә уйнап;
Акыллырак итеп сизәм
Үземне хәзер чынлап.

Әйттең миңа матурым, дип,
Сокланып күзләремә,
Сибелде күк таң нурлары
Шул вакыт йөзләремә.

Үзгәрдем, сизәм үзем дә,
Канатлар үсте хәтта.
Мең рәхмәт шулай үзгәрткән
Тылсымчы мәхәббәткә.

*1977*

* * *

---

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда чәчәкләр бәйләме,
Каядыр ашыккан җиреңнән
Карыйсың әйләнеп-әйләнеп.

Карыйсың, кулларың изисең,
Юлларга чәчәкләр коела.
Йөзеңдә нindидер үпкәләү
Һәм сагыш бар сыман тоела.

Нәрсәдер әйтәсең каерылып,
Тик җилләр өзгәли сүзеңне.
Тирбәлә һавада бер аваз:
«Без инде...
            Без инде...
                        Без инде...»

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда яшьлекнең гөлләре.
Гөлеңне йолкыйлар кулыңнан
Тормышның аяусыз җилләре.

*1977*

* * *

Очрашырга чакыр мине,
Көтә-көтә таң аттыр;
Мин килмәм, бәлки, яныңа,
Ә син барыбер чакыр.

Чәчәкләр алып кил миңа,
Юлларымны гөл иттер;
Мин алмам, бәлки, чәчәгең,
Ә син барыбер китер.

Еракка китсәм, хатлар яз
Күп итеп, кайнар итеп;
Яшә син, минем хәбәрне
Атналар, айлар көтеп.

Ачулан миңа, үпкәлә,
Тынгылык бирмә бер дә.
Тик ышандыр гына мине
Сөю барлыкка җирдә.

*1977*

* * *

— Әбәү, мәхәббәтсез! — диден,
Үзен сөеп карадын.
Күзләренә карадым да,
Мин киресен аңладым.

— Башкаларны сөй,— диден син,
Әйттен: «Артымнан йөрмә!»
Аңладым сине башкача:
— Мәнге ятларга бирмә!

— Турыбыздан үтмә,— диден.
Мин: — Үт,— диеп аңладым.
— Көтмә,— диден.
Ә мин: — Көт,— дип,
Үз-үземне алдадым.

Яшьлек теле — сөю теле,
Сөйли шулай киресен.
Сөйләшсәләр дә киресен,
Аңлый йөрәк бер-берсен.

*1974*

## *Син бар*

Дусларым күп, саный китсәң,
Җитмәс бармак-куллар;
Дуслар дуслар инде алар,
Ярый әле син бар.

Кешеләр килә дә китә,
Эчтә кала моң-зар.
Моң-зарларны сөйләр өчен
Ярый әле син бар.

Рәнҗетеп тә куям кайчак,
Гөнаһсыз соң кем бар?!
Көн дә, төн дә яннарымда
Ярый әле син бар.

*1973*

## * * *

Әллә күктә яшен гөлт итте,
Әллә кызлар кашын сикертте —
Өлгермәдем һични аңларга...
Ялкын капты зәңгәр таңнарга.

Әллә көзләр артык тиз җитте,
Әллә яшьлек артык тиз үтте —
Утын күрдем — җылысын сизмәдем,
Болынын күрдем — гөлен өзмәдем.

*1972*

* * *

Ярларда ялгыз калдырмам,
Син көймә, мин җил булсам,
Упкыннан йолып алырмын,
Хисләремә тиң булсаң.

Кырларда күрми калдырмам,
Мин тургай, син гөл булсаң.
Җырларда мактап җырлармын,
Сөюемә тиң булсаң.

*1972*

* * *

Әгәр йөрәгең таш булса,
Хисләрем булыр тамчы.
Тамармын да тамармын мин,
Таш тишелеп чыкканчы.
Әгәр йөрәгең боз булса,
Ут булырмын, тор белеп.
Янармын да янармын мин,
Бозың беткәнче эреп.
Йөрәгең кыя-тау булса,
Ургырмын чишмә булып.
Агармын да агармын мин,
Тау төшкәнче убылып.

*1962*

## Үпкә

Хәтер, үпкә саклыйм сиңа:
Никадәрле гүзәлләрне,
Сылуларны, чибәрләрне,
Мине өзелеп сөйгәннәрне
онытkансың.
Хәтердә юк исемнәре,
Хәтердә юк карашлары,
Онытылган тавышлары,
Онытылган сагышлары.
Хәтер, үпкә саклыйм сиңа.
Бер кешене,
Онытырга тиешлене,
Мине һич тә сөймәүчене,
Яман итеп сөйләүчене
онытмыйсың.
Гел телемдә исемнәре,
Күз алдымда карашлары,
Колагымда тавышлары,
Йөрәгемдә сагышлары.

*1968*

* * *

Гөнаһсызга кәефең кырсам,
Кирәксез сүз ычкындырсам,
Кичерә беләсең син.
Урынсызга шапырынсам,
Һәр мактауга авыз ерсам,
«Пешерә» беләсең син.

Эчендә янса да утлар,
Килеп керсә минем дуслар,
Елмая беләсең син.
Сагыш басса иңнәреңне,
Көйләп моңлы көйләреңне,
Моңая беләсең син.

Күреп эштә уңганнарны,
Бар яктан да булганнарны,
Көнләшә беләсең син.
Хакыйкатькә туры карап,
Гаделлекне генә яклап,
Сөйләшә беләсең син.

*1967*

# *Булды инде*

Булды инде яшь чагында
Яныпяратучылар.
Булды яратмый гына да
Үзенә каратучылар.

Булды...
Сиздерми генә кесәгә
Кулъяулык салучылар.
Урамнан җырлап үткәндә,
Уф, диеп калучылар.

Яшьлек яшен кебек узды,
Кабынып сүнде генә.
Кулъяулыклар кесәләрдән
Күчте сандык төбенә.

Еллар үткәч, актарамын
Шул кызларның бүләген.
Берсе дә яулыкка төреп
Бирмәгән шул йөрәген.

*1964*

# *Мин*

*Мин – халкымның баласы,*
*Баласы – күз карасы.*
*Халык күңеленә таба*
*Барасы да барасы...*

## *Матур күренеш*

Яшен сукты очып барган кошны,
Кош гәүдәсе меңгә теленде.
Каурыйлары, ап-ак каурыйлары
Йолдыз булып күккә эленде.

Карап тордым мин бу күренешкә,
Кайнар хисләремә буылып.
Күзләремнән яшьләр тәгәрәде,
Кала алмадым һич тыелып.

Юк, кызганыч түгел иде бу кош,
Юл өзелде гүзәл очышта.
Никадәрле биек очсалар да,
Мондый бәхет тими һәр кошка.

Озак тордым яшеннәргә карап,
Уйлар өермәсе эчендә.
Миңа нидер сөйләмәкче булып,
Кошлар бөтерелде өстемдә.

Еллар үткәчтен дә онытылмас
Шундый матур күренеш иде бу!
Үлем түгел, онытылу түгел,
Мәңгелеккә күчеш иде бу.

*1999*

## *Кара сакал*

Эзәрлекли мине гомерем буе
Кан дошманым — кара сакалым.
Адаштырып аны калдырыйм дип,
Кая гына чыгып чапмадым!

Сикереп төштем ярсу дәрьяларга,
Дулкыннарда күпме чайкалдым.
Тик үземнән алда яр өстенә
Чыгып басты кара сакалым.

Үз-үземне упкыннарга аттым,
Сакалымны бәйләп тирәккә.
Тирәк чыкты тамырыннан кубып,
Кара сакал калды аяктә.

Утка кердем, үзем пешеп беттем,
Тыннарымны ялкын ялмады.
Кара сакал — кара кисәү булып
Ята бирде, утта янмады.

Чыгып чаптым, йокыларым өзеп,
Җеннәр адашырлык төннәрдә.
Тик сакалым мине эзләп табып,
Килеп уралды гел билләргә.

Булды, булды минем тормышымда
Бәхеттән баш җуяр чакларым.
Шатлыкларым җанны күккә тартты,
Түбән өстерәде сакалым.

*1999*

* * *

Түзә алмый пычрагына
Бу дөньяның,
Ак каенга асылынды
Ак хыялым.

Җимерәм дип явызлыкның
Дивар ташын,
Ярылыр, ахры,
                беркөн килеп,
Минем башым.

*1999*

## *Картлык*

Кулларымнан эшем төшсә,
Туктап калсам арып —
Килеп атланырга тора
Иңнәремә картлык.

Уйнамасам һәм көлмәсәм,
Йөздә сүнсә шатлык —
Ишегемне кага башлый
Чытык йөзле картлык.

Чыгам юлга, барам алга
Көчне җыеп актык.
Карыйм үзем як-ягыма —
Күренмиме картлык?!

*1999*

## *Хәтер аланнары*

Хәтер аланымда күләгә юк,
Хәтер аланнарым якты әле.
Ул аланда пешкән җимешләрем
Һаман сусыл, һаман татлы әле.

Анда йөри ябь-яшь чибәр кызлар,
Челтерәтеп матур чиләкләрен.
Каптыралар минем үземә дә
Чиләкләргә җыйган җиләкләрен.

Ул аланда гөлләр шау чәчәктә,
Матурлыктан күзләр камашырлык.
Кызлар күзе кебек чишмәләрнең
Карашыннан башлар адашырлык.

Аланнарда тамган яшьләремнең
Ачылыгы күчкән баланнарга.
Яшьлегемнең яшеннәрдән алган
Катылыгы калган чаганнарда.

Сөйгән ярлар биргән кулъяулыктай
Кадерле сез, хәтер аланнарым.
Ул аланда кулъяулыгын болгап
Басып тора кавышалмаган ярым.

Хәтер аланымда күләгә юк,
Хәтер аланнарым якты әле.
Күңелемә күчкән хатирәләр
Тәүге үбешү кебек татлы әле.

*1999*

# *Яралы кош тавышы чыгарып*

Бар дөньямны онытып шигырь язам,
Җирләр белән күкләр кушылган.
Әллә нинди сихри сайрар кошлар
Очып чыга каләм очыннан.

Йә чабышып атлар килеп керә
Язып яткан шигырьләремә.
Йөгән кидерергә тырышып карыйм
Атларның иң өлгерләренә.

Ләкин атлар кешни-кешни кача,
Көлгән кебек миннән кычкырып.
Болытларга менеп китә алар,
Тоягыннан яшен очырып.

Ә күкләргә менеп җиткәч кенә
Әйләнәләр ап-ак кошларга.
Атыла уйлар,
Шушы кошлар белән
Иркен күктә ярышып очарга.

Барам ярсу атлар артыннан мин,
Томан сара керфек-күзләрне.
Арып егылам.
Күрәм — ак кәгазьдә
Ярылып ята тояк эзләре.
Гаҗәпләнеп карыйм бу эзләргә:
Кайда хыял, кайда чынбарлык?
Каләм төшеп китә кулларымнан,
Яралы кош тавышы чыгарып.

*1999*

## *Күңелемдә ныгый шул нәрсә*

Таусыз якта туган кешеләргә
Мин кызганып карыйм нигәдер.
Мондый уйлар минем күңелемә
Белмим инде, каян киләдер.
Гел иелеп йөргән башлар күрсәм,
Йә очратсам мескен йөзләрне;
Үзләреннән түбән булса әгәр
Кеше турындагы сүзләре;
Хыяллары, кылган гамәлләре
Булса әгәр эттән тәбәнәк;
Һәрбер түмгәккә дә тау дип карап,
Алларында йөрсә мәрәләп —
Уйлап куям: бу бәндәләр бер дә
Тау күрмәгән, димәк, үскәндә.
Йөгермәгән, тотам-тотам, диеп,
Кояш таудан-тауга күчкәндә.
Сокланмаган күреп бер тапкыр да
Бөркетләрнең кыя-тәхетен.
Татымаган, егылып төшә-төшә,
Тауга менүләрнең бәхетен.
Яшен ташын тотып карамаган
Учларына кайнар чагында.
Тумаган ул җиргә кабат-кабат,
Кайный-кайный таңнар карнында.
Торган саен минем күңелемдә
Үсә, ныгый бара бер нәрсә:
Горур була алмый икән кеше,
Йөрәгендә таулар йөртмәсә.

*1999*

* * *

Йөрәгемне вак-вак кисәкләргә
Турадым да аттым күк йөзенә.
Йолдыз булып янып төште алар
Мәхәббәтнең шаулы диңгезенә.

Әй ярсыды диңгез, әй ярсыды,
Дөрләп-дөрләп янды дулкыннары.
Ул диңгезнең кайнар комнарында
Кемнәр генә ятып кызынмады.

Ә кемнәрдер энҗе-мәрҗәннәрен
Җыеп йөрде, төпкә чумып-чумып.
Янып төшкән йолдыз кисәкләре
Әверелгән иде энҗе булып.

Ул диңгездә һаман байлыклар күп,
Ярсуы да әле басылмаган.
Маҗаралар эзләүчеләр өчен
Утраулары да бар ачылмаган.

Дулкыннары яна һаман дөрләп,
Күкнең йөзен ялый ялкын теле.
Кояшның иң кайнар ноктасында
Чәчәк атып ята сөю гөле.

*1999*

## *Кайсы зуррак*

Дөньяның чите кайда соң,
Кем белә дөнья читен?
Шашкын күңелемне басарга
Мин дә бер шунда китим.

Бәлки, иң матур хыяллар
Болытлар белән бергә
Киткәндер дөнья читенә
Су булып түгелергә.

Бәлки, өзелгән өметләр
Офыкка таралгандыр,
Шулардан дөнья читендә
Тау-ташлар яралгандыр.

Шундадыр, бәлки, яшьлекнең
Югалган гүзәл язы.
Үзе китсә дә,
Тауларда
Калгандыр кайтавазы.

Китим дә дөнья читенә,
Үтеп мәгарәләрен —
Күрим якты уйларымның
Ватык хәрабәләрен.

Чагыштырыйм: кайсы зуррак,
Кылган гамәлләремме?
Әллә очышта югалган
Хыял, моң, гамьнәремме?

*1999*

## *Соңгы яшь тә кипкән инде*

Кемдер морза нәселеннән,
Кем — мулла нәселеннән.
Мин үзем бар эшне белгән
Ярулла нәселеннән.
        Итек баскан, тула баскан,
        Йон кайнаган казанда.
        Киез эшләпәләр сугып
        Дан тоткан ул заманда.
Сабан сөргән, иген иккән,
Абзарда өч ат тоткан.
Эшләгән ул ал-ял белми,
Ялкаулыклар ят булган.
        Ташны да бик яраткан ул,
        Койма, йортлар таш булган.
        Үзе таштай булгангамы,
        Кушамат — Чаташ булган.
Таштан салынган йорт-нигез
Таралмас дип белгәндер.
Тамырларым мәңгелек, дип,
Тынычланып үлгәндер.
        Тик тормышның мәрхәмәтсез
        Һәм аяусыз җилләре
        Йолкып атты тамыры белән
        Хәтта бу таш өйләрне.
Черек йорт кына утыра
Бабамнар нигезендә.
Соңгы яшь тә кипкән инде
Тәрәзәләр күзендә.

*1999*

## *Көзге мизгел*

Көзнең була яздан матур чагы,
Кояш тула кереп күзләргә.
Бетте инде, бар да үтте, диеп,
Өметләрне нигә өзәргә?

Үрмәкүчләр кояш нурларына
Өмет җебен сузган, күр әнә.
Ул җепләрдә, гамьсез бала кебек,
Алсу күбәләкләр тирбәлә.

Очар кошлар инде китсәләр дә,
Туган якларыннан моң алып,
Аларның да һавадагы юлы
Агачларга калган уралып.

Җәйләр үзенең төсен калдырганмы —
Болытларга тулган кызыллык.
Кызыл болытларга сузылып ятып,
Бер аласы килә кызынып.

Ятам карап, ә өстемдә минем
Күкнең гүзәл чуар юрганы.
Йөрәгемдә уйлар өермәсе,
Җирдә сары яфрак бураны.

*1999*

## *Сорау белән җавап арасы*

«Нишләргә соң?» дигән сорауларны
Куеп тора тормыш гел алга.
Бәгырь учагында бәргәләнеп,
Шул сораулар көн вә төн яна.

Бер сорауга җавап таптым дисәң,
Икенчесе туа сорауның.
Яңа сорауларга җавап эзләп,
Мең кат урыйм уйлар урманын.

Кайчагында акыл арый хәтта,
Билгесезлек буа тыныңны.
Тик сорауга җавап тапмый торып
Дәвам итеп булмый юлыңны.

Бер сораудан бер сорауга яшим,
Белмим башка яшәү чарасын.
Гомерем дә минем нибарысы —
Сорау белән җавап арасы.

*1999*

## *Гел сакта*

Күзләремнең үткенлеге бетте,
Врач әйтә: күзлек кирәк, ди.
Ярый әле күңел күзем үткен,
Анысына күзлек кирәкми.

Аерамын әле бар төсләрне,
Картаюны белми ул күзем.
Аның белән төнлә кояш күрәм,
Йолдыз күрә алам көндезен.

Ә бит кайчак яхшы белән яман
Ташып чыга бер үк йөрәктән.
Аерыр өчен мең кат үткәрәсең
Намус дигән нечкә иләктән.

Дөнья, дөнья! Әй мәкерле дөнья!
Батмас өчен синдә гөнаһка,
Маңгай күзем йомык чакларда да,
Күңел күзем тора гел сакта.

*1999*

## *Бар әле, бар*

Башларымны түбән иелүдән
Саклап тора бары горурлыгым.
Горурлыгым әгәр ташламаса,
Бар әле, бар җирдә торырлыгым.

Күз яшемнән энҗе-мәрҗән ясап,
Йолдызларга чөя алам әле.
Ләйләләрне Мәҗнүннәреннән дә
Ныграк итеп сөя алам әле.

Бәгырь ташларымны алмаз итеп
Куя алам йөзек кашларына.
Яралардан тамган ал каннардан
Гөл үстерәм тауның башларында.

Ак болытлар булып агылып тора
Җанны ярып чыккан
җырым-моңым.
Җырым-моңым әгәр ташламаса,
Бар әле, бар җирдә торырлыгым.

Бар әле бер яшеннәргә кушылып,
Очкын булып кинәт чәчрәрлегем.
Очкын булып чәчри алам икән,
Бар әле, бар, димәк, яшәрлегем.

*1999*

* * *

Хозурланып карап ята идем,
Алмагачка кунды бер ак кош.
Танымадым, нинди кош булгандыр,
Матур иде ләкин бу ят кош.

Өлгермәдем хәтта сокланырга,
Очты-китте минем ак кошым.
Күреп калдым бары җилфер-җилфер
Зәңгәр күктә канат кагышын.

Күңелемә бер салкынлык кына
Бәрелеп китте шушы ят коштан.
Юмарт көзең инде үтте, диеп,
Хәбәр килде гүя ак кыштан.

*1999*

## *Үпкәләмим*

Рәнҗемим һәм үпкәләмим һич кенә
Күрмиләр, дип тәнкыйтьчеләр,
түрәләр.
Шулай була: зур агачны күрмичә,
Ботактагы бер чыпчыкны күрәләр.

Җил исүгә, чыпчык очар да китәр,
Эз дә калмас ул утырган ботакта.
Агач үсәр давылларга бил бирми,
Горур гына караш ташлап як-якка.

*1999*

## *Кояш баеганда*

Әкрен генә кояш баеп килә,
Бар дөньяда серле кызыллык.
Шәрә башлы тауның өсләрендә
Ак болытлар ята кызынып.

Яфракларга шәфәкъ уты капкан,
Урман-кырлар яна шул утта.
Сайрар кошлар, сайравыннан туктап,
Хәйран калып утыра тынлыкта.

Җил дә исми. Ул да, чалкан ятып,
Кояш баеганны күзәтә.
Әй бу кичләр, әй бу хозурлыклар —
Күңелләрне әллә нишләтә.

Уйлар китә ерак-еракларга,
Сокланудан тыннар кысыла.
Урап калдырасы килә гомер җебен
Биек агачларның очына.

Әкрен генә кояш баеп килә,
Җирдә, күктә сихри кызыллык.
Әллә нигә кояш баешына
Ешрак карыйм хәзер кызыгып.

*1999*

## *Ак кәгазьдә – ак уйлар*

Төшмә, каләм, кулларымнан,
Төшмә соңгы көнгәчә.
Син әйтәсен беркем әйтмәс,
Әйтер сүзең әйт, яшә.

Үз халкыңның күңеленә
Иң яраклы ачкыч бул:
Биеклеккә менәр өчен
Ышанычлы баскыч бул.

Җаннан җанга сукмаклар суз,
Кушылсын моңнар моңга.
Гашыйкларны очраштыр да,
Ашык син тагын юлга.

Гаделлекне иман ит син,
Хакыйкатьне кыйблаң ит.
Синең бер тамчы караңа
Тулы кояш сыйган бит.

Төшмә, каләм, кулларымнан,
Сызыйк гел яңа юллар.
Ак чәчәкләр булып калсын
Ак кәгазьдә — ак уйлар.

*1999*

## *Мин юклыкны, бәлки, беркем сизмәс*

Сабыр канатымның каурыйларын
Берәм-берәм җилләр йолкып бара.
Ул каурыйлар, көзге яфрак булып,
Үткән юлларыма коелып кала.

Килер бер көн: каурыйларым бетәр,
Канатларым калыр шәрәләнеп.
Очармын да тирән упкыннарга,
Җан бирермен шунда бәргәләнеп.

Якты кояш миңа ясин чыгар,
Җилләр күмәр җиргә җәсәдемне.
Кеше хәтере — рәшә, тиз таралыр,
Онытырлар җирдә яшәвемне.

Онтылулар ләкин һич куркытмый,
Һәрнәрсәнең була бер азагы.
Мин юклыкны, бәлки,
беркем сизмәс,
Кимер бары җирнең бер газабы.

*1999*

## *Кем матурлар дөньяны?*

Йөрәгем — кош оясы,
Оянын юк хуҗасы.
Әллә инде бер агачка
Аны элеп куясы?!

Бәлки, күрерләр иде.
Күргәч — керерләр иде.
Эченә ак мамык түшәп,
Җылы өрерләр иде.

Агач шатланыр иде,
Оя җанланыр иде.
Яфраклардан яфракларга
Җырлар таралыр иде.

Эзлим әле ояны,
Ник буш тотам мин аны?
Кем матурлар, без үзебез
Кайгыртмасак дөньяны?

*1999*

## *Телем-телем телмәс иде*

Салкыннарда өши-өши,
Кояшларда яна-яна
Үскән саен агачларның
Кайрылары катылана.

Их, нигә соң йөрәкләрнең
Булмый икән кайрылары? —
Телем-телем телмәс иде
Пычак булып кайгылары.

*1999*

## * * *

Язам-сызам, язам-сызам,
Сызылганы күбрәк тә.
Язганнары — кәгаземдә,
Сызганнары — йөрәктә.

Язам-сызам, язам-сызам,
Бар эшем шуннан тора.
Гомерем шигырьдән
                    шигырьгә
Сузылган юлдан тора.

Язам-сызам, язам-сызам,
Күбрәктер сызылганы.
Язсам да, сызсам да, гомер
Заяга узылмады.

*1999*

## *Иске машина*

Таралырга торган машина мин,
Искергәннәр инде детальләр.
Ничек йөри бу машина диеп,
Карап кала күргән-белгәннәр.

Моторының күптән рәте беткән,
Җүнләп тотмый хәтта тормозы.
Руле борыла бары тик шул якка —
Кайда күренә берәр хур кызы.

Калтыр-колтыр килеп эшләсә дә,
Көн-төн сүнми аның моторы.
Сүндерденңме, кабыза алмый аны
Җирнең хәтта иң шәп шоферы.

Искерсә дә, тәмам таушалса да,
Ышанычлы иске машина,
Көнләшмичә «Волга»,
«Вольва»лардан
Үз юлыннан алга ашыга.

Кемнәрнедер туктап утырта ул,
Йә төшерә туктап берәрсен.
Соңгы пассажиры беткәч кенә
Сүнеп калырдыр ул, күрәсең.

*1999*

# *Яктылык*

Күңелемдә ниндидер бер яктылык,
Бетми дә ул, кимеми дә өләшеп.
Килегез, кил, күпме кирәк алыгыз,
Читтән генә карамагыз көнләшеп.

Кышын аны карлар итеп таратам,
Ул аклыктан күзләрегез камашсын.
Гашыйк җаннар чыгып
күңелем кырына,
Шул яктылык буранында адашсын.

Сибәм җәен болындагы гөлләргә,
Нурлар белән көнне үрәм көннәргә.
Илтегез, дип,
аны күбрәк җирләргә —
Йөрәгемне җилгәрәмен җилләргә.

Бетми дә һич, кимеми дә өләшеп,
Күңелемдә ниндидер бер яктылык.
Йөгерәмен офыклардан офыкка,
Күкрәгемнән кояш чыга атылып.

*1999*

# *Алар да бит һәрчак очышта*

Казаннарга кайтсам, Баулым якын,
Баулыларга кайтсам — Казаным.
Туган якларымда түл җыям да
Казаныма кайтып язамын.

Әрле-бирле киләп сарып йөрим,
Юл газабын иңгә күтәреп.
Арып-талып юлда йөрсәм генә
Җаннарымны басмый күгәрек.

Туган ягым сыңар канат булса,
Икенчесе аның — Казаным.
Казанымның —
                    шигъри башкаламның
Урамнары саен яз аның.

Үпкәләмә миңа, туган ягым,
Казанымны мактап язганга.
Һәр шагыйрьнең туган ягы икәү —
Берсе авылда, берсе Казанда.

Һаваларда оча алсын өчен,
Ике канат кирәк һәр кошка.
Шагыйрьләр дә кошлар нәселеннән,
Алар да бит һәрчак очышта.

*1999*

## *Бөтенләйгә ташлап китмәдең*

Кайгы-хәсрәтләрем күп булса да,
Мин бәхетсез түгел, әлбәттә.
Бәхетем минем килеп-китеп йөри,
Кереп төрле-төрле сурәткә.

Йә килә ул кышкы салкыннарда
Аллы-гөлле чәчәк төсендә.
Яки туа, ярсу шигырь булып,
Хисләр өермәсе эчендә.

Йә килә ул яңа бер дус булып,
Ә яңа дус — яңа бер дөнья.
Йә уятып якты өметләрне,
Алып чыгып китә ул юлга.

Килеп керә кайчак ишегең ачып,
Күзләр камашырлык кыз булып.
Куя шунда шатлык-сөенечтән
Йөрәк майкайларың сызылып.

Алма булып учларыңа тама,
Ялкын булып ялый битләрне.
Йә атылган йолдыз нуры булып,
Тоташтыра җир һәм күкләрне.

Бетте инде, бусы соңгысыдыр,
Бәхет килмәс, дисең, яңадан.

Ә ул кабат, утлы чәчәк булып,
Калкып чыга канлы ярадан.

Кайгы-хәсрәтләрем күп булса да,
Шөкер, бәхет үги итмәде.
Сирәгрәк кунак булса да, ул
Бөтенләйгә ташлап китмәде.

*1999*

## *Егылыр ул*

Тагын бер алмасын өзеп
Гомер алмагачымның,
Үтеп китте иске елым,
Күңелгә салып моңын.

Алмаларын берәм-берәм
Чүпләп бетергәч еллар —
Болыт ишелеп төшәр дә
Алмагачымны егар.

Тик уфтанмас алмагачым
Гомернең үткәненә —
Егылыр ул, башын салып,
Чәчәкләр түтәленә.

*1999*

## *Егерме яшьлек булып*

Өч кыз утыра каршымда,
Әй матурлар, әй шәпләр!
Кайсына күз ташласаң да,
Әллә нишли йөрәкләр.

Менә монсы Эльмира,
Елмаюы ни тора!
Күзләренең яктысыннан
Күңелләрең яктыра.

Резидәсе, әй, нурлы,
Уң битендә чокыры.
Шул чокырга күптән инде
Йөрәк кереп утырды.

Бусы Айгөл-каракаш,
Карый керфек аралаш.
Тфү, тфү, күзем тияр,
Туры карау ярамас.

Алар өчәү, мин берәү,
Кайгырмыйм ләкин һич тә.
Бүләм алтмыш яшемне
Төп-төгәл итеп өчкә.

Мондый чибәр кызларны
Беркемгә дә бирдем юк.
Озатам өчесен дә
Егерме яшьлек булып.

*1998*

# *Киек Каз Юлларыннан*

Киек казларга ияреп,
Эшне ташлап кулымнан,
Чыгып китәсе килә бер
Киек Казлар Юлыннан.

Зөһрә кызның чиләгеннән
Эчәр идем су алып.
Фәрештәләр мәҗлесендә
Йөрер идем сыйланып.

Китәр идем ерак-ерак,
Кызлар йолдызлыгына.
Гашыйк булыр идем шунда
Иң чибәр бер кызына.

Чүмеч йолдызын тотырып,
Шатлыклар эчәр идем.
Бик ошаса, мәңгелеккә
Мин күккә күчәр идем.

*1998*

* * *

Мине хәзер, никтер, күкләр тарта,
Күктә әллә күңеллерәкме?
Фәрештәләр, канатларын кагып,
Җилкендереп тора йөрәкне.

Нинди балкыш ялт-йолт итә анда,
Күз кысамы әллә берәрсе?
Күз кысуы шундый якты булгач,
Нинди икән аның иясе?

Фәрештәләр калфагыдыр, бәлки,
Йолдыз дигәннәре — кем белә?
Энҗе-мәрҗән калфаклардан гына
Шундый йомшак нурлар бөркелә.

Җир кызлары, рәнҗемәгез миңа,
Хушлашмыйча китсәм беркөнне.
Күптән инде мине күкләр чакыра,
Биеклекләр тарта күңелне.

*1998*

## *Йокысыз сәгатьләр*

Йә, нихәл, карак төн,
Килдеңме кунарга,
Әллә соң килдеңме
Йокымны урларга?

Соңардың шул инде
Бичара, карак төн,
Мин инде йокымны
Күптәннән югалттым.

Бәлки, ул киткәндер
Сугышка, фронтка —
Әтигә ияреп
Кергәндер ул утка.

Туң җирдә яткандыр,
Суларга баткандыр.
Ә кайтыр юлларын
Карурман япкандыр.

Кем белә: бәлки, ул
Югалган язларда?
Ә бәлки, беренче
Шигырьне язганда?!

Үзем дә белмимен,
Ул кайда калгандыр.
Бәлки, ул мәхәббәт
Утында янгандыр.

Ә бәлки, ачлыкның
Тозлы күз яшендә
Кинәт юк булгандыр,
Әверелеп яшенгә.

Югалттым мин аны
Бик иртә — гомергә,
Саулыгым белән ул
Калдымы чит җирдә?!

Җилбәзәк берәр кыз
Алдымы шаярып?
Онытып йөриме
Бирергә кайтарып.

Йокысыз калырга
Булды шул сәбәпләр.
Санасаң — бер гомер
Йокысыз сәгатьләр,
Тынгысыз сәгатьләр.

*1998*

## *Гомер үтә тора*

Килә тора кошлар, китә тора,
Йөрәгемне оя итә тора.
Һәрбер коштан берәр җылы кала,
Һәрбер кошның берәр җыры кала.

Килә тора кошлар, китә тора,
Күзләремне язлар итә тора.
Алда әле яңа язлар бар, дип
Ымсындырып гомер үтә тора.

*1998*

## *Рәхмәт*

Рәхмәт сиңа, кайнарлыгым!
Син булмасаң йөрәгемдә —
Ятар идем өйләремдә,
Чыкмас идем авыр юлга,
Эшләр тотмас идем кулга.
Булмас диеп куркыр идем,
Үз җанымны йолкыр идем.

Рәхмәт сиңа, сабырлыгым!
Син булмасаң йөрәгемдә —
Кызыксам да гөлләренә,
Бирешеп тормыш җилләренә,
Менә алмый үрләренә,
Җитә алмый калыр идем
Иң бәхетле көннәремә.

*1998*

## * * *

Айкый-айкый йөргәндә дә,
Мең ел яшәп үлгәндә дә
Белеп бетерә торган түгел —
Серле син, дөнья.

Чайкый-чайкый юганда да,
Бик-бик чиста булганда да
Юып бетерә торган түгел —
Керле син, дөнья.

# *Күкләр дәшми*

Кеше нигә туа җиргә, нигә яши?
Ходай нигә акыл биргән бәндәсенә?
Уйлансын да хакыйкатьне
тапсын дипме,
Һәм төшенсен туу, яшәү мәгънәсенә?!

Ә бит акыл керә алмый бик тирәнгә,
Уй йомгагы әйләнә гел үз тирәңдә.
Үз акылы бизмәненә салып үлчи,
Үз язмышын хәл иткәндә һәрбер бәндә.

Ялгышмыймын дия-дия ялгышасың,
Кибәк булып очмас өчен тартышасың.
Уйларыңнан күк читенә күпер сузып,
Болытларның ялларына ябышасың.

Әкрен-әкрен төшенәсең һәммәсенә —
Дөньяларның ымсындыргыч хәйләсенә.
Төшенсәң дә ләкин мең-мең хәйләсенә,
Төшенеп булмый
яшәүнең чын мәгънәсенә.

Күңелемдә кабатлана гел шул сорау:
Кеше җирдә газапланып нигә яши?
Уйларымны юнәлтәмен чиксез күккә,
Ләкин күкләр сүзсез тора,
күкләр дәшми.

*1998*

# *Кайту*

Казаннардан безгә, ай-һай, ерак,
Кайта-кайта күзләр күгәрә.
Машиналар хәлсезләнеп кала
Менгән чакта биек үрләргә.

Әллә инде туган якларымнан
Артык ераклашты күңелем —
Кайтып җитә алмый калырмын күк,
Юллар дулкынына күмелеп.

Үрле юллар, таулы юллар аша
Кырык елдан артык барылган.
Йөзләремә түгел, арттан бәргән
Искән җилләр туган ягымнан.

Кайту өчен китү кирәк иде,
Кайтып булмый иде китүсез.
Җанга җыр һәм шигырь кирәк иде,
Авыз булганда да иписез.

Казаннардан җырлар төяп кайтам,
Йөрәк шигырь белән тулышкан.
Офыкларга дөрләп ут кабына
Күкрәгемнән чыккан сулыштан.

Кайтам-кайтам, яна-яна кайтам,
Эчләремне тоташ ут баскан.
Ул утларның кайнар тамырлары
Халкым йөрәгенә тоташкан.

*1998*

## *Үз ояң*

Рәхәт икән, бик теләгән чакта
Кайтыр өчен булса үз ояң.
Артык булмасам да кешеләргә,
Үз ояма гына мин сыям.

Үз оямда гына мин иректә,
Үз оямда гына җаным хөр.
Үз оямда гына җырлар туа,
Үз оямда гына күңелем көр.

Юккамыни һәрбер җан иясе
Үз оясын кора тырышып.
Тормыш җилләреннән
сакланырга
Һәрбер җанга кирәк бер ышык.

Ә бит җирдә күпме
жил-давыллар!
Гарасаттан тора бу дөнья.
Оясызлар кыяларга бәрелеп
Тәгәриләр түбән упкынга.

Яшәр өчен генә түгел әле,
Үләргә дә кирәк үз ояң.
Мин оясыз булсам әгәр җирдә,
Үги булыр иде бу дөньям.

*1998*

## *Ак болытлар булып агыла күктән*

Балконымнан таулар күренеп тора,
Ак каеннар — тауның башында.
Егылмыйлар алар давылларда,
Тамырлары — тауның ташында.

Ә тауларның тамырлары җирдә,
Алар җиргә мәңге береккән.
Ничә гасыр үсте икән алар
Карар өчен шулай биектән?!

Шул тауларга карап утырамын,
Гыйбрәтле бит таулар язмышы.
Ак болытлар булып агыла күктән
Бу дөньяның шатлык-сагышы.

*1998*

## * * *

Бәхет өчен, шатлык өчен
Көрәшеп яшим.
Көрәшеп тапкан бәхетне
Өләшеп яшим.

Намус белән, Вөждан белән
Киңәшеп яшим.
Шулар киңәшчем булганга,
Һәрчак хөр яшим.

*1998*

* * *

Эшләр өчен әле эшем бар,
Тешләр өчен әле тешем бар.
Янар өчен әле хисем бар —
Тагын нәрсә кирәк кешегә?!

Яшәр өчен корган оям бар,
Ташына исемем язган кыям бар.
Шигърият дигән елгам бар —
Тагын нәрсә кирәк кешегә?!

Гомрен миңа биргән ярым бар,
Ярыма ярып бирер җаным бар.
Йөрәгемдә кайнар каным бар —
Тагын нәрсә кирәк кешегә?!

Кеше арасында йөзем ак,
Кара эшләр минем җанга ят.
Калдырмыйммын җирдә яманат —
Тагын нәрсә кирәк кешегә?!

*1998*

## *Күз нурларым*

Ак кәгазьгә күз нурларым түктем,
Кич утырып озын кышларда.
Ак болытлар аны төшеп алды,
Шәфәкъ яктысына кушарга.

Ак кәгазьгә күз нурларым түктем
Көзге моңсу елак кичләрдә.
Хәлсез яшен төшеп алды аны,
Соңгы учагына өстәргә.

Ак кәгазьгә күз нурларым түктем,
Сикереп торып кара төннәрдә.
Яз җилләре алып китте аны
Күңел кырларына сибәргә.

Күз нурларым ак чәчәкләр булып
Үсәр, бәлки, күпләр күңелендә.
Ак кәгазьгә соңгы күз нурларым
Шундый өмет белән түгелә.

*1998*

## *Яз кошы*

Быел язлар иртә килде миңа,
Сизмичә дә калдым бу кышны.
Күңелемә, һич тә көтмәгәндә,
Килеп оялады яз кошы.

Әй сайрады, әй сайрады ул кош,
Кош җырыннан карлар эреде.
Тәнемдәге барлык тамырлардан
Ярсу гөрләвекләр йөгерде.

Агачлар да шаулап яфрак ярды,
Чәчәк атты болын гөлләре.
Буран ояларын пыр туздырып,
Яшен учаклары дөрләде.

Бу яз кошы очып китәр, беләм,
Оя корыр берәр тирәктә.
Тик ул кошның җылылыгы калыр,
Җыры калыр минем йөрәктә.

*1998*

## *Барам*

Борчуларым да күп минем,
Шатлыгым да җитәрлек.
Барам-барам иңнәремә
Көн вә төннәр күтәреп.

Елларымны, жәлләмичә,
Учак итеп яндырам.
Күмерләрен, йолдыз итеп,
Күккә сибеп калдырам.

Барам, барам.
Керфекләрне
Сарган юллар тузаны.
Алдагы юллар билгесез,
Күренә бары узганы.

*1998*

## * * *

Сыгылган чаклар була,
Егылган чаклар була;
Үзеңнән сыекларга да
Сыенган чаклар була.

Сиңа түгел, дусларыңа
Җил бәргән чаклар була:
Үзеңнән көчлерәкләрне
Күтәргән чаклар була.

*1997*

## *Яшьлек эликсиры*

Кызлар!
Беләсезме шуны? —
Күзегезнең нуры,
Күңелегезнең җыры
Минем өчен иң шәп
Яшьлек эликсиры.

Мине мәңге-мәңге
Яшь итим дисәгез,
Акылыма хисне
Баш итим дисәгез —

Килегез,
Көлегез,
Шукланыгыз,
Мутланыгыз,
Үртәшегез,
Көнләшегез.

Күзләремә тулсын
Яшьлек яктылары,
Күңелемә тулсын
Сөю чаткылары.

Минем еллар янсын
Сезнең учакларда.
Минем йөрәк калсын
Сезнең кочакларда.

Алмаз итеп мине
Шомартыгыз әле,

Ялтыраткан саен
Арта алмаз яме.

Их сез, кызлар, кызлар,
Шаштырыгыз әйдә.
Оҗмах ишекләрен
Ачтырыгыз әйдә.

Эчерегез күбрәк
Яшьлек эликсирын.
Сүндермәгез бер дә
Йөзләремнең нурын.

Дөнья бит ул — мизгел,
Шуны белеп яшик.
Җаныбызда булсын
Яшен ташы — яшьлек.

*1998*

* * *

---

Ачык иде пәрдәләрем,
Тәрәзәмнән керде нур.
Шул нурны
            кыл итеп сузып
Уйнадым мин язгы җыр.

Ул җырыма исемне дә
«Балачак» диеп куйдым.
Нур сүнде...
            кылым өзелде...
Тәмамланмады җырым.

*1997*

* * *

Мин кыр казы нәселеннән, ахры,
Яратамын ерак очышны.
Тик очышлар, зур очышлар гына
Иркенәйтә ала сулышны.

Очкан чакта диңгез өсләреннән,
Каурыйларың җилдә йолкына.
Ул каурыйлар ак пароход булып
Тирбәләләр көчле дулкында.

«Кыйгак-кыйгак» диеп
бер кычкырсаң,
Урман өсләреннән узганда —
Тавышларың меңкат кабатланып
Сеңеп кала уйчан урманга.

Күкләр саклый синең эзләреңне,
Урман саклый синең тавышны.
Канат очларыннан кан тамса да,
Каргамыйсың һич тә язмышны.

Күкләр белән җирне тоташтырып,
Шәфәкъларга кушылып янасың.
Очышларда янып бетсәң генә
Мәңгелеккә күктә каласың.

*1997*

## *Мин бары тик...*

Мин бары тик бер түгәрәк ташны
Тәгәрәтеп менгән идем тауга.
Ә ул ташым кулдан ычкынды да
Әверелде дә куйды ап-ак Айга.

Төнге ауга чыккан киекләр дә
Туктап калды барган юлларыннан.
Фәрештәләр көмеш сәйлән сипте,
Чумырып алып
Айның нурларыннан.

Якынрак торган йолдызлар да
Айның яктысында коендылар.
Йолдызларның ап-ак тәннәреннән
Ак тамчылар җиргә коелдылар.

Төн югалтты үзенең каралыгын,
Угрыларның күренеп китте йөзе.
Җен-пәриләр тауга үрмәләде,
Кулларына тотып утлы гөрзи.

Мин бит бары бер түгәрәк ташны
Алып менгән идем биек тауга.
Никадәрле ыгы-зыгы купты,
Әверелде дә ташым якты Айга.

*1997*

* * *

---

Керми киттем каен урманына,
Каен урманнары ак иде.
Керер идем, күңелемә минем
Кара уйлар тулган чак иде.

Аңламады мине ак каеннар,
Миңа рәнжү саклап калдылар.
Матурлыкны безнең күрмәдең,
дип,
Шәфәкъларга кушылып яндылар.

Шәфәкъ уты күкне биләп алды,
Күктә купты яфрак бураны.
Уйларымны яшереп,
читкә чаптым,
Озатып калды каен урманы.

Керми киттем каен урманына,
Тыелып кына утырып еладым.
Ап-ак каеннарның йөзләренә
Сарылмады кара уйларым.

*1997*

## *Кызлар үтеп киткәч кенә*

Миңа алтмыш тулган, диләр,
Кем чыгарган бу сүзне?
Тутыра алмый әле йөрәк
Һаман да унсигезне.

Унбиш яшьлек кызларга да
Күз салмый үтәм әле.
Күз салмыйча үтеп шулай,
Бик кызык итәм әле.

Иң чибәр кызлар күреп тә
Төшмим әле коелып:
Калам шунда — читкә карап,
Бер чаткарак сыенып.

Йөрим горур, сер бирмичә,
Башны тотам югары.
Кызлар үтеп киткәч кенә
Йотам авыз суларын.

*1997*

## *Яшәп ятам моң-зар белми генә*

Берсе яратмаса,
Берсе яратыр, дип,
Сөюемне әйттем ике кызга,
Әллә үзем бик шәп булгангамы,
Әллә сүзем бик шәп булгангамы —
Баш тартмады миннән ике кыз да.

Берсе килмәгәндә,
Берсе килер, диеп,
Очрашырга дәштем боларны мин,
Әллә сүзем бик тәэсирле булды,
Әллә йөзем бик тә серле булды —
Икесе дә килде кызларымның.

Берсе ташлап китсә,
Берсе калыр, диеп,
Алып кайттым гүзәлләрне өйгә.
Әллә үзем гаярь ир булдыммы,
Әллә алар миннән бик уңдымы —
Көйләнделәр алар минем көйгә.

Йөрәк таза әле,
Һичберсен дә
Куып җибәрергә юк ниятем.
Яшәп ятам моң-зар белми генә,
Икесе дә мәңге күңелемдә —
Берсе — хатын,
берсе — шигърияте.

*1997*

## *Була*

Була көннәр —
Давыл куба җанда:
Талкый сине җилләр,
Килалмыйсың аңга.

Була көннәр —
Бәреп керә бәхет.
Була шундый көннәр —
Авып төшә тәхет.

Була көннәр —
Син җирдә зур терәк.
Була шундый көннәр —
Син яралы йөрәк.

Була көннәр —
Учта үсә гөлләр.
Була шундый көннәр —
Эчтә елый җилләр.

Була көннәр —
Өзелә соңгы өмет.
Беттем, дигәч, шуны
Берәү ялгый килеп.

Була көннәр —
Тартылалар кыллар.
Тартылмаса кыллар,
Тумас иде җырлар,
Тумас иде моңнар.

*1997*

## *Җаваплы*

Алдымда чип-чиста ак кәгазь,
Әйтерсең фәрештә канаты.
Тапларга һич хакым юк аны,
Мин кәгазь алдында җаваплы.
        Кулымда яраткан каләмем,
        Күп нәрсә язарга яраклы.
        Тик ялган язарга хакым юк,
        Мин каләм алдында җаваплы.
Агылып торсыннар шигырьләр,
Шагыйрьлек әйбәт эш, саваплы.
Тик начар язарга хакым юк,
Мин халкым алдында җаваплы.

*1997*

## *Тыныч кына яшим*

Ялагайлар да юк минем янда,
Килүче юк ришвәт белән дә.
Күңелемне вәсвәсәгә салып,
Чибәр кызлар йөрми тирәмдә.
        Гади эшемне дә күккә чөеп,
        Әйләндерүче юк башымны.
        Бик күп гөнаһлардан азат булып,
        Тыныч кына ашыйм ашымны.
Әйтер сүзен боргаланмый гына
Ярып әйтә дошман да, дус та.
Белә чөнки: минем менәсем юк
Һичбер вакыт югары постка.

*1996*

## *Илаһи мизгел*

Кайчагында җаннан кинәт
Бер җыр чыга атылып.
Сайрамый ул баш очымда
Тургай булып, талпынып.

Ул — илаһи, ул — дәһшәтле,
Ул — ярсу, ул — ирекле.
Як-якка каерып ташлый
Күкрәк дигән читлекне.

Оча ул биек-биеккә,
Менә җиде кат күккә.
Урап Айны, йолдызларны,
Уй җитмәс җиргә җитә.

Китә дә шунда югала,
Иярә алмыйм аңа.
Күпме исемсез җырларым
Югалды яна-яна.

Һич үкенмим ләкин моңа,
Янсыннар, югалсыннар.
Күккә менеп, йолдызларның
Нурына уралсыннар.

Бу — җанның илаһи чагы,
Мондый мизгелләр сирәк!
Күрәсең, сирәк булса да,
Җанга очышлар кирәктер,
Җанга очышлар кирәк.

*1997*

* * *

Һәр яз саен яңа гөлләр калкып чыга,
Таҗларыннан матурлыклар
саркып чыга.
Ирексездән үреләсең дә ул гөлләргә,
Яз сулышы бәреп керә күңелләргә.

Күзе барның күзе төшә гел матурга,
Матурлык та кирәк җанны уятырга.
Яз булмаса, гөл булмаса — нәрсә кала
Тамырларда аккан канны уйнатырга?!

Яздан көчле шәраб барын
белмим җирдә,
Шул исерткеч шәраб исе һәрбер гөлдә.
Тик берсенә иренеңне тидерсәң дә,
Фәрештәләр бии башлый күңелеңдә.

Сокланамын яңа туган һәрбер гөлгә,
Сокланамын яңа килгән һәрбер язга.
Һәммәсендә татылмаган яңа сер бар —
Язлар язга охшаш булмый,
назлар — назга.

*1997*

## *Эчтем*

— Эчәсеңме? —
дип сорыйсың, —
Эчтем һәм эчәчәкмен.
Гел эчүләргә бәйләнгән
Үткәнем, киләчәгем.

Эчтем язлар яктылыгын,
Сарысын эчтем көзнең.
Чумып таңнар шәрабына,
Ярдан ярларга йөздем.

Исереп башым югалттым,
Айныгач тагын эчтем.
Күкләр зәңгәрлеген эчеп,
Кабат җирләргә төштем.

Кышларның аклыгын эчтем,
Җәйләрнең җылылыгын.
Эчтем, тынга капланганчы,
Рәшәләр куелыгын.

Эчтем шатлык, эчтем сагыш
Тустаганнар тутырып.
Дөнья үзе кыстап торгач,
Булмый эчми утырып.

Белмим, күпме эчәчәкмен
Төрлесен шәрабларның.
Җилләр кайсы якка борыр
Тормышым корабларын?

*1997*

* * *

Язмыш миңа бик күп бирде
Бәхетле мизгелләрне.
Очтым, очтым — кулларыма
Нык урап тезгеннәрне.

Сикердем упкыннар аша,
Үрелдем кыяларга.
Куркуга ирек бирмәдем
Җаныма ояларга.

Эзләдем, таптым, югалттым,
Яраттым, яратылдым.
Бер байлыгымны югалтсам,
Яңасын таба тордым.

Мин тауларга баралмасам,
Таулар килде үзләре.
Күкләр минем күкрәгемнән
Яшен уты эзләде.

Яшеннәргә утлар бирдем,
Диңгезгә — ярсуымны.
Яндырдым төнге учакта
Нәфрәтем, ачуымны.

Булды инде, бар да булды —
Агы да, карасы да.
Күпме чәчәкләр үстердем
Йөрәгем ярасында.

*1997*

* * *

Тәгәри китте йомгагым,
Тәгәри китте ерак.
Йөгердем йомгак артыннан,
Җеп очын кулга урап.

Кердем кара урманнарга,
Уралдым каеннарга.
Уралмадым каеннарга,
Уралдым кайгыларга.

Төштем тирән дәрьяларга,
Актым бозлары белән.
Йоттым кайнар яшьләремне
Ачы тозлары белән.

Үрмәләдем кыяларга,
Исемем яздым ташына.
Чаптым йомгагым артыннан
Давылларның каршына.

Барам, барам, белә алмыйм,
Күпме калды юлларым.
Кайларга килеп тукталыр
Тәгәрәгән йомгагым?

*1996*

## *Кошлар юлы*

Кошлар юлы биек-биек,
Китә болытларга тиеп.
Кошлар юлын күзәтәмен,
Башларымны күккә чөеп.

Әй соклангыч очышлары,
Үз-үзләрен тотышлары.
Яшеннәрне кисеп үтә
Үткен канат-кылычлары.

Күкне — җиргә,
җирне — күккә
Нурлар белән бәйли-бәйли,
Оча алар
Хыялларны
Югарыга әйди-әйди.

Язны — көзгә, көзне — язга
Кушучы да шул ук кошлар.
Кошлар салган юллар буйлап
Күңелләрдән китә кышлар.

Ярый, канатлы кошлар бар,
Ярый, кошлар юлы биек.
Карыйсың бер күтәрелеп,
Йөргән чакта башны иеп.

*1994 – 1996*

## *Никтер , төшми әле убылып*

Кыяларга исемнәрне яздык,
Мәңге торсын диеп янәшә.
Вакыт яңгырлары исемнәрдән
Калдырмады ләкин бернәрсә.

Урамнарны йөз кат урый-урый,
Айлы кичтә антлар бирештек.
Тора-бара антлар онытылды,
Ятлар булып кына күрештек.

Бер-беребезнең исемнәре белән
Якты йолдызларны атадык.
Ул йолдызлар атылып
юкка чыкты,
Кыйпылчыкларын да тапмадык.

Әллә җилләр, әллә агымсулар
Араларга керде ургылып.
Икәү бергә менгән таулар гына,
Никтер, төшми әле убылып.

*1996*

* * *

Күпме юллар уздым җирдә,
Йоттым юл тузаннарын.
Кояшка кулларым сузып,
Китсәм дә күпләрне узып,
Язмыштан узалмадым.
Гел биеккә, гел үрләргә
Ашкынып торды йөрәк.
Менсәм дә биек үрләргә,
Көчем җитмәде менәргә
Үземнән биеккәрәк.
Кабыздым күпме учаклар,
Төшсен, дип, яктым ерак.
Җылытса да күпләр җанын,
Булмады яккан учагым
Үз җанымнан яктырак.

*1996*

* * *

Әй, бар иде яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар:
Дусларга да, дошманга да
Ачык иде кочаклар.
Үтте-китте ул чаклар,
Коелдылар борчаклар.
Хәзер инде кесәләрдә
Борчак түгел, пычаклар.

*1995*

## *Таулар аша үтә юлларым*

Язмышымнан һич тә зарланмыймын,
Ходай миңа биргән күп нәрсә:
Сулышым белән җирне җылыта алам,
Җылытырга әгәр кирәксә.

Упкыннарда биеклекләр күрәм,
Кара төннән табам яктылык.
Күккә чөйсәң, утлы күмер дә бит
Йолдыз булып китә атылып.

Кирәк булса, болыт булып агылам,
Яңгыр булып явам, кирәксә.
Шиңгән гөлләр кабат терелләләр,
Хисләр яңгырыма эләксә.

Кояш нурларыннан камчы үреп,
Яшен итеп күктә шартлатам;
Аклыгымны чәчәкләргә бирәм,
Ярсуымны җиргә таратам.

Гигант булмасам да, кәрлә түгел,
Бәхетемә җитә буйларым.
Карурманнар, зур дәрьялар аша,
Таулар аша үтә юлларым.

Даным да бар минем, малым да бар,
Бөтенесе, шөкер, җитәрлек.
Халкым мине үзенең иңнәрендә
Киләчәккә бара күтәреп.

*1996*

## *Ни эзлим?*

Нәрсә эзлим мин бу җирдән,
Бәргәләнеп көн вә төн?
Дөреслек кирәкме миңа? —
Таба алган аны кем?
        Бәлки, мин пакьлек эзлимдер
        Кергә баткан дөньядан?
        Дөньяларны юар өчен
        Су алыйм кай елгадан?
Ни эзлим? Алтын-көмешме?
Байлыкмы — күмелерлек?
Яңа җырмы — күңелләрдән
Тулышып түгелерлек?
        Эзлимме әллә матурлык
        Дөньяны коткарырлык?!
        Кайда ул андый матурлык —
        Кешеләр таң калырлык?!
Ни эзлим? Тугры дуслармы —
Сатылмый, сатмый торган,
Дуслык хакын Тәңре хакы
Шикелле хаклый торган.
        Ни эзлим? Ялганның тамырын
        Чабар өчен балтамы?
        Кайда ул балта, әллә соң
        Су төбендә ятамы?
Ни эзлим гомер буена,
Юлларга нәрсә тарта?
Яшәгән саен җанымда
Борчулар гына арта шул,
Сораулар гына арта.

*1996*

## *Яңа дәфтәр ачканда*

Яңа дәфтәр, яңа дәфтәр,
Өстә миңа яңа дәртләр.
Каләм-атым чабып торсын,
Тояклары янып торсын.
Ак кәгазең өсләрендә
Ак уйларым ташып торсын.
Һәр яңа көн яшәешнең
Яңа серен ачып торсын.
Һәрбер битең үзенә гел
Ашкындырып тартып торсын.
Яңа шигырь язган саен
Шатлыкларым арта торсын.
Яңа дәфтәр, ап-ак битләр,
Таба алсын синнән күпләр
Акылымның тирәнлеген,
Кайнарлыгын йөрәгемнең.
Күрсен зиһен яктылыгын,
Тойсын телнең татлылыгын.
Сизсен йөрәк сизгерлеген,
Белсен фикер өлгерлеген.
Яңа дәфтәр, сыйдыр җанның
Шәфәгын һәм алсу таңын.
Язларымның күкрәүләрен,
Күңелемнең тетрәүләрен.
Яңа дәфтәр, яңа дәфтәр,
Тамсын сиңа кайнар яшьләр,
Гомернең күп мизгелләре
Синдә калыр, синдә яшәр.

*1995*

# Алдану

Алдакчылар остардымы,
Аңгырайдым әллә мин —
Адым саен алданамын,
Белмим, нинди бәндә мин.

Алданамын якыннардан,
Алданамын ятлардан:
Китереп-китереп суга ялган
Һич көтмәгән яклардан.

Һәр ялганның үз йөзе бар,
Булмый ул кичәгечә:
Йә алтын булып ялтырый,
Йә чәчәк булып үсә.

Йә, иң татлы сүзләр булып,
Күңелгә тамып тора.
Татлы агуын ул шулай
Тамчылап салып тора.

Алданамын белмичә дә,
Алданамын белеп тә.
Алдануларны кичерәм
Елап та һәм көлеп тә.

Алданмыйча яшәүләрнең
Белмим һичбер чарасын.
Телим бары: берүк миннән
Башкалар алданмасын.

*1995*

## *Җиңелү*

Курыкмыйм мин һич тә җиңелүдән,
Батырлар да җиңелә бервакыт.
Көрәшчеләр алмашынып тора,
Вакыт агышын булмый туктатып.

Мәйданнарга яшь батырлар чыксын,
Көрәшә торган — аяк чалмыйча.
Тастымаллар билгә батып керсен,
Торсын мәйдан тын да алмыйча.

Чишмә булып биттән тирләр аксын,
Сөлгеләрне булсын сыгарлык.
Яшь кызларның йөрәкләре типсен,
Менә-менә атылып чыгарлык.

Матур итеп җиңелә белсәң әгәр,
Сизмисең син һичбер авырлык.
Җиңелүне горур кичерә белү —
Үзе җиңү, үзе батырлык.

*1995*

## *Уйлыйм*

Уйлыйм, уйлыйм,
                    үткәннәрне уйлыйм,
Киләчәкне уйлыйм еш кына.
Беләм юкса, матур уй-хыяллар
Күктән очып киткән кош кына.

Күктә очкан коштан эзләр калмый,
Башта туган уйдан эз кала.
Һәрбер уй ул йөрәк аша уза,
Һәм йөзләргә тирән эз сала.

Уйларым күп илем турында да,
Уйларым күп халкым турында.
Ил язмышы, халык язмышлары
Уйлый белгән ирләр кулында.

Күкрәгемнән язгы ташу булып
Ургып чыга уйлар елгасы.
Ак уйларым белән канлы җирне
Бер юасы килә, юасы,
Пычранды бит бик тә дөньясы.

*1995*

## *Җыр калдырыйк*

«Кеше китә — җыры кала»,— диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә.
Ул җыр җанга шатлык булып керсен,
Кояш булып кунсын йөзләргә.

Без һәммәбез җирдә берәү генә,
Беркемнең юк җирдә алмашы.
Кабатланмас үз язмышы белән
Туа җиргә адәм баласы.
Җыр калдырыйк җирдә,
нур калдырыйк,
Җырда калсын безнең гомерләр.
Безнең дөрләү, безнең януларны
Киләчәккә җырлар илтерләр.

*1995*

## * * *

Матур кызга гашыйк булу саваптыр,
Ашкынулар — йөрәкләрдән җаваптыр.
Кабыналмасаң чибәрләрне күреп тә,
Газаптыр ул, ай-һай, авыр газаптыр.

Берүк,
Тәңрем, салма мондый газапка,
Ахыргача йөзим әле савапта.
Сөю-гыйшык гөнаһ булса әгәр дә,
Мин әзермен моның өчен җавапка.

*1995*

* * *

Төшләремдә, никтер, атлар күрәм,
Гел шул бирми тынгы җаннарыма.
Томырылып чапкан яшь тайларның
Барып ябышамын ялларына.

Очам, очам зәңгәр офыкларга,
Күтәреләм ярсу болытларга.
Таш сибелә тояк асларыннан,
Җилләр сыйпый
кайнар башларымнан.

Кулым белән кагылам йолдызларга,
Чәчәк өләшәмен яшь кызларга.
Сокланамын дөнья киңлегенә,
Матурлыклар җыям күңелемә.

Буталалар төшләр белән өннәр,
Кушылалар төннәр белән көннәр.
Коелып кала барлык авыруларым,
Иркенлеккә чыга тоткын җаным.

*1995*

* * *

Күкрәгемнән җырлар бәреп чыга,
Ярсу чишмә булып.
Ага чишмә ерак-еракларга,
Улаклары тулып.

Кызлар килә чишмә буйларына,
Көянтәләр асып.
Китә алар чиләкләрен тутырып,
Сусауларын басып.

Юлчылар да бик еш
туктый монда,
Юлчыга су кирәк.
Бушаналар күпләр, чишмәләргә
Эч серләрен сөйләп.

Яшь гашыйклар йөрәкләрен ача
Сөйгән ярларына.
Агышының ярсулары күчә
Алар җаннарына.

Төпләренә талир тәңкә сала
Картлар, укып дога.
Шуңа күрә уйнак дулкыннардан
Чулпы тавышы чыга.

Була кайчак пычратучылар да
Саф чишмәнең суын.
Сафлыгыңны саклап калулары
Кыен, бик тә кыен.

*1995*

## *Сагынып сөйләргә*

Теләмим яшьлеккә
Яңадан кайтырга —
Ник бер үк җимешне
Ике кат татырга?

Теләмим бер юлны
Яңадан кичәргә,
Бер эчкән суларны
Яңадан эчәргә;

Бер сөйгән ярларны
Яңадан сөяргә —
Бер утта ике кат
Ник янып-көяргә?

Бер менгән үрләргә
Ник тагын менәргә?
Бер килгән шатлыкка
Ник ике көләргә?

Юлларым чәчәккә
Күмелгән булса да,
Күгемә йолдызлар
Сибелгән булса да,

Алтыннар, көмешләр
Өелгән булса да,
Уңыштан башларым
Чөлгән булса да —

Кирәкми, кирәкми,
Яшьлегем кайтмасын.
Мин телим үтәргә
Юлларның яңасын.

Сызлатсын, елатсын
Өр-яңа сагышлар.
Йөрәкне кузгатсын
Өр-яңа табышлар.

Эчерсен суларның
Тозлысын, ачысын.
Шартлатсын түбәмдә
Яшеннәр камчысын:

Кайгылар тетрәтсен,
Шатлыклар дөрләтсен,
Мәхәббәт җырлатсын,
Хыянәт елатсын.

Тик иске булмасын
Кичереш, уйларым,
Яңарып торсыннар
Һәрвакыт юлларым.

Карыйм гел сокланып
Өр-яңа гөлләргә,
Ә яшьлек калсын тик
Сагынып сөйләргә,
Мактанып сөйләргә.

*1995*

## *Шушы килеш яратыгыз*

Аунап үстем авылымның туфрагында,
Башак җыйдым язын-көзен кырларында.
Ятсам-торсам һаман да
шул бер үк нәрсә —
Туйганчы бер ашау иде уйларымда.

Кәлҗемәгә тамак туйса — шатлык иде,
Ипи ашар өчен әле хак юк иде.
Арба тартып, күз яшьләрен ялый-ялый,
Кызлар сөйдем,
чалбарларны ямый-ямый.

Үлән ашап үселсә дә, шөкер әле,
Сарык булып калынмады дөньясында.
Бер булса да очкын булдым учагында,
Бер булса да дулкын булдым елгасында.

Ләкин тормыш барыбер үз эзен салды,
Янган чакта күңелләрдә сөрем калды.
Чайкалсам да елгаларда дулкын булып,
Юып бетерә алмагандыр әле җанны.

Әгәр мине ап-ак диеп уйласагыз,
Ул уйларны күңелләрдән таратыгыз.
Мин заманнан һәм үземнән
шәбрәк түгел,
Яратсагыз, шушы килеш яратыгыз.

*1995*

## *Хаҗга барган кебек саваплы*

Авырайдым, кайнарлыгым бетте.
Нишләдең соң әле син, йөрәк?
Авылыма кайту миңа хәзер
Хаҗга барудан да читенрәк.

Чакыралар, ә мин уйлап ятам,
Киләә алмыйм ныклы карарга.
Машинам да юкса әзер тора
Выжт иттереп чыгып чабарга.

Моңа кадәр юләрлегем йөртте,
Ярдәм итте дөнья урарга.
Яраларга туфрак сибә-сибә,
Әзме йөрдем инде юлларда.

Ә хәзер юк, юллар ашкындырмый,
Түшәгемнән килми кубасым.
Җан талпынса, тәнем изалана:
«Мине кая алып чыгасың?»

Беләм юкса, беләм, кайту кирәк,
Авыр булса да юл ничаклы.
Туган авылыңа кайту бит ул
Хаҗга бару кебек саваплы.

*1995*

* * *

Зур дәрьялар кичтем, диеп
Тынычланма, күңелем.
Алда тирән диңгезләр бар,
Калуың бар күмелеп.

Күкләргә менгән чакта да
Шашынма, җан, ул чаклы.
Күккә менеп җитеп булмый,
Күкләр бит җиде катлы.

Мең сынау аша үтсәң дә,
Гел бер уй булсын анда:
Әле тормыш сынавының
Иң авырлары алда,
Иң авырлары алда!

*1995*

## *Утлы корал*

Утлы корал йөртү бездә
Тыелганын белсәм дә,
Йөртәмен утлы корал мин
Һәрвакытта кесәмдә.

Ансыз һичбер юлга чыкмыйм,
Кая барсам да алам.
Яклаучым да, саклаучым да
Утлы коралым — Каләм.

*1994*

## *Шундый-шундый төшләр керә*

Яттым исә бик еш кына
Әллә нинди төшләр керә,
Өннәремдә һичбер вакыт
Эшли алмас эшләр керә.

Җәйге айлы кичләр керә,
Күкрәгемә көчләр керә.
Яшьли сөйгән ярлар белән
Яшерен-яшерен эшләр керә.

Озын-озын юллар керә,
Җырланмаган җырлар керә.
Язылмаган әсәрләрдән
Басылып чыккан томнар керә.

Уйланмаган уйлар керә,
Сыйланмаган сыйлар керә.
Кочагыма, суырылып,
Матур, зифа кызлар керә.

Алмалар сикерә учка
Көзнең сихри кичләрендә.
Мәңгелеккә калсаң иде
Шушы матур төшләреңдә.

*1995*

## *Бирим, диеп, яктылык*

Озын-озын юллар үттем,
Күрдем җилен, карларын,
Кызуында парландым мин,
Җилләрендә чарландым.

Сазлыкларында баттым мин,
Үрләрендә калыктым.
Елгаларында актым да
Ярга чыгып сарыктым.

Кышларыннан гөл эзләдем,
Җәйләреннән ак карлар.
Упкыннарны тигезлим, дип,
Аудармак булдым таулар.

Мин әле һаман юлларда,
Мин әле һаман шул ук.
Боздан шәм ясыйм,
Бирим, дип,
Җиргә бераз яктылык.

*1995*

* * *

Мин халкымның баласы —
Агачтагы алмасы.
Бар әле бар, җилдә җилләп,
Кояшларда янасы.
Мин халкымның баласы,
Килми арып каласы.
Халык күңеленә таба
Барасы да барасы.
Мин халкымның баласы,
Килә шуны ачасы:
Әллә күзенең карасы,
Әле йөрәк ярасы.

*1995*

* * *

Китәсе килә кайвакыт
Еракка, бик еракка,
Тормыш гел шатлыктан торган,
Кайгы-хәсрәтсез якка.
Менәсе килә кайвакыт
Биек-биек үрләргә,
Тормышның түбәнлекләре
Күренмәслек җирләргә.
Югаласы килә кайчак
Эреп алсу таңнарда.
Үтте инде, үтте вакыт
Кабат юллар сайларга...

*1994*

## *Курай иткән*

Кайвакытта сөенәмен йөрмәвемә,
Дөньяның күп явызлыгын күрмәвемә.
Каным кайнар:
                    менеп төшми түзмәс идем
Явызларның авыз дигән мөнбәренә.

Андый эшкә башсызлыгым җитәр иде,
Ахры ничек бетсә дә бер бетәр иде.
Йә тукмалып кайтыр идем, яки тукмап,
Гомер буе яши алмас идем сыктап.

Беләм, беләм: явызларның кулы озын,
Теле уклы, ә очында агу була.
Чаккан саен аның да бит агуы кими,
Шуңардан да күңелләргә ару була.

Ярый инде, язмыш мине болай иткән,
Йөрәгемне басудагы тургай иткән.
Сугам дигән чыбыгымны алган да ул,
Җырлы-моңлы уйнап туймас
                                        курай иткән.

*1993*

* * *

Син дә хәлсезләндең, йөрәк,
Арыдыңмы әллә?
Хәлсезлегең кичереп булыр,
Ләкин дәртсезләнмә.
        Күпме кортлар кимерә сине,
        Син бит йомшак алма.
        Кортлар кимерсә кимерсен,
        Ләкин катыланма.
Син яшисең каный-каный,
Гел яралы хәлдә.
Яраларыңнан үлсәң үл,
Ләкин мәнсезләнмә.

*1991*

* * *

Яндырамын хәтер учагында
Үткән көннәремнең җыеп барсын;
Яңа вакыйгалар мәйдан сорый,
Яңа кичерешләргә урын калсын.
        Һәрбер көнең елга тиң чагында
        Ничек барсын
                сыйдыра алсын йөрәк?
        Хәтер архивларын вакыт-вакыт
        Чистартырга, яңартырга кирәк.
Арынырга теләп артык йөктән,
Кичерешләрне ягам өеп-өеп:
Шатлыкларым яна дөрли-дөрли,
Кайгыларым ята кара көеп.

*1984*

## *Дошманнарым*

Өч дошманым бар минем:
Күзем, колагым, телем.
Юктыр минем шулардан
Зыян күрмәгән көнем.

Колагым күп ишетә —
Күп белгәнне кем сөяр?
Күзләрем күпне күрә —
Күп күргәнне кем сөяр?

Иң явызы телемдер —
Әйтә туры, әйтә хак.
Хаклыкны соң кем сөяр?
Хаклык бит ул йөзгә тап.

Менә шушы дошманнар
Дусларымнан аерды.
Дусларымнан аерды да
Япа-ялгыз калдырды.

*1991*

## *Каләм эзлим*

Язар өчен каләм эзлим,
Сайлыйм елга камышларын.
Ул камышлар сөйләр миңа
Елгаларның агышларын.

Эзлим былбыл кунганнарын,
Эзлим дулкын юганнарын,
Эзлим җилдә сынганнарын —
Эченә моң тулганнарын.

Эзлим давыл күргәннәрен,
Яшеннәрдә көйгәннәрен,
Эзлим башын игәннәрен,
Яшәү серен белгәннәрен.

Язар өчен каләм эзлим,
Сайлыйм аккош каурыйларын.
Ул каурыйлар сөйләп бирер
Аккошларның сагышларын.

Алам ялгыз ятканнарын,
Илләр урап кайтканнарын,
Алам суга акканнарын,
Алам канга батканнарын.

Язар өчен каләм сайлыйм —
Төрле-төрле, төрлеләрен.
Табигатьнең үзе кебек
Гамьлеләрен, серлеләрен.

*1989*

## *Көттермә*

Син бит миңа барыбер киләчәксең,
Килми йөреп гаҗиз иттермә.
Көткәннәргә минуты да озак,
Көттермәче, бәхет, көттермә.

Адресымны, бәлки, белмисеңдер.
Йөрисеңдер шуңар гел читтә.
Гомер — мизгел, гомер үтә-китә,
Кил тизрәк, уңыш, көттермә.

Түбәнлекләр җанга ояласа,
Оятсызлык менсә иң түргә —
Горурлыгым, кил дә битемә төкер,
Көттермәче берүк, көттермә.

Ялварамын сиңа, әй язмышым,
Дан алдында тезем чүктермә.
Тезләнгәнем күрсәң, данымны ал,
Көттермәче, зинһар, көттермә.

Кадерем бетсә, кеше күзләренә
Каратып син газап чиктермә.
Бар эшеңне ташлап, яныма йөгер,
Көттермәче, әҗәл, көттермә.

*1989*

* * *

Моңлы күңелем, уйлы күңелем
Айкала да чайкала.
Түгелә моңнар, сибелә уйлар,
Җирдә гөлләр таптала.

Дөнья упкын, һәрбер дулкын
Тамчыларга таркала;
Кибә яшьләр, иелә башлар,
Шатлык китә, зар кала.

Бетә көчләр, сүрелә хисләр,
Йөз аллыгын таң ала;
Өзелә кыллар, тына җырлар,
Бәргәләнеп җан кала.

Язмыш кулга, манып суга,
Актык сынык нан сала;
Читкә тибелеп, җиргә сибелеп,
Мәңге җыйган мал кала.

Килдем диеп, җиңдем диеп,
Картлык итә тантана;
Җиргә ятып үксеп-шашкан
Иясен җуйган дан кала.

*1989*

# *Кара урман*

Кара да гына урман,
караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә;
Заманалар авыр,
михнәтләр күп,
Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.

*Татар халык җыры*

«Кара урман» җырын
җырлый-җырлый
Күпме карурманнар кичелгән.
Әле һаман чыгып җиталган юк
Кара урманнарның эченнән.

Яхшы атлар ак күбеккә батып
Егылып калды инде юлларда.
Дус-ишләр дә бетте таралышып,
Тавышым гына калды җырларга.

Адашсам да, курыксам да җырлыйм,
Сөенеп җырлыйм тавышым булганга.
Шушы җырым — яхшы атым да һәм
Дус-ишем дә кара урманда.

Өскә килә бүре өерләре
Ташланмакчы булып бугазга —
Ботарларлар иде, җырлавыңнан
Туктап калсаң әгәр беразга.

Бүреләр бит алар аңлый барсын —
Җырлый алгач, димәк, син көчле.

Җырың белән китереп сугуың бар
Агач сындырырлык җил төсле.

Җырлап барам. Җырым кайтавазы
Офыкларга кадәр таралсын;
Шул җырлардан, юлдагылар өчен,
Яңа җырлар җирдә яралсын.

«Кара да гына урман, караңгы төн...»
Карурманда ерткыч җитәрлек.
Яхшы атлар егылып калган чакта,
Яхшы дуслар коелып калган чакта,
Җырлар бара безне күтәреп.

*1988*

* * *

Тукта, тукта, кем елый соң,
Тетрәндереп күңелне?
Әтисез, иписез үткән
Балачагым түгелме?
Тукта, тукта, кем елый соң,
Бәгырьне кисеп-кисеп?
Рәнҗетелгән яшьлегемме
Тора һаман да үксеп?
Тукта, тукта, кем елый соң,
Ишетәм нинди өннәр?
Җирне тырнап елый мәллә
Заяга үткән көннәр?
Хәтер дигән учагымның
Җил актара көлләрен.
Көл астыннан саркып чыга
Күзе яшьле көннәрем.

*1984*

## *Рәхмәт укыйм*

Язмыш, сиңа рәхмәт укыйм
Күп чакларда:
Ыргытсаң да кайнар-кайнар
Учакларга —

Ярый, димен, иш итмәдең
Куркакларга,
Үз-үзен дә яклый алмас
Йомшакларга,

Юк өчен дә күз-яшь түккән
Елакларга,
Эче тулы мәкер булган
Пычракларга.

Иш итмәдең дөнья җитмәс
Комсызларга,
Кеше кайгысыннан көлгән
Тозсызларга,

Егылганны тәпәләүче
Кансызларга,
Гомре бер тиен тормый торган
Сансызларга.

Иш итмәдең оятсыз һәм
Әрсезләргә,
Сүлпәннәргә, сүрәннәргә,
Дәртсезләргә.

Бар дөньяны каралтучы
Ямьсезләргә,
Пошмасларга, ялкауларга,
Гамьсезләргә.

Иярттең син, иптәш иттең
Зур затларга —
Яхшылыкка, яктылыкка
Юмартларга.

Эше олы, ә күңеле
Тыйнакларга,
Карый белә торганнарга
Еракларга.

Бирми мине елакларга,
Куркакларга,
Иптәш иттең миһербанлы
Олпатларга.

Юлдашларым үземнән шәп,
Үземнән зур.
Алар белән барган чакта
Булмамын хур.

*1987*

## *Елый белмәү*

Күп нәрсәдән мәхрүм калдым
Елый белмәү аркасында.
Яшьләр түгел, очкын булды
Күзләремнең чакмасында.

Ә бит юкса дөньясында
Әз булмады елар чаклар.
Елау гына түгел, хәтта
Бүре булып улар чаклар.

Ачлык белән хәерчелек
Яңакларга сугып торды.
Суккан саен, көлтә-көлтә
Күздән утлар чыгып торды.

Кемнәрдер зар еладылар,
Ә кемнәрдер нык булдылар.
Елый белеп елаучылар
Ач елда да тук булдылар.

Тук булдылар, киенделәр,
Кикерделәр, симерделәр.
Елый белмәүчеләр генә
Бер сынykка тилмерделәр.

Заманалар рәтләнгәч тә,
Елаучылар кала бирде.
Мескеннәр, гел елый-елый,
Үз кирәген ала бирде.

Кемдер елап исем алды,
Кемдер елап бүләк алды.

Күзләрендә яше юклар
Рәхмәт көтеп эшләп арды.

Әйе, күпләр үзләштерде
Кайда ничек елау серен.
Ә мин — тинтәк, һаман менә
Шуның серен белми йөрим.

Хәер, миңа еласам да
Ышанмаслар, белеп торам.
Шуңа күрә еламыймын,
Горур гына көлеп торам.
Шул горурлыкның бәясен
Үзем генә белеп торам.

*1987*

* * *

Язмыш, язмыш, күп сорамыйм
Синнән бер дә:
Яманлыкны онытмаслык
Хәтер бирмә.
Йөрәгемне май басарлык
Байлык бирмә.
Һичкем өчен сызланмаслык
Саулык бирмә.
Кешелегемне күмәрлек
Шөһрәт бирмә.
Сөюне таптап изәрлек
Кодрәт бирмә.
Усаллыктан сукраерлык
Күңел бирмә.
Кешеләрне туйдырырлык
Гомер бирмә.

*1986*

## *Соңгы сулышыма кадәр*

Ташлама мине, ташлама,
Гел минем җанда уян.
Актык көнемә кадәрле
Ташлама мине, Хыял.

Ташлама мине,
Ташлама,
Ымсындыр мине, йөгерт,
Мәңге күзләрем йомганчы
Ташлама мине, Өмет.

Ташлама мине, ташлама,
Рәхәт син барны тою.
Йөрәгем соң кат типкәнче
Ташлама мине, Сөю.

Ташлама мине, ташлама,
Гел тор сафлыгың чәчеп.
Соңгы сулышыма кадәр
Ташлама мине, Яшьлек!

*1984*

## *Ишекләр*

Шаштың, күңел, шаштың,
Һәм күкләргә аштың.
Җиде кат күкләрнең
Ишекләрен ачтым.

Иң беренче катта
Балачагым ишеге.
Болытларга эленеп
Калды шунда бишегем.

Ә икенче катта
Мәктәп дигән ишек.
Ачтым, яптым. Еллар
Тиз үттеләр ничек.

Өченче катында
Яшьлек иде бугай.
Күренеп кенә калды
Чәчәкле бер тугай.

Дүртенчегә менгәч,
Сөю ишеген какты м.
Бәлки, аңа минем
Булмагандыр хакым.

Ә бишенче катта
Каршылады урман.
Үз юлымны эзләп
Киттем әнә шуннан.

Алтынчысын ачкач,
Тирән диңгез күрдем.
Иҗат диңгезенә
Күмелгәнче кердем.

Инде ишекнең мин
Иң соңгысын кактым.
Шушы биеклектән
Төшәргә юк хакым.

*1982*

## *Ару турында*

Эшләп ару — рәхәт ару,
Эшли-эшли арылсын;
Эшсезлектән арылмасын,
Күрсәтмәсен анысын.

Көтеп ару — өметле ару,
Көтеп арта януың;
Билгесезлек арытмасын,
Табу кыен даруын.

Юлда ару — татлы ару,
Арылса да, барылсын;
Адашулар арытмасын,
Юл тапмасаң авыр соң!

Җиңел эшләр таләп итмим,
Талчыктырсын, арылсын.
Яшәү генә арытмасын,
Күтәралмам анысын.

*1979*

## *Әнкәй тирбәтә бишек*

Кышкы кич. Авыл өе.
Бозланган тәрәз, ишек.
Мондый теләкләр теләп
Әнкәй тирбәтә бишек:
«Батыр булып үс, улым.
Җитмеш дәрья кич, улым.
Җитмеш юлның төенен
Акыл белән чиш, улым.
Бөркеттән син канат ал,
Боланнан син аяк ал.
Арысланнан йөрәк ал,
Юлбарыстан куәт ал.
Тургай дәртле моң бирсен,
Имән таза сын бирсен.
Кояш якты йөз бирсен,
Лачын үткен күз бирсен».

Акладыммы әнкәйнең
Бөтен изге теләген?
Һәрнәрсәгә түзәрлек
Көчлеме соң йөрәгем?
Күтәрелә алдыммы
Бөркет кебек югары?
Тиңме тургай моңына
Күңелемнең моңнары?
Дус кайгысын күрерлек
Очлымы минем күзем?
Ил йөзенә багарлык
Яктымы минем йөзем?

Күз алдымда: кышкы кич,
Бозлы тәрәзә, ишек...
Изге теләкләр теләп,
Әнкәй тирбәтә бишек.

*1982*

* * *

Ялгышмам дип уйлый идем,
Адашмам дип уйлый идем,
Ләкин тормыш
Урман булып юлым япты.

Сине эзләп табар өчен,
Адашуны онытып,
Ялгышуны онытып,
Карурманга чаптым.

Иелмәм дип уйлый идем,
Бөгелмәм дип уйлый идем,
Ләкин тормыш
Чишмә булып җирдән акты,

Саф суларын эчәр өчен,
Иелү генә түгел,
Бөгелү генә түгел,
Түшләремә яттым.

*1978*

* * *

Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач,
Минем өскә теләсә кем менә ала.
Теләсә кем ботакның иң биегенә
Тузанланган чабатасын элә ала.

Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач,
Балта чабу авырмыни минем сыртка?
Моны киссәм, авып билне сытар, диеп
Маташулар кирәк түгел курка-курка.

Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач,
Тормыймын мин башым белән күкне сөзеп...
Буе җиткәч, үткән-сүткән һәрбер кеше
Берәм-берәм яфракларым китә өзеп.

Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач,
Тамырларга авыр бигрәк, тамырларга.
Менә-менә кубарылып чыгар кебек
Тамырларым көчле җил һәм давылларда.

Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач,
Буем озын, тик күрмиләр җирдә булгач.
Озынлыгым күренер әле минем дә бер,
Янәшәмә башка агачлар егылгач.

*1981*

# Өйрәт

Өйрәт мине, тормыш,
Күп нәрсәгә өйрәт.
Мәңге чүкелә торган
Сандал булсын йөрәк.
Кеше күңеленә
Туры юллар өйрәт.
Сагыш кумалмаслык
Олы моңнар өйрәт.
Җырга кертер өчен
Сихри сүзләр өйрәт.
Ул сүзләрдән кеше
Тетрәп куйсын кинәт.
Дошманнардан дусны
Аерырга өйрәт.
Алдануың белсәң,
Авыр була бигрәк.
Ач син серләреңне,
Юмартлыкка өйрәт.
Җанны кызганмаска
Нинди булу кирәк?
Өйрәт саранлыкка,
Саранлык та кирәк,
Вәгъдә өләшергә
Яратабыз күбрәк.
Тагын шуны телим:
Батырлыкка өйрәт.
Курыкмыйча керим
Янган утка дөрләп.

Дөньяда ни булмас,
Куркырга да өйрәт.
Хыянәт итүдән
Гел курыксын йөрәк.
Өйрәт катылыкка,
Өйрәт йомшаклыкка,
Өйрәт горурлыкка,
Өйрәт сабырлыкка.
Өйрәт мине, тормыш,
Сернең барчасына.
Тик өйрәтә күрмә
Зарланырга гына.

*1980*

## *Күңел күзем*

Маңгай күзем күрмәгәнне
Күрә күңел күзем.
Шуңар кылган эшем өчен
Һич кызармый йөзем.

Бар минем илем каршында
Шагыйрь дигән атым.
Шул атыңа тугры бул, ди
Күңел күзем — халкым.

*1979*

* * *

Күңел һәрчак кайнап торды,
Тулып торды,
Язлар-көзләр бер-берләрен
Куып торды,
Сөенечләр, көенечләр
Туып торды —
Бер сөенеч йөз кайгыны
Оныттырды.

Ак хыяллар миңа кулын
Сузып торды,
Бик күбесе эшкә ашмый
Узып торды,
Ә шулай да ашкындырып,
Җилкендереп,
Хыялларның яңалары
Кызыктырды.

Уңышсызлык аяк чалып,
Егып торды,
Кояш көтсәң, кара болыт
Чыгып торды,
Көрәшкәндә кылычларым
Сынып торды,
Ахры, шушы җиңелүләр
Чыныктырды.

*1978*

## *Гомернең һәрбер көнендә*

Алда юллар, юлда утлар,
Янмыйча чыгасы бар;
Тормыш сандалына салып,
Ныклыкны сыныйсы бар.

Алда юллар, юлда сулар,
Батмыйча узасы бар;
Бер ярыннан бер ярына
Күперләр сузасы бар.

Алда юллар, юлда үрләр,
Үрләргә менәсе бар;
Кыяның иң биегенә
Йөрәкне эләсе бар.

Алда юллар, юлда серләр,
Серләрне ачасы бар;
Гомернең һәрбер көнендә
Чигенми яшисе бар!

*1976*

## *Сагышларым*

Сагышларым бирдем җилләргә,
Алып кит, дип ерак илләргә...
Канатлары җилнең сыгылды,
Сагышларым җиргә,
Таралашып җилдә,
Сары чәчәк булып коелды.

Сагышларым салдым суларга,
Адашсын, дип ерак юлларда...
Елга туктап калды ярсудан.
Сагышларым бар да
Утырып калды ярда,
Ташулардан калган боз сыман.

Сагышларым аттым яшенгә,
Яндыр, дидем, җиргә төшермә.
Яшен сүнде күкләр йөзендә,
Синнән башка беркем
Күтәралмый, диеп,
Сагышларым кайтты үземә.

*1976*

* * *

Юл буенда бер чәчәк
Зәңгәр күккә караган.
Җиргә энҗе коела
Тәнендәге ярадан.

Атлар да таптый аны,
Тузан да каплый аны.
Котырып искән җилләр
Чак өзеп атмый аны.

Көнгә ничә мәртәбә
Егыла да тора ул.
Яраларын ялый да
Башын күккә бора ул.

Бетте дигәч — терелә,
Гел кояшка үрелә.
Дөнья аңа көннән-көн
Матур булып күренә.

*1975*

* * *

Калганда караңгы төннәрдә,
Әйттем мин, бушлыкка күз терәп:
— Юк, алдый алмассың, кара төн,
Дөньяда яктылык күберәк,
Дөньяда яктылык күберәк.

Кешеләр яманлык кылса да,
Шуңардан әрнесә дә йөрәк;
Әйттем мин күз яше аралаш:
— Дөньяда яхшылык күберәк,
Дөньяда яхшылык күберәк.

Хаксызлык тантана итәр дип,
Каршымда торса да мең өрәк,
Әйттем мин чып-чынлап ышанып:
— Дөньяда гаделлек күберәк,
Дөньяда гаделлек күберәк.

Гомремнең буеннан-буена
Барсам да гел авыр йөк сөйрәп,
Әйттем мин гөлләргә үрелеп:
— Дөньяда матурлык күберәк,
Дөньяда матурлык күберәк!

*1971*

* * *

Малай чагым шул минем:
Апрельдәге гөрләвек,
Агачтагы чикләвек,
Оядагы карлыгач,
Кесәдәге чакматаш.

Гөрләвек — күп йөгермәгән,
Чикләвек — нык өлгермәгән,
Канатлар — кагынмаган,
Эчтә ялкын — кабынмаган.

Яшьлек чагым шуңар тиң:
Кысып буган көлтәгә,
Балкып янган иртәгә,
Җәйге көчле яңгырга,
Тирән киткән тамырга.

Көлтәм — буылган билем,
Иртәм — мәхәббәт гөлем,
Җәйге яңгыр — шуклыгым,
Тамырларым — ныклыгым.

*1971*

## *Тугры дус*

Һич хыянәт итми торган
Бер дустым бар янымда:
Күңелем минем кимлек сизми
Янда ул бар чагында.

Ул булганга, ил алдында
Кызармый минем йөзем.
Кая барсам — кадерем бар,
Сөйләсәм — үтә сүзем.

Ул булганга көнем якты,
Офыкларым киң һаман.
Арысам да, авырсам да,
Туя белмим дөньядан.

Ул минем шатлык, юаныч,
Ул минем зур горурлык.
Дөньяда һичнәрсә юктыр
Аңарга тиң булырлык.

Ул минем тормыш тоткасы,
Ул минем бетмәс көчем.
Тугры дустымның исеме —
Хезмәтем минем, эшем!

*1970*

## *Аерылмасам әгәр*

Сөйрәсәм дә йөкнең авырын,
Ташламамын көрәш-дау кырын;
Гел барырмын, бер дә ялыкмам,
Аерылмасам әгәр халыктан.

Үрмәләрмен кыя-тауларга,
Кул сузармын якты таңнарга;
Ерак юлда һич тә арымам,
Аерылмасам сөйгән ярымнан.

Кайгы басмас көләч күзләрне,
Онытмамын шаян сүзләрне;
Гел янармын яшьлек хисеннән,
Аерылмасам якын эшемнән.

Күкрәгемдә көчем кимемәс,
Горур башым түбән иелмәс;
Аһ-зар сүзе чыкмас телемнән,
Аерылмасам туган илемнән.

*1968*

## *Каз кычкыра*

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Җил каерган канатын;
Һаваларга оча алмый,
Талпына да кала тын.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Тавышы ерак китә;
Очкан кошлар өстән генә
Хәлләрен сорап китә.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Күккә сузган муенын,
Ак болытлар арасыннан
Эзли бугай үз юлын.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Кырга сыймый тавышы;
Кемнәр килеп уртаклашыр
Кыр казының язмышын?

*1968*

* * *

Җир әйләнә, диделәр,
ышанмадым,
Ул чагында сабый идем.
Һәрнәрсәгә тик беркатлы
Караш белән карый идем,
Аңлый төштем, үсә төштем.
Дөньяларны кичә төштем,
Чишелмәгән төеннәрне
Тешем белән чишә төштем.

Берәүләрне дус иттем мин,
Берәүләргә үч иттем мин.
Берәүләрне зурладым мин,
Берәүләрне хурладым мин.
Яхшылык та, начарлык та
Кайта торды үземә дә:
Хәзер белдем инде менә —
Җир әйләнә, җир әйләнә.

*1967*

* * *

Дөньяда мин бер битараф кеше түгел,
Матурлыкны күрер өчен күзләрем бар;
Шуңа күрә шатлана һәм сөенә күңел,
Тормышымда үзем салган эзләрем бар.
Дусларымны кочар өчен кулларым бар,
Ялкынланып сөяр өчен хисләрем бар.
Сөйгәнемне назлар өчен моңнарым бар,
Сөенеп искә ала торган кичләрем бар.
Кешеләргә йөрәгемне бирә алам,
Диңгез кебек ярсып торган йөрәгем бар.
Авырлыкка туры карап яшим һаман,
Чөнки минем кешеләргә кирәгем бар.
Каерса да язмыш минем канатымны,
Ала алмас кешеләрне яратуны.

*1966*

* * *

Беренче кат кайгыны мин шунда белдем,
Ул чак миңа нибарысы биш яшь иде,
Әтиебез яу кырында һәлак булды,
Кайгы ул көн ташып торган күз яшь иде.
Шатлыкны мин беренче кат шунда белдем:
Яңа гына сугыш беткән айлар иде,
Әниебез мич тутырып ипи салды,
Бәхет ул көн түп-түгәрәк, кайнар иде.
Ә аннан соң шатлыклар да, кайгылар да
Күрмәдем дип әйтмимен мин сезгә һич тә.
Ләкин хәтер соңгыларын тиз онытты,
Тик болары бүгенгедәй һаман истә.

*1966*

# *Әткәм төсе тыныч көннәрдә*

(Туплам)

## 1. Тамыры калган

Сугыш тавышлары күптән тынды,
Төзәлделәр җирнең яралары.
Әтиләренең окопларын сөреп
Иген чәчә хәзер балалары.

Кырлар шундый тигез сулап ята,
Офыкларда яңа шәфәкъ кына.
Зәңгәр күккә күзен төбәгәннәр —
Штык түгел алар, башак кына.

Тонык күкрәү ишетелә кайчак,
Яшен генә йөри, яшен генә.
Ә шулай да күпне күргән картлар
Бер-беренә карый яшерен генә.

Сугыш тавышлары тынды, ләкин
Күңелләрдә шомы яши һаман.
Сугыш агачларын аударсак та,
Кайлардадыр әле тамыры калган.

Шушы тамыр
тишелеп чыкмасын дип,
Көне-төне дөнья сакта тора.
Дөнья уяу сакта торган чакта
Тынычлыкның гомере арта тора.

*1984*

## 2. Хәтерләү

Мин әтине хәтерлимме икән?
Уйланамын бүген шушы хакта.
Миңа бары өч яшь ярым булган
Ул сугышка чыгып киткән чакта.

Буен, төсен, әйе, хәтерләмим,
Ләкин
Сагынуларым онытылмый һич тә:
Үтмәс пәке белән карт-корыдан
Чәч алдыруларым һаман истә.

Чалгы чүкетергә ир тапмыйча
Авыл буйлап йөргән чакларда да,
Черек бәрәңге эзләп бакчаларны
«Борын белән сөргән» чакларда да;

Өйнең тишек салам түбәсеннән
Өстебезгә тамчы тамганда да,
Өлкәннәрдән, бездән көчлеләрдән
Бер дә юкка камчы алганда да;

Ат урынына үз сыерыңны җигеп,
Тырмалаганда да колхоз җирен,
«Әти булса иде, әти»,— диеп
Кысылып-кысылып куя иде ирен.

Һәм сугышка ачу, нәфрәт белән
Йомарлана иде нәни йодрык.
«Сугыш» дигән ләгънәт төшкән сүзне
Иреннәрдән без яшь белән юдык.

Әтине мин рәтләп хәтерләмим,
Ул чак булган миңа өч яшь ярым.
Тик хәтерлим, без ипи сорасак,
Әнкәй күзләренең чыланганын.

Аннан бирле шактый көннәр үтте,
Күзләр кипте, күрдек шат көннәрне,
«Сугыш» сүзе генә онытылмый,
Сискәндерә һаман күңелләрне.

*1984*

### 3. Әни әйтә

Әни әйтә: «Әтиең киткән чакта
Елап чаптың арба артыннан.
Әтиең сине кочагына алды
Төшеп шунда үзенең атыннан.
Өзгәләндең, ник китәсең, диеп,
Кушмыйсың бит үзең сугышырга...
Мин дә барыйм әле, мин дә барыйм
Сугышларда сиңа булышырга.
Борыныңны сугып канатсалар,
Су салырмын битең юганда.
Бер кеше дә безне җиңә алмас,
Синең белән икәү булганда».
Елаганмын әнә шулай ярсып,
Ни аңлый соң сабый акылы?
Кем уйлаган килеп җитәр диеп
Безгә кадәр сугыш ялкыны.
«Ник китәсең?» — диеп соравыма
Әйтмәсә дә әти һичбер сүз
Тыныч еллар биргән бәхет аша
Ник киткәнен аның белдек без.

*1984*

### 4. Бер пуля

Бер пуля тигән берьюлы
Сигез кеше йөрәгенә,
Яуда килеп кергән дә ул
Әтиемнең күкрәгенә.

Кырык яшьтә сулышын өзгән
Һәм тол иткән анамны да.
Шул ук пуля ятим иткән
Безне — алты баланы да.

Бер пуля бит, ә сугышта
Алар күпме явып торган.
Йөзләр яуда авып торган,
Меңнәр яра алып торган.

*1984*

### 5. Әткәбезнең фронт хатлары

«Әти» сүзен әйтеп үсмәдек без,
Белмим аннан авыр ни барны.
Боекканда җыелып укый идек
Әткәбездән килгән хатларны.

Бәхетлеләр күреп күзебез янса,
Әни безгә андый чакларны
Укый иде, йөзләр яктырганчы,
Әткәбездән килгән хатларны.

Суык булса безгә, әни тагын
Шул ук сандык төбен актарды:
Җанны җылытканчы укыдык без
Әткәбездән килгән хатларны.

Озата барды безне гомер буе
Әткәбезнең фронт хатлары.
Безне һәрчак түбән төшүләрдән,
Хурлык эчүләрдән саклады
Солдат әткәбезнең хатлары.

*1984*

## 6. Кызыл байрак төсле кызыл күлмәк

Җиңү көне шулай истә калган,
Әни яңа күлмәк кидерде:
«Әтиеңнең күлмәге бу, улым,
Саклап кына кия күр»,— диде.

Җиңе аның шактый озын иде,
Һәм төшенке иде иңнәре.
Аларына бер дә ис китмәде —
Сызгандым да куйдым җиңнәрне.

Әни шунда әллә нишләп китте,
Кинәт кенә читкә борылды.
Ак канаттай яулык очы белән
Керфек очларына орынды.

Миңа нәрсә — чыгып чаптым тизрәк
Күрсәтергә яңа күлмәкне.
Кызыл байрак төсле кызыл күлмәк
Ашкындырды минем йөрәкне.

Кичкә кадәр йөрдем урамнарда,
Онытасым юк һич тә ул көнне.
Рәхәт иде миңа, иңнәремнән
Әти үзе кочкан шикелле.

Кызыл байрак төсле кызыл күлмәк
Җилкендерде кайчан кисәм дә.
Бик тиз ир булдык без,
әтиләрнең
Күлмәкләрен киеп үскәнгә.

*1984*

## 7. Бар микән соң

Кабереӊ синеӊ, әти, бик еракта,
Гәүдәӊ чит җирләргә күмелгән.
Ничә еллар инде шул якларга
Бер барсаӊ дип йөрим күӊелдән.
Бара алмыйм.

Юлыӊ өзелеп калган
Ул урыннар, белмим, ниндидер?
Безнеӊ яктан искән җилләр, бәлки,
Кабереӊә ятып иӊридер.

Баш очында гөлләр үсә микән,
Ак каеннар әллә шаулыймы?
Каеннарга моӊлы кәккүк кунып,
Тыныч еллар гомерен саныймы?

Санасын ул меӊ-меӊ еллар безгә,
Куркытмасын беркем ул кошны.
Чит җирләрдә син бит ятып калдыӊ
Имин итәр өчен тормышны.

Бар микән соӊ, чәчәк салыр өчен,
Кабереӊне синеӊ белгәннәр?
Бик бәхетле икән, бик бәхетле
Илләренә кайтып үлгәннәр.

*1984*

# *Яшьсез генә елый йөрәгем*

(Туплам)

*Әнием — Галим кызы*
*Бибигафифәнең якты истәлегенә*

Әй дөнья, дөнья, дөнья —
Уралган сагыш-моңга.
Көтмәгәндә ялкыннары
Килеп бәреләә тынга.

Кинәт өнсез каласың,
Тавыш-тынсыз янасың.
Хәвеф-хәтәр сагалый гел
Җирдә адәм баласын.

Упкынында батасың,
Үрләрендә калкасың.
Көчең җитсә-җитмәсә дә,
Үз йөгеңне тартасың.

Алтынмы ул, көмешме —
Һәркемнең үз өлеше.
Башкаларның өлешенә
Керә алмый бер кеше.

* * *

Үтә гомер, үзгәрә төс,
Бетә гайрәт коелып.
Кала бары маңгайларда
Уйлар гына уелып.

Яна кайгы, яна шатлык,
Учак эзе — күзләрдә.
Вакыт җиле туфрак сибә
Юллардагы эзләргә.

Ташлый хыял, сүнә өмет,
Җан ашкынмый югары.
«Зың» иттереп бер чыңлый да
Өзелә гомер кыллары.

Ишетми дә кала күпләр
Соңгы кылның чыңлавын:
Маңгайлардан укып булмый
Кеше киткәч — уйларын.

* * *

Таңда җилләр килделәр,
Әнкәң үлде, диделәр.
Бу хәбәрдән күңелемнең
Ал гөлләре шиңделәр.

Кошлар тынды сайраудан,
Урман тынды шаулаудан.
Вакыт кинәт туктап калды
Минутларны санаудан.

Җанны бушлык урады,
Сарды — кайгы томаны.
Күкрәгемә башын салып,
Йөрәк үксеп елады.

Акыл әйтте: тынычлан,
Кеше түгел корычтан.
Вакыт җиткәч һәркем үтә
Әҗәл дигән кылычтан.

Беләм шулай икәнен,
Учакта ут беткәнен.
Иреннәрем чәйни-чәйни
Уй йомгагын сүтәмен.

* * *

Иңендә зәңгәр көянтә,
Су тулы чиләкләре.
Көянтә өстенә яткан
Ак канат — беләкләре.

Борма-борма су юлы,
Бу кемнәрнең сылуы?
Мөлдерәгән чиләгеннән
Су эчерер кемнәргә?

Кемнәр белән атлап китәр
Иңен куеп иңнәргә —
Сәүдәгәр Галим кызы,
Авылның таң йолдызы.

Кызның тик бер карашыннан
Кабына күпме өметләр.
Юлларына гөл сибәргә
Әзер барлык егетләр.

Әй билләре, билләре —
Көнләштерә гөлләрне.
Бөгелә-сыгыла атлаганда
Түгеләдер сулары.

Борма-борма сукмаклары
Гүя йолдыз юллары.
Йолдызларга кемнең генә
Җитәр икән буйлары?!

* * *

Димтамактан Кызылъярга
Килен төшә пар атта.
Дугадагы кыңгыраулар
Як-якка моң тарата.

Кошлар һавага күтәрә
Кыңгыраулар тавышын.
Җырлар белән юллар куша
Кешеләрнең язмышын.

Ык буенда үскән егет
Дим буе чибәренә
Йолдызлар аша юл салды —
Иреште теләгенә.

Кавышты ярсу дулкыннар,
Дим белән Ык кушылды.
Ә хыяллар зәңгәр күктә
Тургай булып очынды.

Кәккүкләр бу гашыйкларга
Тигез гомер юрады.
Ләкин юллар гына никтер
Бик үк тигез булмады.

Еллары китте болганып,
Бөтен нәрсә буталды.
Галим байның йортларын да
Үз куенына ут алды.

Дөрләп янды таш кибетләр,
Ут капты диварларга.
Бу ялкынның сөремнәре
Җитте Кызылъярларга.

* * *

Галим байның иркә кызы —
Чибәр Бибигафифә
Гел наз өчен яратылган
Иде дә бит югыйсә...

Тик дөньялар бармый шул ул
Син уйлаганча гына:
Кинәт атың егылып үлә,
Йә тәртәң шартлап сына.

Каласың кара урманда,
Белмисең ни эшләргә.
Китәсең чишмәләр эзләп,
Ятып суын эчәргә.

Галим байның төпчек кызы
Чибәр Бибигафифә —
Үзе тапкан чишмәләрнең
Суларын эчә-эчә,

Китте бормалы юллардан
Сөйрәп язмыш арбасын.
Арбасына утыртты ул
Үзенең алты баласын.

Яндырды сугыш ялкыны
Пар канатның сыңарын.
Җиңелмени ялгызларга
Үтү гомер юлларын!

Сыңар канат белән хәтта
Оча алмый бөркетләр.
Бөркетләр менмәс җирләргә
Менде әнкәм кебекләр.

Яралы канатларыннан
Җиргә тып-тып кан тамды.
Алар каны тамган җирдә
Ал гөлләр үсеп калды.

* * *

Акты сулар, акты сулар,
Акты сулар түбәнгә.
Сулар белән акмадың син,
Каршы йөзә белгәнгә.

Акты сулар, акты сулар
Күбекләнеп, болганып.
Еллар судай болганса да,
Син калмадың югалып.

Акты сулар, акты сулар
Ишә-ишә ярларын.
Ишелгән чакта ярларың,
Ничек түзде җаннарың?

Утыз биштә тол калдың да
Мәңге бетмәс моң алдың.
Аккан сулар уртасыннан
Күкрәк белән юл ярдың.

Акты сулар, акты сулар,
Акты суның салкыны.
Сулар булып акты еллар
Синең йөрәк аркылы.

Акты сулар, акты сулар
Бер болганып, бер тынып.
Юшкыннары йөрәгеңдә
Кала барды утырып.

* * *

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр
Кемнәр бии очынып?
Бертуктаусыз биюче ул
Әнкәбезнең орчыгы.

Кыштыр-кыштыр,
кыштыр-кыштыр
Җеп савыла кабадан.
Гомер җебен урап булмый
Йомгакларга яңадан.

Тукы-тукы, тукы-тукы...
Бу соң нинди тавышлар?
Киндерләр булып тукыла
Безнең гомер, язмышлар.

Келтер-келтер, келтер-келтер
Тегү тегә машина.
Алты бала үсеп килә,
Кием кирәк барсына.

Кабына-сүнә, кабына-сүнә
Җиделе лампа өстәлдә.
Лампаларда майлар бетсә,
Әнкәм өмете өстәлә.

* * *

Йолдызсыз, айсыз —
Көн шундый кара.
Шомлы каралык
Өннәрне ала.

Яшен кылычы
Күкләрне кисә.
Болытлар җиргә
Теленеп төшә.

Күкләр күкри,
Таулар тетри.
Яшен ташларын
Кем җыеп йөри?

Чү, тукта, бу бит
Безнең әнкәбез.
Утлы ташларны
Сүндерә тиз-тиз.

Ул ташлар безгә
Тимәсен, дидер.
Без яшеннәрдә
Көймәсен, дидер.

Үзенең инде
Учлары пешкән.
Яшен эзләре
Йөзенә күчкән.

Кычкырам аңа:
— Әнкәй, янасың!
Тик еллар аша
Бармый авазым.

Тавышым кире
Үземә кайта —
Җанда мең төрле
Сорау уята.

* * *

Әни, сине нинди җилләр екты?
Хәер, моны нигә сорашам!
Җиңелрәк яшәр идең, бәлки,
Зарлар түгеп ешрак еласаң.

Еламадың шул син, еламадың,
Булганда да яшәү бик авыр.
Кайчагында, бәлки, җирне тырнап
Елаулар да кирәк булгандыр.

Болыт булып кайгы ишелеп төште,
Иңнәреңә ничә тапкырлар.
Мондый авырлыкка түзә алмый
Үкереп елар иде батырлар.

Ә син һаман эшли генә белдең,
Яшь түкмәдең, бары тир түктең.
Дөньяларны бераз турайтыйм дип,
Көнне, төнне белми бил бөктең.

Тураймады ләкин дөньялары,
Бөгелсәң дә җиргә кадәрле.
Тормыш сине көлтә итеп сукты,
Тормыш сине җилдә җилгәрде.

Елый алганнарның кайгылары
Яшьләр белән бетте юылып.
Синекеләр бәгырь түрләренә
Ташлар булып барды җыелып.

Ник соң, әни, ыграк еламадың,
Чыгармадың тышка зарларың?
Күпләр белмәделәр
Йөрәгеңдә
Нинди утлар дөрләп янганын.

* * *

Йоклый алмыйм, бәргәләнәм,
Тәрәзәм карый Айга.
Әйтче миңа, якты Аем,
Әнкәмнең җаны кайда?

Оҗмахлар түрендәме ул,
Җимешләр илендәме?
Сөтле-баллы елгаларның
Кушылган җирендәме?

Укыган намазларының
Күрәме савапларын?
Мең төрле сорауларына
Таптымы җавапларын?

Һаман безнең хакта уйлап
Өзелмиме үзәге?
Кылган гамәлләребездән
Каралмыймы йөзләре?

Йоклый алмыйм, бәргәләнәм,
Җаным күккә тартыла.
Әллә әнкәм йөгереп үтә,
Әллә йолдыз атыла.

Күз алдымда яп-якты эз,
Сузыла да юк була.
Тамактагы кайнар төен
Яшьләр белән юыла.

* * *

Күнегә алмыйм һаман
син юклыкка,
Басуларны урый уйларым.

Менə-менə кайтып килерсең күк
Иңбашыңа салып урагың.

Төенчектə — «куян күчтəнəче»,
Без чабабыз синең каршыңа.
Кулларыңнан алып төенчекне,
Актарабыз ашыга-ашыга.

Анда була ипи кыерчыгы,
Йə бəрəңге — көлдə пешергəн.
Əле һаман җаннар актарыла
Ул чакларны искə төшерсəң.

Бер тапкыр да сорап карамадык:
«Ашадыңмы, əни, үзең?» — дип.
Уйларыңда синең үзең түгел,
Без идек шул, һəрчак без идек.

Иң тəмлесен безгə ашаттың син,
Иң матурын безгə кидердең.
Үзең өчен арып егылсаң да,
Безнең өчен торып йөгердең.

Нинди генə юллар үтмəдең дə,
Нинди генə сулар кичмəдең.
Упкыннарга төштең —
калкып чыктың,
Һичбервакыт түбəн төшмəдең.

* * *

Ташлар сайлыйм бүген,
ташлар сайлыйм,
Ошардаен сайлыйм күңелгə.
Ə уйларым барып укмашалар
Тамактагы кайнар төергə.

Кемнәр генә уйлап тапты икән
Таш куюны кабер өстенә?
Ай авырдыр, бигрәк авырдыр бит
Таш астында яткан кешегә.

Болай да бит кеше гомере буе
Йөк күтәреп йөри иңенә.
Торган саен йөге авырая —
Йөк өстенә йөкләр өелә.

Шушы йөкнең авырлыгы ега,
Бер көн килеп адәм баласын.
Китә кеше фани дөньялардан
Ялый-ялый канлы ярасын.

Дөнья, дөнья, синең серләреңә
Төшенеп җитеп булмый һич кенә.
Нигә инде таш бастыру кирәк
Газиз кешеләрең өстенә?!

Күңелемдә уйлар өермәсе,
Яшьсез генә елый йөрәгем.
Мәңгелеккә инде, мәңгелеккә
Ауды җирдә иң нык терәгем.

*1996*

# *Без*

*Гомер тора җәйдән, кыштан,*
*Яздан, көздән.*
*Дөнья тора*
*«Син»нән, «Мин»нән*
*Һәм дә «Без»дән.*

## *Мактау*

Мактау — шәраб,
Бик аз эчсәң,
Куя ярап:
Арта көчең,
Балкый йөзең,
Гөрли эшең.

Китсә күпкә,
Менсәң күккә,
Ул исертә
Һәм сикертә,
Һәм тилертә.

*1999*

## *Гөл тамыры*

Җил актара кар катламын
Китап актарган сыман,
Ахры, җәйнең бер чәчәген
Арага салып куйган.
Китап эчендәге чәчәк
Чәчәк түгел шул инде.
Кар астында чәчәк булмау
Гаҗәп түгел шул инде.
Ә җил һаман кар китабын
Актара да актара.
Кар астында хәтер булып
Гөл тамыры саклана.

*1999*

## *Иске ел*

Үтеп баручы ел,
Соңгы сулышын алып,
Ята кар-түшәктә.
Әйләнгән ул хәзер
Эшкә ярамаган
Хәлсез карт ишәккә.

Аны санламыйлар,
Аны данламыйлар,
Булмаган ул гүя.
Ауный картайган ел
Салкын түшәгендә
Яшен коя-коя.

Һәркем тора көтеп,
Бәхет өмет итеп,
Туар Яңа елны.
Кулларында — чәчәк,
Табыннарда — чәкчәк,
Хыял матур, олы.

Бер ел үтәр-китәр,
Кирәклеге бетәр
Бу Яңа елның да.
Ак кар булыр түшәк,
Тагын бер карт ишәк
Ятыр җир куйнында.

*1999*

## *Кабырга*

Хатын-кызлар безнең кабыргадан
Яратылган — белми кем генә?
Белә торып, шушы кабырганың
Аптырыйбыз кәкрелегенә.

Турайтмакчы булып кабырганы
Тырышабыз гомер буена.
Күпме генә сукма — ул тураймый,
Йә уалып бетә, йә сына.

Тимердән дә түгел, камырдан да,
Кабырга бит була сөяктән.
Ходай аны юкка яратмаган
Умырып алып безнең күкрәктән.

— Мә! — дигән Ул,—
кәкре кабырганны
Үзеңә бирәм гомер итәргә.
Йә син аны кимереп читкә ыргыт,
Йә йолдыз ит, күтәр күкләргә.

Кабыргалар, кәкре кабыргалар,
Сез бит безгә тигән өлешләр.
Без эт булсак — сез бер сөяк кенә,
Без ир булсак — алтын-көмешләр.

*1999*

## *Көч кирәк*

Алтыным, диярләр,
Көмешем, диярләр.
Һич ашап туймаслык
Җимешем, диярләр.

Күңеленә салып куй:
Алтыннар сатыла.
Җимешләр, кимереп,
Бер читкә атыла.

Былбылым, диярләр,
Күз нурым, диярләр.
Син —
    җырлап туймаслык
Үз җырым, диярләр.

Истә тот: былбыллар
Сайрамый гел генә.
Иң матур җырлар да
Тияләр күңелгә.

Бар нәрсә туйдыра,
Бар нәрсә искерә.
Сөюгә дә хәтта
Икенче төс керә.

Әзер бул тормышның
Рәхимсез көченә.
Бик күп көч кирәк
Яшәргә кешегә.

*1999*

## *Пошп*

Алан уртасында поши тора
Мөгезе белән күкне күтәреп.
Мең яшәрлек мәгъруур иманнәрне
Караш-кылычыннан үткәреп.

Читтән-читтән бүре өере уза
Койрыкларын кысып — шүрләүдән.
Сокланып бу урман патшасына
Бөркет үрелеп карый үрләрдән.

Әллә нинди көч бөркелеп тора
Бу җәнлектән тирә-якларга.
Әйтерсең лә туган ул урманның
Кыргый матурлыгын сакларга.

Былбыл куна аның мөгезенә, —
Сайрар өчен нинди шәп урын!
Яфраклардан яфракларга бәрелеп
Күтәрелә күккә һәр җырың.

Поши тыныч, хәтта бераз гамьсез,
Үз көченә шундый ышанган.
Карурманнар аның йөрәгенә
Таулар аударырлык көч салган.

...Менә кинәт мылтык шартлап китте,
Асты-өскә килде урманның.
Дөбер-шатыр күкләр ишелеп төште
Күкрәгенә кыргый боланның.

Һәм Матурлык алан уртасында
Җирне тырный-тырный җан бирде.
Шуны гына көткән ач бүреләр
Ботарлап та аны өлгерде.

Матурлыкка гел куркыныч яный.
Яхшылыкны җимерә яман көч.
Бер карыйсың —
                    дөнья шундый матур,
Бер карыйсың — яшәү куркыныч.

*1999*

## *Йолкыш эт*

Бар этләр ялагайлана
Бер йолкыш кына эткә.
Кайберсе аның танавын
Хәтта ялап ук китә.

Кайсы исни койрык астын,
Хушбуй иснәгән кебек.
Йөри бар да койрык болгап,
Зур эш эшләгән кебек.

Койрык болгамаслар иде,
Яшисе бар — тормыш бит.
Хуҗа белән бер табактан
Ашый чөнки йолкыш эт.

*1999*

* * *

Аерылганны аю ашар,
Бүленгәнне — бүре.
Халкым, синең сафларыңа
Нинди җилләр керде?

Кемдер болгар, кемдер татар,
Ә кемнәрдер нугай.
Бүреләр ботарласын, дип
Бүленәбезме шулай?

Кем керәшен, кемдер мишәр,
Ә кемнәрдер типтәр.
Саный китсәк, татар исеме
Бер дистәгә җитәр.

Монгол булып та йөрдек без,
Тагып шундый ярлык.
Аерыла, бүленә торгач,
Шушы хәлгә калдык.

Аерылганны, бүленгәнне
Көтә аю, бүре.
Тупланмасак бер йодрыкка,
Калырбызмы тере?!

*1999*

## *Тора-бара*

Ни өчен без яратабыз
Этләрне, мәчеләрне?
Эттән кадерсез итәбез
Иң якын кешеләрне?
        Хайваннарның
                теле юк шул,
        Алар безнең колыбыз.
        Этләр риза, булса әгәр
        Ялар өчен кулыбыз.
Кайвакытта алларына
Калган аш куйгаласак,
Койрык болгап йөри алар,
Шуңарга да алар шат.
        Ә кирәкләре беттеме,
        Куалыйбыз урамга.
        Йә адаштырып кайтабыз,
        Алып барып урманга.
Кешеләр шул җайсызрак,
Нидер сорарга мөмкин.
Сораганын бирмәсәләр,
Хәтта дуларга мөмкин.
        Урамга да куып булмый,
        Бетте, диеп, кирәге.
        Куып чыгарсаң да кала
        Өйдә аның өрәге.
Тора-бара бетәр, бәлки,
Җир йөзендә кешеләр,
Һәр ярыктан карап торыр
Эт, песи һәм күселәр.

*1999*

## *Ярлыка*

Мал өчен, дан өчен түгелә кан,
Җир җитми — күңелләр тарлыкка.
Нәфсенә кол булган бәндәңне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Күпләрнең өмете өзелгән,
Ышанмый хакыйкать барлыкка.
Адашкан, саташкан җаннарны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Кешеләр үзенә кул сала,
Түзмичә изелү-хурлыкка.
Сабыры төкәнгән мескенне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Юләрләр хакимлек иткәндә,
Инсаннар әйләнә сарыкка.
Сарыкка әйләнгән инсанны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Сугышлар. Суешлар. Кырышлар.
Халыклар ачулы — халыкка.
Гөнаһка баткан бу дөньяны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

*1999*

* * *

Газраилгә эш кимеде бугай,
Кешеләр үтерә хәзер бер-берләрен.
Мөнкир-Нәнкир, сорау алыр өчен,
Эзләп таба алмый каберләрен.

Ишетмичә генә калдык, ахры,
Исрафилнең җиргә сур өргәнен.
Күреп торабыз бит әрвахларның
Кабереннән кубып йөгергәнен.

Җәннәтләрнең серле капкалары
Ябыламы әллә ачыламы?
Бу әрвахлар кая йөгерә соң? —
Һәммәсе дә Алла каршынамы?

*1999*

## *Шул бер сүз инде*

Үлем түшәгенә егылгачтын
Яман телле дәһри бер бәндә,
Якыннары аңа ялвардылар:
— Соңгы сүзеңне син әйт, әйдә.

— Ни көтәсез миннән? —
диде дәһри,—
Минем һаман шул бер сүз инде...
Һәм актык кат, бөтен көчен куеп,
Җиде катлы итеп сүгенде.

*1999*

## *Өй эте*

Күрше фатирда эт елый,
Җанга тия тавышы.
Җиңел түгелдер, күрәсең,
Өй этенең язмышы.

Бәлки, ул сагынып елыйдыр
Ирекгәге көннәрен.
Уйлыйдыр гүзәл җәйләрнең
Ай-йолдызлы төннәрен.

Йә карга ятып аунавы
Төшәдер дә исенә,
Рәнҗидер үзен таш йортка
Ябып торган кешегә.

Ә бит ул ирекгә чакта
Шаян иде, шук иде.
Өреп тә таралмый торган
Сагышлары юк иде.

Кызык иде дөнья шундый,
Киң иде, иркен иде.
Тамак ярым ач булса да,
Тормышы бөтен иде.

Күрше фатирда эт елый,
Таш диварга баш орып.
Буламыни соң ирекне
Ипигә алыштырып?

*1999*

## *Теләсә ничек алдый*

Югарыдагы түрәләр
Шуны бик яхшы белә:
Ач кешенең күңелендә
Горурлык бик тиз үлә.

Шуңа күрә алар безне
Көн-төн кычкыртып талый:
Хәерче булдымы халык,
Ирекле була алмый.

Тәмам котны алыр өчен,
Сугышлар белән яный.
Белә чөнки: куркак халык
Көрәшче була алмый.

Анда — сугыш,
                монда — сугыш,
Уйларга вакыт калмый.
Уйсыз халыкны һәр юләр
Теләсә ничек алдый.

*1999*

## *Көзге бакча*

Җимеше җыелып беткән,
Хуҗасы кайтып киткән.
Шәп-шәрә агачларга
Салкын яшь коела күктән.

Сузылып ятып җил йоклый
Сары яфрак өстендә.
Җәйнең назлы гөлләрен
Күрми микән төшендә?

Бушап калган оялар
Эленеп тора ботакта.
Былбыллар бер-беренә
Йөрмәс инде кунакка.

Бакчаның уртасында
Басып тора карачкы.
Үрелеп-үрелеп карый ул —
Язда бугай карашы.

*1999*

## *Нигә?*

Нигә китә икән бу кошлар?
Канатларын сынар өченме, —
Күбрәк юллар узар өченме?
Куркытамы әллә соң кышлар?
Нигә китә икән бу кошлар?

Чиксезлекләр үзенә тартамы,
Очышларда гайрәт артамы?
Ышыкланыр өчен суыктан
Монда юкмы оя-куышлар?
Нигә китә икән бу кошлар?
Аларны да нужа йөртәме,
Чит җирләрдә бәхет көтәме?
Бәхетенә барып җитмичә
Өзелмиме икән сулышлар?
Нигә китә икән бу кошлар?

Җимеш кенә үскән илләрдә,
Кышлар булмый торган җирләрдә
Күбрәктер бит гүзәл гөлләр дә,
Оҗмахларга тиңдер тормышлар —
Нигә кайта икән бу кошлар?
Нигә?

*1999*

## *Намусыңа күз ташла бер*

Син үзеңне беләсеңме,
Киңме күңелең, тармы?
Мохтаҗларга, бер булса да,
Ярдәм иткәнең бармы?

Бармы егылып ятканга
Тор, диеп, кул сузганың?
Әллә үтәсеңме бары
«Мескен» диеп кызганып.

Иң яраткан ризыгыңны
Куясыңмы кунакка?
Әллә кеше күрмәсен дип,
Яшерәсеңме еракка?

Кеше күңеленнән кер эзләп
Уздырганчы гомерне —
Намусыңа күз ташла бер,
Чистамы ул, керлеме?

*1999*

## *Һәрвакытта янәшә*

Бәхет килә кайчагында
Кызлар кыяфәтендә.
Ә бераздан очып китә
Кошлар кыяфәтендә.

Кайвакыт килеп керә ул
Кесәгә акча булып.
Бераздан каласың янә
Таланган бакча булып.

Йә дустың булып килә дә,
Дошманың булып китә.
Дусны дошман ясар өчен
Бер ялгыш сүз дә җитә.

Бәхет белән бәхетсезлек
Һәрвакытта янәшә —
Берсе йөрәгең каната,
Икенчесе бәйләшә.

*1999*

## *Агач ат*

Нинди хикмәте булгандыр —
Без бәләкәй чакларда
Чаба идек урам буйлап
Гел-гел таяк атларда.

Кызык иде, рәхәт иде
Шул атта чабулары.
Атта чабып баргангамы —
Белмәдек аруларны.

Үтте-китте балачаклар,
Ташладык таяк атны.
Томырылдык киләчәккә
Аермый кара-акны.

Алда безне акбүз атлар
Көтәдер кебек иде.
Үрелсәк, буйлар хыялга
Җитәдер кебек иде.

Акбүз ат өмет иткәндә,
Балачак калгач артта —
Атландырдылар түрәләр
Яңадан агач атка.

*1999*

## *Таш гасыр*

Таш гасыры үтте, диләр,
Таш гасыр килә генә.
Ташлар үсеп чыкты хәзер
Күпләрнең йөрәгенә.

Ул ташлардан таулар үсеп,
Басылып калса Кеше —
Тауларны ишеп чыгарга
Җитәрме аның көче?!

*1999*

## *Каеннар иртәрәк уяна*

Каеннар яшь кыздай
дәртлеләр,
Каеннар тыялмый хисләрен.
Язларның бер нуры төшүгә,
Бөреләр ачалар түшләрен.

Иманнәр тирәнтен йокыда,
Алар соң тоялар яз ямен.
Җилбәзәк каеннар җилләргә
Күтәреп калалар күлмәген.

*1999*

## *Дөнья, ахры, шулай төзелгән*

Хаҗга бару хәзер җиңеләйде,
Юл газабы дигән газап юк:
Фәрештәдәй ак канатын җәеп
Очырта да китә самолет.

Күпләр йөри казна исәбенә,
Хаҗ — аларга кызык сәяхәт.
Алар ашый король табагыннан,
Нишлисең бит — шундый сәясәт.

Белмәсә дә хәтта бисмилланы,
Һәр чиновник — хаҗи хәзрәт.
Йөри алар үзләренә шулай
Оҗмахлардан урын әзерләп.

Ә кемнеңдер әле урыны юк
Намазлыгын җәяр өчен дә.
Андыйларның, укылмаган килеш,
Догалары үлә эчендә.

Оҗмахка да өмет итми ярлы,
Өмете аның күптән өзелгән.
Савап белән гөнаһ
кушылып беткән,
Дөнья, ахры, шулай төзелгән.

*1999*

## *Могҗизалар арта*

Безне юктан бар итүче,
И кодрәтле Алла —
Синең барлыгыңны раслап,
Күктә кояш яна.

Сүнмәс ул, мәңге яначак,
Сүндермәсәң Үзең.
Каралмас, безнең гөнаһлар
Тапламаса йөзең.

Күкнең җиде каты булып,
Салават күпере калка.
Дөнья иманга килмичә
Ачылмас күк-капка.

Һәр төн йолдызлар кабына
Синең кодрәт белән.
Күңелгә ышаныч иңә
Төрле гыйбрәт белән.

Диңгезнең күкрәген ярып,
Утлы таулар калка.
Күзләр ачыла барган саен,
Могҗизалар арта.

*1999*

## *Эшкә керәм*

— Җитте, мин дә эшкә керәм! —
Диде иренә хатын,—
Бу ике катлы өйдә мин
Берүзем нишләп ятыйм?
— Нәрсә җитми тагын сиңа? —
Диде ир, кырыс кына,—
Йөз күлмәгең, ун пәлтәң бар,
Өйдә ят тыныч кына.
Муеныңда алтын чылбыр,
Ун бармакта — ун йөзек.
Яшисең бит болай да син
Байлык эчендә йөзеп.
— Әйе,— диде хатыны аңа,—
Ун пәлтәм бар, йөз күлмәк.
Алтын-көмеш әйберем дә
Бардыр инде бер чүлмәк.
Йә, бу кадәр байлыгымны
Нишләтим мин, нишләтим?
Эшләмәгәч, мин аларны
Кая барып күрсәтим?
Кемнәр алдында мактаныйм,
Кемнәрне көнләштерим?
Аларны күрүче юк, дип,
Мин бит гел янып йөрим.
Җитте, мин дә эшкә керәм,
Тыялмыйм йөрәгемне:
Һәркөн күрсәтеп кайтырмын
Бер яңа күлмәгемне.

*1999*

## *Юл калмас иде*

Башлаган эшең
Тукталып кала,
Алтын вакытың
Югалып кала;
Уйлар сүтелә,
Күңел кителә,
Өмет киселә,
Канат өтелә;
Тартыла кыллар,
Җитеп соң чиккә —
Очрыйсың да бер
Вәгъдәсезлеккә.

Зиһен тарала,
Йөзең карала,
Күгеңне каплап,
Болыт кабара;
Күз күрми башлый,
Эчтә үч кайный,
Яшен утлары
Дөньяны айкый;
Кояшның чите
Кителә күктә —
Очрыйсың да бер
Мәгънәсезлеккә.

Кеше — кеше дип
Санаса үзен,
Әйтер алдыннан
Үлчәсә сүзен;

Һәркемдә йөрәк
Барын уйласа,
Караса сиңа
Үз җаны аша —
Юл калмас иде
Вәгъдәсезлеккә.
Ким булыр иде
Мәгънәсезлек тә.

*1999*

## *Яшь килен төшәсе өй кебек*

Яз быел бик сәер кылана —
Ала да битләрдән бер үбеп,
Каядыр китә дә югала,
Вәгъдәсен оныткан кыз кебек.

Көтәсең, көтәсең — килми ул,
Чакырасың таулардан кул изәп...
Әллә ул бик артык тәкәббер,
Әллә ул бик артык җилбәзәк.

Барыбер килерен белсәң дә,
Көтәсең сөенеп-көенеп.
Күңелләр капкасы шар ачык,
Яшь килен төшәсе өй кебек.

*1999*

## *Зур уңышлар яуладык*

«Кешеләрдә һәрбер нәрсә
Матур булырга тиеш».
Бер акыл иясе менә
Шулай дип әйткән, имеш.
        Бу сүзләрне безнең илдә
        Шик астына куймыйлар:
        Матур итеп алдашалар,
        Матур итеп урлыйлар.
Артыңа китереп тибәләр
Елмаеп-көлеп кенә,
Типкәнгә рәхмәт әйтәбез,
Башларны иеп кенә.
        Депутатлар трибунадан
        Матур вәгъдә яудыра.
        Ә хөкүмәт, матур итеп,
        Ыштаныңны салдыра.
Матур итеп сүгенәбез,
Килешә безгә бар да.
Матур җирләрне күрсәтеп
Йөрибез урамнарда.
        Безнең илдә һәркем гүзәл,
        Бездә һәр кеше матур.
        Елмаеп кесәгә керә
        Һәр шпана, һәрбер бур.
Матурлыкта зур уңышлар
Яуладык без галәмәт.
Моннан да матур булырга
Мөмкин түгел, җәмәгать.

*1999*

## *Яңа таяк*

Тәрәккыят, тәрәккыят,
Яшәсен тәрәккыят!
Тәрәккыятле булырга
Җитми тик яңа таяк.

Әгәр күчсәк «Яңалиф»кә,
Ягъни яңа таякка —
Баш та кирәк булмаячак,
Һәм кирәкмәс аяк та.

Ачылыр дөнья капкалары
Киң булып һәр тарафка.
Төркияләргә йөрербез
Чабып кына пар атта.

Америка да каршылар,
Келәм җәеп юлларга.
Каршыламыйча карасын —
Таяк бар бит болгарга.

Шушы таягыбыз булса,
Урыс та хөрмәт итәр.
Тәрәккыят учагыбыз
Кабыныр, дөрләп китәр.

Чын бәхеткә ирешергә
Калды бик чак-чак кына:
Үз-үзебезне тукмарга
Җитми шул таяк кына.

*1999*

## *Шәфәкъ*

Офыкларда шәфәкъ уты яна,
Шундый серле аның балкышы.
Чагыла анда бөтен гомеремнең
Язы, көзе, җәе, ак кышы.

Болытлар да әнә кып-кызыллар,
Нурлар тама җиргә алардан.
Түп-түгәрәк кызыл алма булып,
Кояш карап тора таулардан.

Урманнарга хәтта утлар капкан,
Һәрбер агач яна шәм булып.
Сулар ага кабаланмый гына,
Ниндидер бер гүзәл гамь булып.

Илаһи бер тынлык табигатьтә,
Җиргә җәелеп яткан уйчанлык.
Һавадагы җете бу төсләрне
Учларыңа алып кысарлык.

Дөнья чумган шәфәкъ балкышына,
Җир коена шушы балкышта.
Ал яулыгын болгап китеп бара
Ал болытлар кояш батышка.

*1999*

## *Җан тартышы*

Су өстендә дулкын булып
Бәргәләнә бер җан.
Тыныч кына йөзә алмый,
Ярлар аңа кысан.

Акчарлакларга ияреп,
Күккә очмак була.
Күкрәгенә ал кояшны
Алып кочмак була.

Ярсып-ярсып, гайрәтләнеп
Сикерә ул ярга.
Сикереп чыгып чапмак була
Иркен болыннарга.

Таулар аны үзенә дәшә,
Әйдә мен, дип, монда —
Таулардан шәбрәк күренә
Иксез-чиксез дөнья.

Бәргәләнә, чәбәләнә
Су өстендә дулкын.
Күкләр аны өскә тарта,
Аска сөйри упкын.

Күк белән җир арасында
Әй тартыша хөр җан.
Бу тартышны сүзсез генә
Карап тора җиһан.

*1998*

## *Кышкы уйлар*

Кышның матурлыгы ак карларда,
Тартылабыз һәрчак аклыкка.
Матурлыкка урын табылып тора
Йөрәк дигән серле сандыкта.

Аклык кирәк безгә, аклык кирәк,
Бик күбәйде җирдә каралык.
Сокландырсын җанны ап-ак карлар,
Карыйк җиргә һәр көн таң калып.

Җир өстенә карлар ява әнә,
Онытмагыз, диеп, аклыкны.
Күңелләргә аклык итеп ябыйк
Күктән яуган шушы байлыкны.

Каралыктан сырхауланган җанны
Дәваласын әле шул аклык.
Кергә күмелеп озак яттык инде,
Ак чәчәкләр булып бер калкыйк,
Бер калкыйк!

*1998*

# *Таулар белән иңдәш булган кеше*

*Ринат Галиевнең*
*60 яшенә багышлыйм*

Син — генерал!
Иңнәреңдә синең
Булмаса да алтын погоннар.
Алтын погонлылар көнләшерлек
Ил каршында синең даның бар.

Биеклекнең чакрымнары авыр,
Тозлы тирләр ага яңактан.
Күпме юл узылган —
Генералга
Күтәрелер өчен солдаттан.

Шарламада туган шаян малай,
Урсаланың йөзеп суында —
Көч җыйгансың,
беләк ныгыткансың,
Ат көткәнсең уйсу болында.

Урсаланың ярсу дулкыннары
Аккан синең йөрәк аркылы.
Хыялыңны күккә алып менгән
Төнге учакларның ялкыны.

Таулар сине биеклеккә дәшкән
Үзләренә тиңдәш иттереп —
Офыкларга тераў булсын өчен
Иңнәренә иңдәш иттереп.

Иптәш сүзе инде искерсә дә,
Индәш сүзе мәңге искермәс.
Таулар белән индәш булган кеше
Алтмыш яшьтә әле егет калыр,
Җитмештә дә әле бил бирмәс.

*1998*

* * *

---

Туган якны сайлап алып булмый,
Сайлап булмагандай әнкәңне,
Иң ямьле як безнең яклар, дибез,
Булмаса да хәтта бик ямьле.

Иделләрдән күбрәк дан җырлыйбыз
Тыйнак кына аккан елгага.
Калкулыгын биек таулар итеп
Күрсәтәсе килә дөньяга.

Билчәннәрен гөлгә тиңлибез без,
Әрәмәсе була — карурман.
Гел матурлык, гел гүзәллек кенә
Эзли күңел туган ягыннан.

Кешеләре үз куллары белән
Кырып барсалар да бар ямьне.
Һаман матур, һаман әйбәт, дибез,
Хурлап буламыни әнкәңне?!

*1998*

## *Халыклар язмышы бар*

Якташлар, бәлки, сез миннән
Күбрәкне көткәнсездер.
Хыялыгызда мине сез
Пәһлеван иткәнсездер.

Кичерегез, күңелегезне
Аңлый алмаган булсам.
Сезнең данлы эшегезне
Данлый алмаган булсам.

Юкса минем иҗатымның
Иң биек ноктасында
Сез торасыз, якташларым,
Мәйданнар уртасында.

Керде, керде туган якның
Бормалы сукмаклары.
Шигыремдә кошлар тулы
Әрәмә куаклары.

Җырларымның моңлысында
Былбыллар тавышы бар.
Ерак тарихка тоташкан
Халыклар язмышы бар.

Ык елгасы иҗатымның
Уртасыннан акты гел.
Өянкеләр иптәш булып
Янәшәмнән чапты гел.

Тауларга биеклек салдым,
Алып туган халкымнан.
Кояшны да «чыгардым» мин
Өем ташлар артыннан.

Авылымның өсләренә
Йолдызлар, айлар сиптем.
Туган якның һәрбер гөлен
Иң гүзәл чәчәк иттем.

Данладым сезне, якташлар,
Мин данлый алган чаклы.
Ләкин дөньяда һәрнәрсә
Була бит ике яклы.

Даннар килә-китә тора,
Дөнья тора үзгәреп.
Зур калырбыз, бер-беребезне
Барсак кына күтәреп.

*1998*

* * *

Сөенәләрдер бакалар
Ямьсез булганнарына,
Сазлы, ләмле һәм болганчык
Күлдә туганнарына.

Үз-үзеңне саклар өчен
Ямьсезлек тә кирәк шул.
Кыяфәте ямьсезләргә
Үрелә бит сирәк кул.

*1998*

## *Газаплы яшәү бара*

Ай йөзә күк диңгезендә,
Охшап ап-ак корабка.
Әйтче, Ай, әгәр яраса,
Юлың кайсы тарафка?

Киләчәккә барасыңмы,
Төяп серле яктылык?
Барып җиткәнче, корабың
Бетмәсме соң ватылып?

Күрәсеңме, күк йөзендә
Шайтаннар ук атыша.
Алар, күккә аяк терәп,
Синең өчен тартыша.

Кабып йотмак була берсе,
Берсе — турап ыргытмак.
Берсе бәреп төшерергә
Тотып чаба зур тукмак.

Явызларга, Угрыларга
Нигә кирәк якты Ай?
Күкнең шәмен сүндерергә
Кара җаннар эзли җай.

Шуларны күргәч, күңелне
Кинәт кенә шом баса.
Кара төндә җен-пәриләр
Әгәр сине урласа?

Йә уклардан тишкәләнеп,
Җиргә төшсәң ватылып?!
Киләчәккә ничек барыр
Без калдырган яктылык?

Җирдә, күктә, бар тарафта
Көрәшә Ак һәм Кара.
Шушы көрәш арасында
Газаплы яшәү бара.

*1998*

* * *

---

Бу дөньяның хикмәтләрен
Аңлап та булмый хәтта —
Акыллылар акыл җыя,
Юләрләр акыл сата.

Исерекләр ил җитәкли,
Аеклар көтү көтә.
Сукырлар юл күрсәтәләр,
Телсезләр тел өйрәтә.

*1998*

## *Кыйблаң кайда?*

Нидер кылган булабыз,
Нидер кырган булабыз;
Нидер чәчкән булабыз да
Нидер урган булабыз.

Ипсез җирне иплибез,
Искеләрне сиплибез.
Кая гына үрелмибез,
Кая гына җитмибез.

Алай иткән булабыз,
Болай иткән булабыз.
Ансын сүтеп, монсын корып,
Дөнья көткән булабыз.

Әй тырышып йөрибез,
Әй тырмашып йөрибез.
Тик эш булмый эшебез,
Юкка китә көчебез.

Утыртабыз — ул ава,
Без куабыз — ул чаба.
Кыек басып, әй дөнья,
Ашыгасың кая таба?

Кыйблаң кайда, әй дөнья,
Борылма уңга, сулга.
Уңда — упкын, сулда — саз,
Алып чык бер хак юлга.

*1998*

## *Фасил Әхмәткә*

Менә син дә китеп бардың, Фасил,
Киткән «Аккошлар»ың артыннан.
Ул аккошлар синең пакь җаныңны
Саклап барыр җилдән, салкыннан.

Якын иттек без гел бер-беребезне,
Аралашмасак та бик артык.
Җаннарыбыз безнең кардәш иде,
Шул кардәшлек торды гел тартып.

Зарланышып ала идек кайчак
Озак-озак итеп телефоннан.
Трубкаңны куеп рояленә,
Бер көй уйный идең син соңыннан.

Әйтә идең: шәп чыккан бит, малай,
Музыкада бу бит — яңалык.
Чукынып китсен, хәер, яңалыгы,
Ничек анда синең тазалык?

Язасыңмы һаман? Язасыңдыр.
Үземә дә бу эш бик таныш.
Тик «тегендә» генә булыр, ахры,
Синең белән миңа тукталыш.

Без бөекләр... Юк, юк каршы килмә,
Без бит моны яхшы беләбез.
Яраларны яшереп бәйли-бәйли,
Карурманнан җырлап киләбез.

Бездән чыкмый сыкрау авазлары,
Безнең тавыш һаман көр әле.
Мин уйнармын сиңа яңа бер көй,
Такси ал да миңа кил әле.

Хәер, килмә, үзем барам сиңа,
Эләктерәмен дә бер ярты,
«Генераллар» булып утырырбыз,
Соңга калсак — күктә Ай якты...

...Шулай диеп шылтырата идең,
Уенын-чынын кушып гел бергә.
Вакыт күп тә, гомер кыска икән,
Кунак-кунак булып йөрергә.

Ашыга-ашыга китеп бардың,
Фасил,
Киткән «Аккошлар»ың эзеннән.
Аккошларның ап-ак каурыйлары
Каберең өсләренә сибелгән.

*1998*

## *Бар*

Балдан да баллырак итеп
Сөйләүчеләр бар.
Тормышын татлы сүз белән
Көйләүчеләр бар.

Әремнән ачырак итеп
Сөйләүчеләр бар.
Бер сүз өчен гомере белән
Түләүчеләр бар.

## *Бишек җыры*

Мин сине күкләрдән эзләп,
Йолдызлардан таптым.
Шуңа күрә йөзләрең ак,
Йөзләрең якты.

Коендырдым Ай нурында
Төннәр буена.
Ай нурлары кереп тулган
Синең куеныңа.

Былбыллар бәхет теләде
Сиңа таңнарда.
Алып китте сагышларың
Сары салларда.

Җәйге кояш битләреңә
Ай нурын якты.
Шуңа күрә йөзең якты,
Телләрең татлы.

*1998*

* * *

Таралыр, диделәр —
Таралмадың.
Яңарыр, диделәр —
Яңармадың,
И Россия,
        мескен Россия.

Сиңа ияргәннәр
Синең хәлгә төште.
Сиңа ышанганның
Мең кат авызы пеште.

Юлың табалмыйсың —
Син ялгышлар иле.
Сиңа ләгънәт ява —
Син каргышлар иле.

Телең тулы ялган,
Авызың тулы хәмер.
Җирең тулы кан-яшь,
Илең тулы җәбер.

Таралыр, диделәр —
Таралмадың.
Яңарыр, диделәр —
Яңармадың,
И Россия,
        исерек Россия!

*1998*

## *Ай белән сөйләшү*

Нихәл, Ай, исәнме, саумы?
Нигә үзгәргән төсең?
Әллә салым салдылармы
Җирне яктырткан өчен?!

Бәлки, шашлык кыздырадыр
Яңа байлар — өстеңдә.
Шулар утының корымы
Чагыладыр төсеңдә.

Әллә өслегең актарып,
Байлар коттедж төзиме?
Шул йортларның күләгәсе
Каралттымы йөзеңне?

Зөһрә кызның хәле ничек,
Түгелмиме сулары?
Берәр алыпсатар белән
Булмадымы туйлары?

Әйтче, Аем, яшермичә,
Нигә соң качкан төсең?
Әллә борчыласыңмы син
Җирнең язмышы өчен?

*1998*

* * *

Беткән инде туган якта
Безне үстергән оя.
Очтык-очтык, каурыйларны
Ят җиргә коя-коя.

Йөрәкләрдән каннар тамды
Каурыйлар белән бергә.
Заманнар күпме җилгәрде
Безнең җаннарны җилдә.

Иләндек, озак иләндек
Тормышның иләгеннән.
Ярый, җепләр өзелмәде
Туган як йөрәгеннән.

Бәлки, шул ярдәм иткәндер
Калкып чыгарга кабат.
Кайтабыз туган якларга,
Читтә ныгытып канат.

*1998*

## *Туганнарга*

Тоштек тә без әнкәбезнең
Бәгыреннән өзелеп,
Очып киттек еракларга,
Кошлар кебек тезелеп.

Бара-бара юлларыбыз
Тартты төрле якларга.
Болытлар килеп уралды
Безнең ак канатларга.

Җил-давыллар каурыйларны
Алдылар йолкып-йолкып.
Үрелсәк тә гел биеккә,
Булмады йолдыз тотып.

Канат очларыннан күпме
Кан тамды кыяларга.
Кыялар аша үтә шул
Юллар зур хыялларга.

Таралдык, сибелдек җиргә,
Гөл өздек үрләреннән.
Ләкин биек булалмадык
Әнкәбез йөрәгеннән.

*1998*

## *Тик шуларда яшәү дәвамы*

Таянырга ныклы иңнәр кирәк,
Яшәп булмый ныклы иңнәрсез.
Упкыннарга очар иде дөнья
Ныклы иңле таза ирләрсез.

Назлар өчен гүзәл гөлләр кирәк,
Яшәп булмый гүзәл гөлләрсез.
Бозлыкларга әверелер дөнья
Кайнар канлы нәзкәй билләрсез.

Дөньяны бит Наз һәм
Ныклык тота,
Тик шуларда яшәү дәвамы.
Юкка гына яратмаган Ходай
Җиргә Адәм белән Хаваны.

*1998*

## * * *

Шагыйрьлек тә,
пәйгамбәрлек кебек,
Бирелә бары Ходай тарафыннан.
Яза шагыйрь, каурый каләм алып
Фәрештәнең ап-ак канатыннан.

Шул каләмен күк нурына манып,
Ак кәгазьгә юллар тезә-тезә,
Халык күңеленә бара шагыйрь —
Мең-мең газапларга түзә-түзә.

*1998*

## *Ике фикер*

Бара ир белән хатын
Күзәтеп шәһәр халкын.
Әнә ашыга-ашыга
Бер кыз килә каршыга.

Кыскадыр итәкләре,
Ачыктыр күкрәкләре.
Җилләр ялгыш исеп куйса,
Күренер «хикмәтләре».

Күзәтә ир һәм хатын
Кызның алдын вә артын.
Хатын әйтә: — Оятсыз!
Ә ир әйтә: — Аh, шәп кыз!

*1998*

* * *

Дан яраткан кеше өчен
Иң матур җыр — үз исеме.
Тыңлап торырга әзер ул
Үз исемен көне-төне.

Үзен мактаучылар аңа —
Иң акыллы затлар.
Тәнкыйть сүзе әйтүчеләр —
Надан һәм ахмаклар.

*1998*

## *Рәхәтләнеп коена дөнья*

Сайрый бер кош. Аның өчен
Сәхнә — урман агачы.
Йотылып тыңлап утыра
Чәчәкләр — тамашачы.

Сайрый бер кош.
Тавышы аның:
Колоратур сопрано.
Бер тавыш урман эчендә
Мең тапкыр кабатлана.

Сайрый бер кош. Ә үзе бит
Йөрәктән дә кечкенә.
Бөтен урманны сыйдырган
Ул үзенең эченә.

Сайрый бер кош. Аның җыры
Зәңгәр күккә языла.
Рәхәтләнеп коена дөнья
Бер нәни кош назында.

*1998*

## *Бәреп чыга бит ул йөзләргә*

Ике яшь кыз шайтан уены тапты,
Булмаса да шайтан затыннан —
Үткән-сүткәннәрнең башларына
Төкереп калды алар балконнан.

Төкерекләре башка төшкән саен
Шатлык белән тулды эчләре.
Шул уенны уйнап үтә торды
Бу кызларның иртә-кичләре.

Астагылар бармак янасалар,
Посты алар балкон читенә.
Һәм ярыкка авызларын куеп,
Төкерделәр кеше өстенә.

Әй көлделәр алар, әй көлделәр,
Үз эшләре белән масаеп.
Көлә торгач, гүзәл бу кызларның
Авызлары калды чалшаеп.

Әкият бит бу, диеп уйламагыз,
Һич ялган юк ошбу сүзләрдә.
Җанга оялаган яманлыклар
Бәреп чыга бит ул йөзләргә,
Бәреп чыга бит ул йөзләргә!

*1998*

## *Бу дөньялар фани*

Төзи кеше гомер буе,
Нидер көйли, җайлый.
Ә бит белеп тора үзе —
Бу дөньялар фани.

Байлык җыя ал-ял белми,
Тирен ялый-ялый.
Ә бит белеп тора үзе —
Бу дөньялар фани.

Анда үрелә, монда үрелә,
Зур исемнәр даулый.
Ә бит белеп тора үзе —
Бу дөньялар фани.

Мәңгелеккә килгән кебек,
Тырыша кеше, кайный.
Ә бит белеп тора үзе —
Бу дөньялар фани,
Бу дөньялар фани.

*1998*

## *Батырлар бер үлә*

Гамьсез генә яшәп булмый һич тә,
Дошманы бар җирдә һәр затның.
Табигать ул үзе уйлап тапкан
Иң камилен капкын-тозакның.

Куяннарны бүре эләктерә,
Бүреләрне аю ботарлый.
Аюларны егып салыр өчен,
Алачыкта аучы ук чарлый.

Кыяларга кунган бөркетне дә
Таш астыннан елан күзәтә.
Табигатьтә һәрбер җан иясе
Бер-берсенең үлемен тизләтә.

Тик барыбер тормыш дәвам итә,
Үлем белән яшәү — бер яшьтә.
Гел көчлеләр генә җиңеп чыкмый
Яшәү өчен барган көрәштә.

Гамьсез генә яшәп булмый һич тә,
Дошманы бар җирдә һәр затның.
Ә шулай да батырлар бер үлә,
Һәркөн җаны чыга куркакның.

*1998*

## *Нинди серләр ята?*

Шәһәр йортларына кысылып,
Бер күл яшәп ята.
Һәрбер камышның төбендә
Сайрый өчәр бака.

Кыр үрдәкләре киләләр
Язлар саен очып.
Бала чыгаралар алар
Күлдә качып-посып.

Акчарлаклар әйләнәләр
Күлнең өсләрендә.
Яңгырый төрле тавышлар
Шәһәр кичләрендә.

Бер карасаң, бу күл һич тә
Матур түгел кебек.
Китә монда әллә кемнәр
Чүп-чарларын түгеп.

Үрдәк бәбкәләре белән
Кәгазьләр дә йөзә.
Күл көрәшә, күл тартыша,
Күл барсына түзә.

Нәрсә тарта соң кошларны
Бу ташландык күлгә?
Алданып йөриме алар
Кемдер биргән җимгә?!

Әллә безгә матурлыклар
Бирик, диләр микән?

Җаннарына җылы сулыш
Өрик, диләр микән?

Белмим, белмим,
бу кошларны
Монда нәрсә тарта?
Суы билдән күл төбендә
Нинди серләр ята?!

*1998*

## *Моң*

Һәрбер күңел катлам-катлам,
Һәр күңелдә сер ята.
Күңелдә яткан моңнарны
Гармун тавышы уята.

Уята да алып китә
Үзе белән ияртеп.
Йөздерә уй дәрьясында
Әкрен генә тирбәтеп.

Изри күңел, сафлана җан,
Бетә кайгы-сагышың.
Хуҗа була бар дөньяга
Моң һәм гармун тавышы.

Энҗе яшьләр сытылып чыга
Керфекләр арасыннан.
Моң чәчәкләре ярала
Йөрәкләр ярасыннан.

*1997*

## *Амнистия көткән тоткындай*

Госсоветта бара зур сессия,
Депутатлар сөйли кызып-кызып,
Президиумның озын өстәленә
Татар телен кемдер салган сузып.

Хирурглар, ягъни депутатлар,
Зур өстәлгә таба игән башын.
Кайсы чеметә телне, кайсы тешли,
Хәл итмәкче алар Тел язмышын.

Сүзен башлый берсе: — Менә бу Тел
Татар теле була, господалар.
Үстермәскә... Тфү, үтермәскә
Берәр чара кирәк булыр аңар.

Икенчесе, Телгә караш ташлап,
Микрофонга мондый аваз сала:
— Бу Тел үлгән инде, әфәнделәр,
Иң яхшысы: Ясин чыгыйк аңа.

Залдан кычкыралар: — Браво, браво,
Ясин чыгыйк тизрәк, тергезмик.
Татар халкы тыйнак, сабыр халык,
Бик килешә аңа телсезлек.

Телле халык азып-тузып йөри,
Яман сүзләр әйтә, сүгенә.
Телсезләрне теге дөньяда да
Утырталар оҗмах түренә.

Шул чагында өстәлдәге зур Тел
Чәбәләнеп куйды, сикерде.

Ә аннары, тыгыз залга карап,
«Лачт» иттереп берне төкерде.

Зал бер мәлгә тынып калды кинәт,
Гаҗәпләнү чыкты йөзләргә.
Тел үлмәгән! Димәк, монда инде
Башка хәйлә кирәк эзләргә.

Шул чагында бер акыллы башы
Тәкъдим кертте: — Күчик латинга.
Хатын врач минем, бәлки, аның
Бер файдасы тияр хатынга.

Сикереп торды бүтән бер депутат,
Әйтте сүзен, чәчеп гайрәтләр:
— Юк, җәмәгать, без гарәпкә күчик,
Күп килә бит безгә гарәпләр.

Дүртенчесе: — Төрек, төрек,— диде, —
Без төреккә тотынып йөрик,— диде.
Бишенчесе әйтте: — Стой, нет!
Татарларга рустан шәбе юк.

Ораторлар алмашынып торды,
Барсының да сүзе акыллы.
Бәхәс кызды, сүзләр куера барды,
Һәрбер чыгыш булды ялкынлы.

Эзли торгач, бәхәсләшә торгач,
Бер чарасын уйлап таптылар:
Өстәлдәге Телне алдылар да
Авыз эченә кертеп яптылар.

...Тел өстеннән һаман хөкем бара,
Кисеп ташларга да чыкмый җай.
Бикле авызда Телебез бәргәләнә,
Амнистия көткән тоткындай.

*1997*

* * *

Күкләр була җиде катлы,
Һәрбер катында капка.
Капкаларда фәрештәләр
Бик уяу тора сакта.

Күкләргә менүләр авыр,
Күкләрнең юк баскычы.
Һәркемнең үз йөрәгендә
Күк капусы ачкычы.

*1997*

* * *

Күктә йолдызлар
шундый күп:
Тоныгы, яктысы бар.
Һәркайсының үз урыны,
Үз төсе — чаткысы бар.

Кояш та бар күктә, Ай да,
Этешми берсе-берсен.
Күкләрнең күңеле бик киң,
Сыйдыра бөтенесен.

*1997*

## *Калҗа һәм чыбык*

Шәп нәрсә инде цирк,
Көләсең шырык-шырык.
Иң җитди кешенең дә
Күңел көр, авыз ерык.

Маймыллар кеше кебек,
Кешеләр маймыл кебек:
Сикерәләр, ауныйлар,
Күз буалар, алдыйлар.

Күр әнә клоунны! —
Борыны шәп — нәкъ түрә.
Коеп куйган депутат —
Ялган сөйләп көлдерә.

Арысланнар көтүе
Буйсына бер кызчыкка.
Чөнки аның кулында
Калҗа да бар, чыбык та.

Филләрне тезләндерә
Шул ук калҗа һәм чыбык.
Хәтта ялкау аюлар
Бииләр тырык-тырык.

Тормышның нәкъ үзе бу —
Кызганыч та, кызык та:
Бөтен нәрсә корылган
Калҗа белән чыбыкка.

*1997*

## *Шуңа горурлар без*

Иң беренче кояш бездән чыга,
Аннан гына китә Казанга.
Шуңа күрә бездән башлана бит
Җирнең туе — шаулы язлар да.

Көн пәрдәсен ачу — зур вазифа,
Анысы да безгә йөкләнгән.
Бөек вазифаны үтәр өчен,
Иртә торабыз без күпләрдән.

Иртә торган — ерак киткән, диләр,
Безнең бар шул ерак барасы.
Гел еракка, гел биеккә генә
Ашкына бит адәм баласы.

Шушы ашкынулар кояшны да
Уятадыр, бәлки, иртәрәк.
Ничек горур булмыйк: Кояшны без
Юлга озатабыз иркәләп.

Әйе, кояш башта бездән чыга,
Без кояшны кабызучылар.
Ә башкалар, шул кояшка карап,
Юлга җыенучы юлчылар.

*1997*

## *Кирәк*

Эшне башлап китәр өчен
Сәбәп кирәк.
Матур итеп тәмамларга
Сәләт кирәк.

Кәеф-сафа корыр өчен
Шәраб кирәк.
Дөньяда син кем булсаң да,
Әдәп кирәк.

Парны парга димләр өчен
Кода кирәк.
Җанны сафландырыр өчен
Дога кирәк.

Тормыш гөрләп барган чакта
Бар да кирәк.
Кайгы-хәсрәт килгәч кенә
Алла кирәк.

*1997*

## *Күкләр юлы*
## *кирәк кешегә*

Килә-китә кеше бу дөньяга,
Кала белем, кала яктылык.
Тоягыннан очкын чәчә-чәчә
Вакыт аты чаба атылып.

Үрелә кеше айга, йолдызларга,
Бөтенесен килә беләсе.
Җиде катлы күкләр ишегенең
Биктә тора ләкин киләсе.

Ә ачасы килә.
Тик ачарга
Ярамый шул гади ачкычлар,
Тартыла җан һаман яктылыкка,
Ымсындыра серле балкышлар.

Офыкларның зәңгәрлеген эчеп,
Якты төсләр җыеп күңелгә —
Вакыт аргамагын иярли дә
Үрләренә кеше үрелә.

Әй аңлыйсы килә бу дөньяны,
Әй ачасы килә серләрен.
Җир-күкләрнең, таң
һәм киңлекләрнең
Кемнәр белә икән телләрен?

Кемнәр беләикән телләрен?
Кемнәр ачар күңел күзебезне,
Гүзәллеккә булыр кем юлчы? —
Сорау бирдем.
Шулчак күз алдыма
Килеп басты минем — Укытучы.

Ул ниндидер горур һәм илаһи,
Йөзләрендә серле яктылык.
Иярәсең аның артыннан син
Серле яктылыкка тартылып.

Кулларында аның ачкычлар күп,
Серле мәгарәләр ачкычы.
Шул ачкычлар белән ачыладыр
Бик күп кешеләрнең язмышы.

Биеклеккә басма сала-сала,
Вакыт, көчен тормый исәпләп,
Алып бара бит ул кешелекне
Йолдыз юлларыннан җитәкләп.

Югарыда анда дөнья башка —
Иңнәреңә нурлар ишелә.
Яктылыкка күңел сусаганда
Күкләр юлы кирәк кешегә,
Күкләр юлы кирәк кешегә.

*1997*

## *Эш көйләнде*

Секс-мекс кинолары
Алып кайтты беркөн Гата.
Сүкте аны әби-бабай,
Сүкте аны ана, ата.

Шактый озак барды тавыш,
Шактый озак барды тартыш.
Тик барыбер малай җиңде —
Заман аның яклы иде.

Бетте тавыш, җайланды эш,
Һәммәсенә тиде өлеш:
Төнлә карый малайлары,
Көндез әби-бабайлары.

Карый һәркем җаен табып,
Бер-берсеннән качып кына.
Малай астан гына көлеп,
Секс-мекс тасмасының
Яңаларын ташып тора.

*1997*

## *Казаным*

Әй Казаным, гүзәл шәһре Казаным,
Синдә үтте күпме көз һәм язларым.
Синдә сөйдем, синдә ярлар сайладым,
Синдә җайсыз тормышымны җайладым.

Шаулыйсың син,
                    кайныйсың син, Казаным,
Дан вә шөһрәт даулыйсың син,
                                        Казаным.
Гүяки син океандагы зур кораб,
Юл табасың халык күңеленә карап.

Үткәннәрең синең бигрәк гыйбрәтле,
Искә алсаң — каннар сава йөрәкне.
Туфрагыңда канлы тарих эзләре,
Моңсу айда — Сөембикә күзләре.

Аҗаганнар — Кол Шәрифләр кылычы,
Тавышы юк, ялтырый тик корычы.
Кояшта тап — бу күләгәме канлы,
Әллә Шаһгалинеңме җаны?

Нигә бетми бу кара тап кояшта?
Искәртәме вөҗданнарны сатмаска?
Күтәрелә һәр чат саен манара,
Канлы яшен сөртеп Казан яңара.

Тик шулай да җаннарда юк тынычлык,
Чөнки әле богауларда корыч нык.
Басалмыйбыз һаман җиргә туп-туры,
Аска тарта безне богау чылбыры.

Карап торсаң:
Казан шаулый, Казан шат,
Ала-сата, кайнап тора һәрбер чат.
Кешеләрнең үткәннәрдә юк гаме,
Бүгенге көн борчый кебек гавамны.

Юк, шулай да күңелләрдә өмет бар,
Туып тора җиргә яңа бөркетләр.
Тотмаса да җаннарында алар үч,
Беләкләрдә җыела бара яңа көч.

Шомлы еллар үтәрләр дә китәрләр,
Үз тәхетенә кайтыр Сөембикәләр,
Кайтмаса да элеккеге ханлыкка,
Бер кайтырга тиеш халык хаклыкка.

*1997*

## *Айлар якты*

Айлар якты, айлар якты,
Айлар яктысы күктә.
Ничек якты булмасын ул,
Яшәп шундый биектә?

Айлар якты, ай янында
Якты йолдыз җемелди.
Якты ай янында — якты
Булмыйча мөмкинмени?

*1997*

## *Югала*

Югала ямьнәр, югала,
Җирдә ярасы кала;
Көннең битенә ягылып
Төннең карасы кала.

Бәргәләнә елга-сулар
Яралы елан кебек.
Тын алалмый, гүя кемдер
Бугазын буган кебек.

«Бетәбез, бетәбез!» — диеп,
Урманнар ыңгыраша.
Куркып бу шомлы аваздан
Бар шүрәлеләр кача.

Кайда ул алтын тараклы
Гүзәл Су аналары? —
Картлар йортларына илтеп
Япканмы балалары?

Кайда ул шук җен-пәриләр,
Мунчадан киттеләрме?
Әллә көмешкә чөмереп,
Исереп беттеләрме?

Кайда ул тирән күлләрнең
Гаярь аждаһалары?
Калдымы алар урынына
Тик яңгыр бакалары?

Кайда әкият, кайда тылсым,
Кайда зурлык, батырлык?
Без аны артык баладай
Суларгамы батырдык?

Җирдә ниндидер моңсулык,
Җирдә ниндидер бушлык.
Оясын югалткан коштай
Җан бәргәләнә очып.

Сафлыгын җуйган гүзәл күк,
Тын гына үкси җилләр.
Фахишәләр кочагында
Яталар хәлсез ирләр.

*1997*

## *Этюд*

Чәчәкләр бии болында,
Җил курай уйнап тора.
Ак каен да, сикереп төшеп,
Биергә уйлап тора.

Итәкләрен чеметеп тоткан,
Чакыру гына көтә.
Тик әле кавалер гына
Йөри кайдадыр читтә.
Чәчәкне күрми үтә.

*1997*

## *Каз өмәсе*

Фәрештәләр каз өмәсе ясый,
Күктә бүген хәйран-тамаша.
Бөтерелеп очкан ак мамыктан
Баш әйләнә, күзләр камаша.

Күктән килә шаян җыр тавышы,
Бу җырлардан йөзләр нурлана.
Муеннарга, кызлар кулы булып,
Ак мамыклы буран урала.

Урала да буран, җибәрми һич,
Алып менеп китә биеккә.
Фәрештәләр казлар йолыкканда,
Эш табыла һәрбер егеткә.

Берсе казны ай читенә элә.
Берсе чайкый ап-ак болытта.
Күк кызының кызыл бармакларын
Җир егете өреп җылыта.

Уен белән тормыш кушылган да,
Бер хозурлык туган галәмдә.
Бәхетле Ай гармун уйнап тора,
Җилләр бии әйлән-бәйләнгә.

Каз өмәсе бүген, наз өмәсе,
Ак бураннан күзләр камаша.
Әллә күктә казлар каңгылдаша,
Әллә яшь йөрәкләр аңлаша...
Күк йөзендә хәйран-тамаша.

*1997*

* * *

Берәүләр үз кирәкләрен
Шуышып таба.
Икенчеләр —
Сугышып таба.

Ә берәүләр сугышмый да,
Шуышмый да;
Бәхет өчен хәтта әз-мәз
Тырышмый да.

Бәхет үзе килеп ава
Өсләренә.
Белми кеше бәхет белән
Нишләренә.

Байлыгына басылып калган
Байлар төсле,
Гомер буе чәбәләнә
Мондый кеше.

Котыла алмый ләкин аннан
Һичбервакыт.
Чөнки байлык гел түбәнгә
Тора тартып.

*1997*

## *Гүзәл гамь*

*Айрат Арслановка*

Сөйли маэстро зур сәхнәдә,
Меңнәрчә күз аңа төбәлгән.
Канатланып шигырь оча залда,
Күңелләргә тулган гүзәл гамь.
Җанга бүтән берни кирәк түгел,
Мөлдерәмә күңел бу гамьнән.
Ишетелә маэстро тавышы
Әллә җирдән, әллә галәмнән.
Уйлата да, хәтта елата да,
Һич битараф итми бу тавыш.
Йөрәкләрдән сыгылып-сыгылып чыга
Татар шигырендәге моң, сагыш.

*1997*

## *Кыюлык*

Озак йөрдем инде телне тешләп,
Ирек куям бүген сүзләремә, —
Дуңгызларга, сез бит дуңгыз, диеп
Әйтәчәкмен, бәреп йөзләренә.

Шулай диеп чыгып китте Вәли,
Гайрәтләнде, җитеп соңгы чиккә.
Һәм кычкырды:
«Һәй, дуңгызлар!» — диеп,
Чучкаларын куып көтүлеккә.

*1997*

## *Сәвиягә*

Яшәү бит ул беркемгә дә җиңел түгел,
Язмыш иңгә авырлыклар өеп тора.
Тормыш безне
 сыңар кулы белән кыйный,
Ә икенче кулы белән сөеп тора.

Бер батабыз, бер калкабыз елгаларда,
Омтылабыз чыгам-чыгам, диеп, ярга.
Агымсулар чайкый безне керләр итеп —
Бер елыйбыз, бер көләбез дөньяларда.

Яшәү тәмен беләбез без әкрен-әкрен,
Күз яшьләрен телләр белән ялый-ялый.
Үрмәлибез һаман алга өмет белән,
Язмышларның ертыкларын ямый-ямый.

Дөнья шулай булган инде гомер бакый,
Ишеп-ишеп яңгыр ява, кояш балкый.
Кайгы килеп башыбызны идерә дә,
Шатлык килеп,
 күңелләрнең ишеген шакый.

*1996*

# *Бар да бер кулланышлы*

Арзан бәягә бер кулланышлы
савыт-сабалар сатыла.

*Газеталардан*

Америкача яшибез,
Хәтта уздык алардан.
Савыт-саба да юмыйбыз,
Җитте рәхәт заманнар.

Бер кулланышлы тәлинкә,
Бер кулланышлы кашык.
Бер кулланышлы оекбаш,
Бер кулланышлы башлык.

Бер кулланышлы стакан,
Бер кулланышлы ярты.
Һәм бер кулланышлы гына
Кесәңдә хезмәт хакы.

Барсы да бер кулланышлы,
Ал да кит, түләп хакын.
Бер кулланышлы карават,
Бер кулланышлы хатын.

*1996*

* * *

Җир — тәгәрмәч,
Кеше — күчәр.
Күчәрләргә урала бит
Бөтен чүп-чар.
        Еракрак барган саен
        Авырайта.
        Чөнки күчәргә уралган
        Чүпләр арта.
Болай барса, түзә алмас
Сынар күчәр.
Йә тәгәрмәч таралыр да,
Очып төшәр.

*1996*

## *Тора икән килешеп*

Әй кычкырып көлә идек
Кыска итәклеләрдән,
Ялангач сыйраклылардан,
Ачык күлмәклеләрдән.
        Заманалар өйрәтте,
        Кыскартмыйлар итәкне:
        Салып кына ыргыталар
        Күлмәк яки итәкне.
Әллә нәрсәләр күрсәк тә
Калмыйбыз һич көлешеп:
Безнең кызларга барсы да
Тора икән килешеп.

*1996*

# *Аккош булып оча һавада*

*Тәбриз Мөбарәковның*
*якты истәлегенә*

Әллә инде артык сукырлар без,
Күп нәрсәне күрә белмибез.
Матурлыкны кешеләрдән түгел,
Йолдызлардан, күктән эзлибез.

Ә бит шундый матур күңелләр бар —
Эче тулы байлык, хәзинә.
Ул хәзинә ургып килеп чыгар —
Кагыл гына аңа әз генә.

Кагыл гына, бары кагыл гына,
Бүтән нәрсә һич тә кирәкми.
Бер җылы сүз киереп ачып ташлар
Хәзинәләр тулы йөрәкне.

Бик гади дип йөргән кешенең дә
Тамырлары буйлап моң ага.
Ләкин күпләр күңелендәге кошын
Очыра алмый кала дөньяга.

Бәргәләнә, чәбәләнә бу кош,
Өзә алмый язмыш чылбырын.
Алып китә кеше үзе белән
Күккә очырасы кош — җырын.

Алып китә тавыш-тынсыз гына,
Үпкә белдермичә дөньяга.
Килеп кушыла аның моң елгасы
Бик соңарып олы елгага.

Ул моңнарны «Хәтер аланы»*на
Җил куалый ашыга-ашыга.
Башларына ак яулыгын бәйләп
«Гөләби»**ләр чыга каршыга.

Ләкин инде күпме үкенсәң дә,
Бер киткәннәр кайтмый яңадан.
Тик җаннары гына аккош булып
Очып үтә һәр яз һавадан.

*1996*

* * *

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Тал бөгелә җилләрдә:
Бер карыймын шул талларга,
Бер карыймын билләргә...

Таллар да төп-төз түгелләр,
Билләр дә бөгелгәннәр.
Тураймый инде, тураймый
Яшь килеш иелгәннәр.

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Сынмаска дип бөгелә;
Иелгәннәр, бөгелгәннәр
Чәч белән җир себерә.

*1996*

* Язучы Тәбриз Мөбарәков.
** Язган әсәрләренең исемнәре.

## *Ләйлә һәм Мәҗнүн*

— Сине сөям! — диде Мәҗнүн,
— Я тоже,— диде Ләйлә.
— Ләкин сиңа өйләналмыйм...
— Ну, что ж,— диде Ләйлә.

— Очрашырбыз,— диде Мәҗнүн,
— Согласна,— диде Ләйлә.
— Кочакlармын,— диде Мәҗнүн,
— Ну, ясно,— диде Ләйлә.

— Ә аннары...— диде Мәҗнүн,
— Понятно,— диде Ләйлә.
— Бүләкләр алып килермен...
— Приятно,— диде Ләйлә.

Әйтте Мәҗнүн, кызны кочып:
— Киттек, алайса, әйдә!
— Наконец до тебя дошло,
О Боже! — диде Ләйлә.

*1996*

## *Нәрсә калыр?*

Җыр диеп атыйбыз хәзер
Ямаулы такмакларны.
Ертык җырлар
җырлый-җырлый
Ертабыз тамакларны.

Шушы ертык такмакларда
Моң үлә ыңгырашып.
Былбыллары китә җанның
Хушлашып, саубуллашып.

Болай да күпне югалттык
Гасырлар кичә-кичә.
Моңнарны җыйдык күңелгә
Сагышлар эчә-эчә.

Үткәннәрдән бүгенгегә
Акты моңнар елгасы.
Саклады безне шул моңнар,
Болганса да дөньясы.

Ә бит гомергә безнең җан
Былбыл оясы булган.
Татардан нәрсә калыр соң,
Аерсак аны моңнан?!

*1996*

## *Исмә, җил*

Әй исмә, җил, исмә, җил,
Күзгә сипмә тузаннар.
Күзле булып яшәсен
Күзле булып туганнар.

Әй исмә, җил, исмә, җил,
Бөгелмәсен кылганнар.
Туры булып үссеннәр
Туры булып туганнар.

Әй исмә, җил, исмә, җил,
Кузгатма син өермә.
Сулышларга капланып,
Горур башны идермә.

Әй исмә, җил, исмә, җил,
Тын алырга ирек бир.
Күктә балкып янучы
Кояш йөзен күрик бер.

Әй исмә, җил, исмә, җил!

*1996*

## *Башка төшә каргышы*

Һәр ике көннең берендә
Яки бәйрәм, яки ял.
Бәйрәмнәрдән арып-талып,
Эш сорап кычкыра җан.
        Җан таләбен ишетмибез,
        Җан таләбе — тавышсыз.
        Яшибез. Әйтерсең дөнья
        Кайгысыз һәм сагышсыз.
Гүя җирдә сугышлар юк,
Коелмый кеше каны.
Ниндидер кыргый шашыну
Биләп алган дөньяны.
        Биибез, юләрләнәбез,
        Акыл ычкынган бәйдән.
        Иртән айнып җиталмыйбыз
        Кичтән эчелгән мәйдән.
Бикле ишекләр аша да
Бәйрәмнәр бәреп керә:
Йә исерек булып сүгенә,
Яки эт булып өрә.
        Яки төнге кунак булып,
        Татлы йокыңны урлый.
        Күзләреңне йомып кына
        Дөньядан качып булмый.
Ә җан ярсып бәргәләнә,
Ләкин чыкмый тавышы.
Тавышсыз елаган җанның
Башка төшә каргышы.

*1996*

## *Кемнәр бирер кулъяулык?*

Дөнья үкси шомлы итеп,
Тыңлап ятсаң — куркыныч,
Гүя дөньяның өстендә
Эленеп тора зур кылыч.

Таң атса да, тынычлык юк,
Таң борыныннан кан тама.
Бәргәләнә кеше җирдә,
Таңнар булып җан яна.

Дөнья авыру, канлы яше
Тама җиргә чулт та чулт.
Дөньяның яшен сөртергә
Кемнәр бирер кулъяулык?

*1996*

## *Игезәкләр*

Игезәкләр туды җиргә,
Икесе дә сау-сәламәт.
Бу гүзәл игезәкләрнең
Берсе — яз, берсе — мәхәббәт.

Заман ничек болганмасын,
Туа болар һәрбер елда.
Яз булгач, мәхәббәт булгач,
Димәк, яши әле дөнья.

*1995*

* * *

Һәрнәрсәнең чын сурәтен
Күрсәталмый дөнья-күзге:
Чынны ялганнан аерып
Күрсәтә тик күңел күзе.

Изрәтсә безнең җаннарны
Кемнәрнеңдер матур сүзе —
— Уяу бул! — дип, әкрен генә
Әйтеп куя күңел күзе.

Хәтта артык яктылык та
Сукырайтып ташлый безне.
Ярый әле, андый чакта
Сизгер кала күңел күзе.

Күңел күзе, күңел күзе,
Синең вазифаң бик изге.
Әгәр син дә сукырайсаң,
Кем җитәкләп йөртер безне?!

*1996*

## *Моңсу шигырь*

Агыла болытлар, агыла —
Авыры, саллылары.
Болытлар булып агыла
Кемнәрнең кайгылары?!

Коела җиргә йолдызлар,
Күкнең юк терәкләре.
Йолдызлар булып атыла
Кемнәрнең йөрәкләре?!

Өзелә яфраклар җилләрдә,
Өзелмәс кебекләре.
Яфраклар булып сибелә
Кемнәрнең өметләре?!

Китәләр кошлар, китәләр
Урап-урап күкләрне.
Кошларга ияреп китә
Кемнәрнең яшьлекләре?!

Котыра җил, сүнә учак,
Сибелә көл-күмерләре.
Көл булып җиргә сибелә
Кемнәрнең гомерләре?!

*1996*

## *Йөрәк белән янәшә*

Эзлибез кайчакерактан
Якындагы бәхетне.
Үтәбез диңгезләр аша,
Айкыйбыз җирне, күкне.

Барабыз, озак барабыз
Ерып еллар томанын.
Кыен адашмый узулар
Озын гомер урманын.

Була — бер ятып елыйсың,
Өметләр өзелгәндә.
Иреннәргә яшьләр тама
Йолдызлар күзеннән дә.

Беттем дигәч, кинәт кенә
Ниндидер аваз дәшә:
Бәхетең синең янында,
Йөрәк белән янәшә,
Йөрәк белән янәшә.

*1996*

* * *

Кошлар китә, кошлар кайта,
Кошларны кем санаган:
Бәлки, аларның да барсы
Кайталмыйлар яңадан.

Кошлар китә, кошлар кайта,
Кошлар урый дөньяны.
Юлларда яныя каладыр
Канатлары сынганы.

Кошлар китә, кошлар кайта,
Нәрсә йөртә кошларны?
Әллә юллар баса микән
Сагыну-сагышларны?!

Кошлар китә, кошлар кайта,
Һавада кошлар юлы.
Йолдызлардан саркып-саркып
Тарала кошлар моңы.

*1996*

* * *

Көзләр көзгә охшамаган,
Көзләр шундый кояшлы:
Августның кайнар кояшы
Уяткан алмагачны.

Алмасы да, чәчәге дә
Бер агачта — берьюлы.
Чәчәктә — язлар балкышы,
Алмада — көзләр моңы.

Яз белән көзләр кавышкан,
Озакка кавышумы?
Әллә соң бу табигатьнең
Очраклы ялгышымы?!

Ни булса да сокланырлык
Бу гүзәл күренешкә.
Яз белән көзнең туйлары
Булсын тик сөенечкә.

*1996*

* * *

Кайный, ярсый, бәргәләнә,
Үкерә, шаша елга.
Урын юк монда сагышка,
Урын юк монда моңга.

Ярсу елганың өстенә
Ава ярның таллары.
Чаба дулкыннар җилләрдә,
Җилфер-җилфер яллары.

Әле уңга, әле сулга
Бора елга агышын.
Елга түгел, шашкын сөю
Яза үзенең язмышын.

Хисләр дулкынына түзми,
Ишелә акыл ярлары.
Атыла күккә, йолдыз булып,
Гашыйкларның җаннары.

*1996*

## *Дачада*

Күршеләрнең бакчасында —
Көлү, шаяру, шатлык.
Тәмле ис керә борынга,
Күрше кыздыра шашлык.
        Күп тә үтми мунчалары
        Төтен пошкыра башлый.
        Габделвәли, җырлый-җырлый,
        Мунчасына су ташый.
Сый да бар бүген, шатлык та,
Юк бары сагыш кына.
Кушыла кошлар тавышы
Гашыйклар тавышына.
        Шампан шәраблары шартлый
        Җиңү салюты сыман.
        Сөю җыры ишетелә
        Хәтта бокал чыңыннан.
Уйлап ятам, хәер, моны
Уйламасам да беләм:
Күрше бүген бакчасына
Сөяркә алып килгән.
        Ике көннән Габделвәли
        Бакчага килде тагын.
        Мунчадан төтен чыкмады,
        Бик такыр булды табын.
Көлү дә юк, шаяру да,
Сукрану яуды телдән.
Аңлыйсыздыр, бүген күрше
Хатыны белән килгән.

*1995*

## *Бер нәтиҗә*

Карап торамын да юлга,
Киләм кызык кына уйга:
Яшәешнең зур мәгънәсе
Чагыла икән менә монда.
Берәүләр бу якка килә,
Икенчеләр теге якка.
Берәүләр борыла уңга,
Икенчеләр сулъяк чатка.
Арлы-бирле, арлы-бирле,
Юнәлешләр төрле-төрле.
Адымнар да бер үк түгел —
Кемдер салмак,
кемдер җиңел.
Ә без менә көчли-көчли,
Әллә ниләр эшли-эшли,
Каратмыйча алга-артка —
Кудык бөтен кешеләрне
Гел бер якка, гел бер якка.
Тигез генә атлагыз, дип,
Бер-берегездән
калмагыз, дип,
Куа торгач сүгә-сүгә
Әйләндек без бер көтүгә.
Ә көтүдә барсы да бар:
Сыер, сарык, чучка, үгез...
Чучка, сыер, сарык, кәҗә
Атлый аламыни тигез?

*1995*

## *Аерма*

Җирдә генә көчле кеше,
Җирдә генә ул батыр.
Өскәрәк үрелгән саен
Өзелә бара тамыр.

Күпләр,
 тамырларын йолкып,
Югарыга калыккан.
Аерылган алар шулай
Җиреннән һәм халыктан.

Авалар андый «бөекләр»
Хәтта көчсез җилләрдән.
Аерма берүк, язмышым,
Тамыр җәйгән җирләрдән,
Терәк булган иңнәрдән.

*1995*

## *Бетмәс*

Болыннарның яме бетмәс,
Җирдә гөлләр барында;
Гүзәлләрнең кадере бетмәс,
Илдә ирләр барында.

Илдә батыр ирләр бетмәс,
Җирдә көрәш барында.
Җирдә әле көрәш бетмәс,
Күзләрдә яшь барында.

*1995*

## *Илдә әле ирләр бар*

Биек-биек таулар бар,
Тау башында таллар бар;
Тау башында таллар булып
Калкып чыккан җаннар бар.

Биек-биек таулар бар,
Тау башында ташлар бар;
Өсләренә таш яуса да,
Иелмәгән башлар бар.

Биек-биек таулар бар,
Тау башында җилләр бар.
Җил-давылда егылмаслык
Илдә әле ирләр бар,
Шөкер, андый ирләр бар!

*1995*

## * * *

Күккә ук атсаң,
Бер гаепсезнең
Башына төшәр.
Җиргә ут яксаң,
Бер гөнаһсызның
Аягы пешәр.
Ук белән утның
(Һәркем беләдер)
Күзе юк аның.
Шуңа күрә дә
Безгә текәлгән
Күзе дөньяның.

*1995*

## *Сине җиңәр өчен мин бар җирдә*

Яшьлек әйтте: — Бу дөньяда берәр
Мине җиңә алыр көч бармы?
Телим икән — таулар күчерәм мин,
Телим икән — чөям ташларны.

Күкрәгемдә ярсу диңгез көче,
Күзләремдә яшен утлары.
Ялларыннан тотып ега алам
Чабып барган җитез тулпарны.

Нинди генә эшкә тотынсам да,
Җиңеп чыгам, кире чигенмим.
Буйсындырам, җиңәм, ләкин үзем
Һичбер вакытта да җиңелмим.

— Тукта, тукта! —
дигән аңа картлык, —
Кайнарланма әле ул чаклы.
Күргәнем юк әле минем һичбер
Мәңге җиңелмәслек бер затны.

Дөнья фани. Ә дөньяда, дустым,
Һәр батырны җиңәр әмәл бар:
Сине җиңәр өчен мин бар җирдә,
Мине җиңәр өчен Әҗәл бар.

*1995*

## *Эт гадәте*

Эткә ике сөяк бирсәң,
Берсен җиргә күмә ул.
Чөнки сөяк көн дә тими,
Шуны яхшы белә ул.

Табалмаска да мөмкин эт
Җиргә күмгән сөяген.
Тик шул сөяк барыбер аның
Җылытып тора йөрәген.

Кешеләр, үпкәләмәгез,
Бездә дә бар эт холкы,
Запас калдҗаң булса гына
Тыныч була бит йокы.

*1995*

## *Шундый без*

Хәзер инде милләтләр дә буталган,
Хәзер инде дәүләтләр дә буталган.
Барыбыз да бер хуҗаның ишәге —
Һәммәбезгә акча хуҗа, акча хан.

Шул патшага
                    бил бөгәбез шатланып,
Ә ул безгә утырган нык атланып.
Торган саен башны ыграк идертә,
Борын белән хәтта җирләр сөрдертә.

Аның кадәр беркемне дә сөймибез,
Аның кадәр беркемгә баш имибез.
Акча безне таулар булып басса да,
Ай-һай, авыр, үтерә бит, димибез.

*1995*

## *Тәхет һәм бәхет*

Акыллылар яңа корал ясый,
Юләрбашлар утыра тәхеттә.
Халык мескен,
анда-монда бәрелеп,
Ирешмәкче була бәхеткә.

Тик бәхеткә якын килеп булмый,
Зур йозаклар тора капкада.
Йозакларның ачкычлары исә
Тәхет асларында саклана.

Бәхет белән тәхет арасында
Һичкайчан да көрәш бетмәгән.
Берәүләргә тәхет җитмәгән гел,
Берәүләргә бәхет җитмәгән.

Бу көрәшнең, ахры, чиге булмас,
Шулай яралгандыр дөньясы —
Тәхет белән бәхет арасыннан
Ярсып ага тормыш елгасы.

*1995*

## *Калмагыз соңга*

Бәлки, мине әнием эзлидер,
Бәлки, мине әтием эзлидер.
— Әтием, мин монда,
— Әнием, мин монда —
Каты тимер караватымда.

Ишек бикле булса — ачыгыз,
Тәрәз бикле булса — шакыгыз.
Кертмәсәләр, кагып керегез,
Ләкин мине барыбер күрегез.

Тәрәз каршысында өянке,
Өянкедә бер кош оясы.
Көне буе сайрашалар алар,
Бигрәк матур кошлар дөньясы.

Әнкә кошлар анда җим ташый,
Бала кошлар тәмләп җим ашый.
Оялары йомшак мамыклы,
Тавышлары шундый шатлыклы.

Ишетәсезме, әнием, мин монда,
Ишетәсезме, әтием, мин монда.
Мин көтәмен әле, көтәмен,
Тик килегез, калмагыз соңга.

Килмәсәгез, китеп барырмын
Кошлар белән ерак илләргә.
Җылы эзләп очып йөрермен,
Керә-керә өйдән-өйләргә.

*1995*

## *Яңа елга иске теләк*

Әй Яңа ел, Яңа ел,
Яңа туган бала ел.
Син шаян, син шук әле,
Гөнаһларың юк әле.

Ай үсәсен көн үсеп,
Туктамыйча гел үсеп,
Күп гамәлләр кылырсың,
Баһадир ир булырсың.

Тик берүк явыз булма,
Җиргә кан-яшь агызма.
Җыйма ләгънәт-каргышлар,
Чуалмасын язмышлар.

Мылтык тоткан кулларга
Кызганмыйча каты сук.
Кара мәкер-уйларга
Давыл булып каршы чык.

Өйсезләрне өйле ит,
Көйсезләрне көйле ит.
Җылы, йомшак кул белән
Үксезләрнең яшен сөрт.

Буең белән түгел син,
Эшең белән олы бул.
Һәр кешенең гел көткән
Иң бәхетле елы бул.

*1995*

* * *

Бу дөньяның ние бар?
Кояшы бар, ае бар;
Теләгәндә учларында
Учак ягар җае бар.

Бу дөньяның ние бар?
Үзәне бар, тавы бар;
Бер тавына менеп җитсәң,
Артларында тагы бар.

Бу дөньяның ние бар?
Елгасы бар, яры бар;
Ярсып аккан елганың да
Уйга баткан чагы бар.

Бу дөньяның ние бар?
Күге бар һәм җире бар.
Күкнең, җирнең
мәңге бетмәс
Ымсындырган сере бар.

*1995*

## *Бары бер генә булса да*

Бу дөньяда
Тамак туйдырырга
Көтүчегә җитә
бер чыбыркы,
Дворникка — бер себерке,
Балыкчыга — сыңар кармак,
Угрыларга — кәкре бармак,
Хәерчегә — иске капчык,
Кабер казучыга — көрәк,
Сугымчыга — үткен пычак...
Тамак туйдырырга
күпме кирәк?!
Ләкин кеше тумаган шул
Бары тамак туйдырырга,
Яратылган ул дөньяга
Могҗизалар тудырырга,
Җиргә яктылык өстәргә,
Җиргә җылылык өстәргә,
Бары бер генә булса да
Җирдә игелек эшләргә.

*1995*

## *Өметсезлек*

Артка карыйм — артта тузан,
Алга карыйм — алда томан.
Туктыймын да уйлап куям:
Барабызмы дөрес юлдан?

Карар өчен юк бер маяк,
Кадалмаган хәтта таяк.
Барыр юлны күзләр түгел,
Капшап бара бары аяк.

Уңда бушлык, сулда бушлык,
Ялгыш бассаң — төштең очып.
Тирән упкын төпләрендә
Кемнәр елый мышык-мышык?

Ай һәм Кояш инде сүнгән,
Өмет үлгән, идеал үлгән.
Аера алмый фәрештәләр
Көнне — төннән,
                    төнне — көннән.

Кайда тау һәм кайда диңгез?
Караңгыда бар да тигез.
Кычкырырлык хәле дә юк,
Бәргәләнә дөнья өнсез.

*1995*

## *Иң матур кеше*

Кунакны бик яратам мин,
Кем килсә дә, мин бик шат.
Каршы алам һәммәсен дә
Елмаеп, җәеп кочак.

Әллә күңелем артык киң,
Аптырыйм үз-үземә.
Әгәр кунак килми торса,
Сагыш чыга йөземә.

Бүген кем килер икән дип,
Таң атса — көтеп торам.
Кем килсә дә, кулларына
Бер «күчтәнәч» тоттырам.

Пычкы, балта, чүкеч, кадак —
Коралларым җитәрлек.
Нишлим инде, дөньяны бит
Ялгыз барам күтәреп.

Йә элгечем килеп төшә,
Йә чалшая ишегем.
Ялгыз гына ямап булмый
Дөньяның һәр тишеген.

Хатын-кыз килсә дә ярый —
Керем тора өелеп.
Юсын әйдә, үтүкләсен,
Килгәненә сөенеп.

Иркен тотсын һәркем үзен
Нәкъ өендәге сыман:
Ашыйсы килсә, пешерсен
Йә өчпочмак, йә коймак.

Бик яратам мин кунакны,
Әйтәмен моны чынлап:
Кулында эш уйнап торса,
Күчтәнәче мулдан булса,
Иң матур кеше — кунак.

*1995*

## *Озак-озак янačак*

Кеше бит ул бер учак:
Утынын сала торсаң,
Көлләрен ала торсаң,
Бераз кузгатып куйсаң,
Утын уятып куйсаң,
Давылдан саклый алсаң,
Явымнан каплый алсаң,
Сүнгәндә өргәләсәң,
Яңа көч биргәләсәң,
Күмерен таратмасаң,
Урынын яңартмасаң,
Таш белән бастырмасаң,
Боз белән катырмасаң,
Ялкыннарын үрләтсәң,
Күмерләрен дөрләтсәң —
Бу учак
Озак-озак яначак.

*1995*

* * *

Бу дөньяның бик еш кына җае булмый,
Ботканң булса, салыр өчен мае булмый.
Атың булса, арбаң яки чанаң булмый,
Йөгең тартып китәр өчен чараң булмый.

Яр сөйгәндә — сайлар өчен акыл булмый,
Акыл кергәч — йөрәгендә ялкын булмый.
Эзләнәсең — эзләгәнең алтын булмый,
Акыл белән табылганнар якын булмый.

Отам, отам, отам, дисең — отып булмый,
Бәхет кошын тотам,
дисең — тотып булмый.
Кайчагында кулга кергән калҗаны да
Тешләп кенә карыйсың, ә йотып булмый.

Югалтасың — табам, табам, табам, диеп,
Ымсынасың — кабам, кабам, кабам, диеп,
Сүреләсең һәм сүнәсең — үз-үзеңне
Алдый-алдый, әле һаман янам, диеп.

*1995*

## *Уйнаучылар һәм уйлаучылар*

Халыклар белән
Уйнаучылар бар.
Халык турында
Уйлаучылар бар.
　　Уйнаучыларның
　　Кулында власть.
　　Уйлаучыларның —
　　Тик акыллы баш.
Власть — таш дивар,
Ул нык һәм каты.
Баш белән бәреп
Булмый шул ватып.

*1994*

## *Ташлар авыр*

Ташлар авыр, ташлар авыр,
Ничек күтәрә таулар?!
Түбәләренә күз салсаң,
Тетрәнеп куя җаннар.
Болытлар да куна бик еш
Ул тауларның өстенә.
Аларны да күтәрә тау,
Ышана үз көченә.
Сыкранмый да, сыктанмый да,
Башын югары тота.
Белә чөнки: ташлар бит ул
Иелгәннәрне сыта.

*1994*

## *Бер үк бишмәт*

Әйләндерәбез дә киябез гел
Бер бишмәтне гомер буена.
Әйләндергән саен бишмәтебез
Матуррак булып тоела.

Бер мәртәбә әйләндергән идек
Унҗиденче елда без аны.
Өстебезгә шуны киеп чыгып
Шаккатырган идек дөньяны.

Ул бишмәтне озак киеп йөрдек,
Ятканда да өстән салмадык.
Итәк кисеп, җиңен ялгадык та,
Тузган саен аны ямадык.

Ямаулары кызыл булгангамы,
Безнең бишмәт бигрәк шәп иде.
Аны кигән кеше бу дөньяда
Бер кайгысыз иде, шат иде.

Күнегеп беткәч кызыл ямауларга,
Бутап бөтен уйны-исәпне,
Әйләндереп кигерттеләр безгә
Тагын бер кат шушы бишмәтне.

Хәзер инде җеп тә тоталмый ул,
Һәрбер җөе тузган, черегән.
Җилләр өрә барлык ертыгыннан,
Өзелеп чыга торган җиреннән.

*1994*

## *Сандугач тыйнаклыгы*

Сандугач сайрый өздереп,
Җыры сарыла җанга.
Карыйм, карыйм —
күрә алмыйм,
Кайда соң, үзе кайда?

Керәм урманнар эченә,
Күрмәмме, диеп аны.
Юк, күралмыйм —
кошым китә,
Моңга күмеп дөньяны.

Үзен күрсәтүдә түгел,
Җырда аның шатлыгы.
Булсачы кешеләрдә дә
Сандугач тыйнаклыгы.

*1994*

## *Бай кеше*

Мин бай кеше.
Күп малайлар
Карый миңа көнләшеп.
Юмарт булсам да, аны мин
Бирә алмыйм өләшеп.

Очыйм дисәм, оча алам,
Канатларым пар минем.
Байлыгым шул — әтием дә,
Әнием дә бар минем.

*1994*

## *Ызгышырга нигез юк*

Тургай сайрый үз телендә,
Сандугач — үз телендә.
Өстен телләр, мескен телләр
Юк табигать илендә.

Саескан да, каргалар да,
Тартай яки бүдәнә —
Һәркайсысы үз телендә
Рәхәтләнеп сөйләнә.

Ник чыпчыкча сайрыйсың,
дип,
Козгын көлми чыпчыктан.
Яңгырый йөз төрле аваз
Йөзләрчә төр кошчыктан.

Табигатьтә гармония,
Табигатьтә тигезлек.
Бер урманга бар да сыя,
Тоймый беркем көйсезлек.

Тавышларның күплегеннән
Арта гына хозурлык.
Уйласаң, уйларга чумып,
Хәйран булып торырлык.

*1994*

## *Сузылган куллар*

Урам тулган хәерчеләр белән,
Киталмыйсың тыныч кына узып.
Йөгереп килә бала-чагалары
Күзләреңә карап, кулын сузып.

Ул күзләрне, ул кулларны күргәч,
Актарыла җаның, сыкрый йөрәк.
Бирәсең дә соңгы сумнарыңны,
Ашыгасың моннан читкә тизрәк.

Бу бәладән читкә борылып кына
Котылып булмый бүген —
шунысы хак.
Елгаларны өстән болгаттылар,
Түбән ага хәзер бөтен пычрак.

Бу шакшылык диңгезләргә төшә,
Җәелә җиргә торган саен зуррак.
Сузыла куллар уңнан,
сулдан, арттан —
Икмәк, хезмәт һәм мәрхәмәт сорап.

*1994*

## *Дөнья бик тә катлаулы*

Акча — нәфес шайтаны,
Шайтанның бар мең җаны.
Арындырып булмый һич
Шайтаннан бу дөньяны.

Ул керә безнең эчкә,
Әйләнеп үрмәкүчкә.
Чорный, кыса җаныңны
Һәм суыра каныңны.

Акча — патша, акча — хан,
Ул йөри бездән алдан.
Арткан саен акчабыз
Кими бара бит Вөҗдан.

Саклау авыр саф җанны,
Дөнья бик тә катлаулы:
Таләп итә йә акчаңны,
Йә Вөҗданны ваклауны.

*1994*

* * *

Кайларда йөртми кешене,
Язмыш дигәнең кызык:
Чыкмас идең авыр юлга,
Тарта җыясы ризык.

Тарта эчәсе суларың,
Тарта сулыйсы һаваң,
Барасың табышлар эзләп,
Югалтуларга табан.
Кайда кадер, кайда кабер,
Һич белә алмый бәндә.
Шул белмәгәнлек туктаусыз
Куалый: «Әйдә, әйдә!»

Ашкындыра, кызыктыра,
Гүя тылсымлы чәчәк —
Алдап-йолдап, ымсындырып
Йөртә безне күрәчәк.

*1994*

# *Агымсу*

Әй агымсу, агымсу,
Чабасың ярсып-ярсып.
Кемнәр серен сөйләмәгән
Синең ярларга басып.

Әй агымсу, агымсу,
Өсләрең дулкын-дулкын.
Күпме кайгы-хәсрәтләрне
Дулкыннар белән йоттың?

Әй агымсу, агымсу,
Ярларың катлы-катлы.
Ярыңа кемнәр язмышы
Ком-ташлар булып ятты?

Әй агымсу, агымсу,
Юлларың борма-борма.
Син дә туры агалмыйсың —
Бәреләсең уңга-сулга.

Әй агымсу, агымсу,
Бик болганган суларың.
Кайсы халык җаны аша
Үтте икән юлларың?

*1994*

## *Бөркет булмый*

Күпме генә үстермә син
Кулыңда өф-өф итеп —
Чыпчык булып туганнарны
Булмый ул бөркет итеп.

Биек чөйсәң — егылып төшә,
Кыяга кунмый чыпчык.
Үтә аның бөтен гомере
Өй тирәсендә очып.

Ләкин шушы хакыйкатьне
Күпләр аңламый кебек:
Чыпчык чөяләр дә күккә —
Көтәләр: булыр бөркет.

Ә өметләр акланмагач,
Нәгълләт ява чыпчыкка.
Чыпчык мескен
нишләсен соң, —
Аның тәхете чыбыкта.

*1994*

## *Яралы җанвар*

Бәргәләнә җирне тырнап
Яралы ерткыч җанвар.
Тирә-юньгә фонтан булып
Чәчри кара каннар.

Аермый дусны, дошманны,
Ташлана уңга, сулга.
Ботарлап атарга әзер
Кем очраса да юлда.

Күзләрен аның кан баскан,
Эзли ул яңа корбан.
Аның үкергән тавышын
Көчәйтә кара урман.

Далалар буйлап бара ул,
Калалар буйлап бара.
Ул үтеп киткән юлларда
Тик канлы эзләр кала.

Алда булган упкыннарга,
Сөякләр өя-өя,
Озак барыр әле, ахры,
Яралы империя.

*1994*

## *Безнең җаннар*

Яңа буын килә аренага,
Хәтерсез һәм әрсез надан буын,
Телләрендә бары катлы-катлы
Сүгенү сүзе генә калган буын.

Милләтсез һәм динсез кавем бит бу,
Беркем белми — кемнең балалары.
Алар өчен изге бернәрсә юк,
Байлык кына табыну аллалары.

Йөзләрендә иман нуры сүнгән,
Авызлары ыржаюдан чалыш.
Ләззәтләнеп изеп китә алар —
Юлларында очрап куйсаң ялгыш.

Күн куртканың һәрбер кесәсендә
Коралларның иң-иң хәтәрләре.
«Мерседес»лар чаба ажгырышып,
Төтен белән күмеп шәһәрләрне.

Хәвеф көтә безне урамнарның
Һәр чатында, һәрбер почмагында.
Безнең җаннар йөри шул буынның
Кесә төбендәге пычагында.

*1994*

## *Болай барса*

Чүп-чар савытында
Актарына бер карт.
Һәрбер чүпне карый
Әйләндереп кат-кат.

Нәрсәнедер ала,
Нәрсәнедер куя.
Нәрсә эзли соң ул,
Нинди байлык җыя?

Эзлиме ул ипи,
Буш шешәме әллә?
Кем төшергән аны
Менә шушы хәлгә?

Һәркөн килә бу карт,
Һәркөн актарына.
Болай барса дөнья —
Чүплек җитми башлар
Илнең картларына.

*1994*

## *Ялганнар*

Ялганнар, ялганнар, ялганнар —
Дөньяны уратып алганнар.
Давыллар аударган агачтай,
Ялганнан батырлар ауганнар.

Ялганнар, ялганнар, ялганнар —
Һәрберсе төрле төс алганнар.
Чәчәк, дип үрелеп алырга
Никадәр гашыйклар янганнар.

Ялганнар, ялганнар, ялганнар —
Күзләргә яшь булып тамганнар.
Беркатлы кешеләр күңелендә
Эремәс таш булып калганнар.

Ялганнар, ялганнар, ялганнар...
Үзгәрә дисәк тә заманнар —
Юк, заман үзгәрми, бары тик
Үзгәрә, яңара ялганнар.

*1994*

* * *

Һәркем патша була алмый,
Тәхетсез торып була.
Тәхетләргә утырып та
Бәхетсез булып була.

Дөнья шулай яратылган —
Һәркемнең үз өлеше.
Алтыннардан кыйммәт була
Кемнәрнеңдер көмеше.

Бәхетне үлчәүче бизмән —
Үзебезнең нәфесебез.
Нәфесебез зурайган саен
Кечерәя бәхетебез.

*1994*

* * *

Дөнья — камыт,
Туу белән киясең дә —
Булмый кабат салып.

Тормыш — тәртә,
Күпме генә чәбәләнмә —
Арасына кертә.

Язмыш — арба,
Гел шуны тартып йөрисең,
Кая гына барма.

*1994*

* * *

Кычкырасы килә кайчак:
— Коткарыгыз, батабыз!
Алда — сазлык,
артта — упкын,
Торабыз бер чатта без.

Ташланабыз анда, монда,
Тотынырга юк казык.
Әкрен-әкрен суыра төпкә
Сәрхушлек дигән сазлык.

Китә алмыйбыз еракка,
Без — азгынлык тоткыны.
Тора йотып берәм-берәм
Фәхишәлек упкыны.

Чистарынмак булсак та без —
Коеныр су калмады.
Сасы күл булып җәелде
Бу дөньяның ялганы.

Кычкырасы килә әрнеп:
— Коткарыгыз, батабыз!
...Кем коткарсын? —
Упкыннарга
Бер-беребезне тартабыз.
Бергәләшеп батабыз.

*1994*

## *Мәңгегә ат бәйләүче юк*

Чибәр кыз мин,
                    гүзәл кыз мин,
Гел шуны белеп йөрим.
Ямьсезләрдән эчтән генә
Кызганып, көлеп йөрим.

Акыл дисәң, акыл миндә
Тулып-түгелеп тора.
Яшермим байлыгымны да,
Бар да күренеп тора.

Аяклар — алтын багана,
Сакчылар юк капкада.
Капкам ачылырга тора,
Җилләр килеп какса да.

Зарланмыймын, булып тора
Байлыкны күрүчеләр,
Пар ат белән җилкапкадан
Чаптырып керүчеләр.

Шул гына эчне пошыра —
Сылтап заманасына,
Мәңгегә ат бәйләүче юк
Капкам баганасына.

*1994*

## *Дөнья бетәр иде күптәннән*

Җәйләрнең дә җылылыгы бетте,
Әллә инде дөнья суына.
Хәер, кояш күптән сүнәр иде,
Тапшырсалар кеше кулына.

Һәр кочегар утынын урлар иде,
Онытыр иде аны ягарга.
Учагына шырпы сызган өчен,
Ярты бирер идең аңарга.

Атна буе кояш чыкмас иде
Күк йөзенә кайбервакытта.
Бөтен дөнья охшап калыр иде
Уты сүнгән салкын тәмугка.

Ярый әле, бик күп нәрсәләргә
Кулың кыска, көчең юк, бәндәм.
Җирләр, күкләр
синең кулда булса,
Дөнья бетәр иде күптәннән.

*1994*

## *Оялчан халык*

Күптән шуны
шәйләп киләм —
Без бик оялчан халык.
Алыштырабыз исемне
Татарлыктан оялып.

Эчәсе килмәгәндә дә,
Бирсәләр әгәр салып —
Эчәбез, янда утырган
Исерекләрдән оялып.

Җаныбыз бик тартмаса да,
Чишендек, шәрә калдык.
Фәхеш кылдык, үзебезнең
Тыйнаклыктан оялып.

Сүгендек без, катлап-катлап,
Һич тә кимен куймадык.
Чөнки без әдәпле булып
Күренүдән оялдык.

Ыштанын пычраткан бала
Әйтмәгән күк, оялып,
Йөрибез чистара алмый,
Бар пычракка буялып.

*1994*

## *Парадокслар*

Бер уйласаң, бу заманда
Парадокслар күп бит:
Энә урласаң — караклык,
Кыз урласаң — егетлек.

Башкаларны мактау әйбәт,
Булса мактап сөйләрлек.
Ә хатыныңны мактасаң,
Бусы була юләрлек.

Урамда сугышып йөрсәң,
Тартыласың җавапка.
Өйдә хатынны тукмасаң,
Санала ул савапка.

*1994*

## *Түбәтәй*

Татарлыктан качар өчен,
Түбәтәйләрне салдык.
Түбәтәйсез генә түгел,
Шулай башсыз да калдык.

Хәзер тагын түбәтәйләр
Керде безнең өйләргә.
Ләкин башлар гына бик әз
Түбәтәйләр кияргә.

*1994*

## *Ташлар һәм башлар*

Таш кискән кешеләр бар,
Баш кискән кешеләр бар;
Таш кискәннәр баш кисми,
Баш кискәннәр таш кисми.
Тик нигәдер бу җирдә
Таш белән баш гел бергә,
Аерылу юк боларга
Хәтта зират-кабердә.
Әмма тагын шунсы бар:
Ташлар өстә, баш аста.
Болай булмас иде дә,
Күрәсең, дөнья хаста.

*1994*

## *Онытып куйсак*

Һиндстаннан килгән чәйләр тәмле,
Эчәбез гел аны кич-иртә.
Авырып китсәк, кирәк була безгә
Туган якта үскән мәтрүшкә.
Җылы яктан килгән җимешләр дә
Авызлардан сулар китерә.
Ә чирләсәк, үз бакчаңда үскән
Кура җиләк тизрәк терелтә.
Онытып куйсак туган якларны без,
Дөнья куып йөреп кич-иртә,
Мәтрүшкәсе, җиләкләре белән
Тәңре безнең искә төшертә.

*1993*

## *Өч нәрсә*

Туган ягына кешене
Өч нәрсә гел тартып тора.
Кайда йөрмә, шул өч нәрсә
Тартып алып кайтып тора.
    Беренчесе — балачагың,
    Агачтагы алма чагың.
    Эзли кеше шул алманы
    Белсә дә алданачагын.
Икенчесе — була өең,
Ул — кендек бәйләгән төен.
Йөртә кеше үз тәнендә
Шул төеннең бетмәс җөен.
    Өченчесе — тапкан анаң,
    Бар яхшылык безнең аннан.
    Кеше ятим, кеше үксез —
    Шушыларны алсаң җаннан.

*1993*

## * * *

Кешеләр бик вакланды, дип,
Күңелем, гаҗәпләнмә.
Аккан сулар да саега,
Тау да тәбәнәкләнә.
    Мәңгелек түгел икән шул
    Бөеклек һәм олылык.
    Шушы хаклыкны аңларга
    Җитми бары кыюлык.

*1993*

## *Чарасызлык*

Беркемгә дә баш имәм дип,
Әйтмә һич — алга узып.
Иелмәс башларны, дустым,
Идерә чарасызлык.

Адашмам, димә — юлларны
Иң башта кара узып.
Кермәм, дигән сазлыкларга
Кертә ул чарасызлык.

Каргамам, димә, дөньяны
Гайрәтең барда кызып.
Әйтмәс сүзләрне әйттереп
Каргата чарасызлык.

Күпләрнең гомер юлы бит
Сихерле кара сызык.
Чыгалмыйсың шул сызыктан,
Бәйләсә чарасызлык.

*1993*

## *Көрәшчеләр булдык*

Көрәшчеләр кирәк, дидек, һәрчак,
Эшлеклеләр кирәк димәдек.
Эшчәннәрдән комсыз, саран, диеп,
Ничек кенә итеп көлмәдек.
Көрәшчеләр, көрәшчеләр, дидек,
Гаделләргә
Вакансия игълан итмәдек.
Ялган чәчеп, шапырынулар урдык,
Гаделлекнең тамырын төпләдек.
Көрәшчеләр кирәк, дидек, һаман,
Акыллылар кирәк димәдек.
Үзебездән акыллыракларны
Эзәрлекли тордык, сөймәдек.
Көрәшчеләр кирәк, дип кычкырдык,
Шәфкатьлеләр кирәк димәдек.
Көчсезләрне таптап, изеп киттек,
Кызгануны һич тә белмәдек.
Көрәшчеләр булдык, көрәшчеләр! —
Башлар таштан, йөрәк корычтан.
Көрәшеп һәм сугышып алабыз без
Һәрнәрсәне хәзер тормыштан.

*1993*

# *Манаралар, айлы манаралар*

Тәрәзәмнән мәчет күренеп тора,
Манарасы аның яшел фәсле.
Түбәсенә кунган алтын ае
Чакырып тора үзенә картны-яшьне.

Һәркөн иртән шул мәчеткә карыйм,
Аумаганмы, димен, манарасы.
Тыныч кына ятып буламыни,
Гел болганып торгач заманасы.

Тәгәрәде күпме манаралар
Чалма чалган башлар белән җиргә.
Урак белән Чүкеч ясап куйдык,
Айны кушып тәре белән бергә.

Берләштердек шулай, укмаштырдык
Динне, телне, гореф-гадәтләрне.
Озыннарны Урак урып торды,
Чүкеп торды Чүкеч шәбрәкләрне.

Сезне кискән саен, манаралар,
Үзебез дә гел кыскара бардык.
Манаралар белән киселә-киселә
Бөеклеген җуйды безнең халык.

Манаралар, айлы манаралар,
Заман йөзен күрсәтүче көзге.
Сезне кисеп — сезне аудармыйлар,
Сезне кисеп, аударалар безне.

*1993*

## *Сабырлык*

Сабыр иткән — морадына җиткән,
Сабырлыкның төбе — сары алтын.
Шулай диеп, сабырлыгың җыеп,
Яшәп килдең һаман, и халкым,
Йөрәгеңә яшереп ут-ялкын.

Ашыкканнар ашка пешәр, дидек,
Сабырлыкның, дидек, тамыры нык,
Күпме үчне, күпме ачуларны
Чыгармыйча эчтә яндырдык,
Тыйды чөнки шушы сабырлык.

Телне дошман тартып алганда да
Тешләшмәдек, булдык сабыр, нык.
Әкрен-әкрен бөкре булып үсте
Сыртыбызга шушы сабырлык,
Торып-торып хәйран калырлык.

Ә сыртыңда шундый бөкре булгач,
Тураюлар авыр шул, халкым.
Ярый инде басып үтермәсә
Сабыр төбендәге сары алтын,
Шуннан сакла безне, и Раббым.

*1992*

## *Кабатлана һаман бер үк сүз*

Әйткән элек безнең бабайлар:
— Авыр килде безгә замана.
Гөнаһлар күп җирдә, гөнаһлар,
Гөнаһлардан дөнья болгана.

Әткәйләр дә әйткән шуны ук:
— Заманалар ай-һай болгавыр.
Хөсетлек күп җирдә, хөсетлек,
Болганулар безнең шуңадыр.

Без әйтәбез хәзер шул сүзне:
— Заманалар авыр, бик авыр.
Бетте җирдә шәфкать, мәрхәмәт,
Кемнәр килеп безне коткарыр?

Яшь буын да әйтер: «Ай, авыр!»
Без тугачтын дөнья болганды...
Йә, әйтегез, җирдә яшәүнең
Бармы берәр җиңел булганы?

*1992*

## *Мәңгелек тартыш*

Һәр күңелдә иблис тә бар — фәрештә дә,
Бара алар арасында мәңге тартыш.
Иблис белән фәрештәнең тартышында
Газапланып языла шулай безнең язмыш.

Була көннәр: күңелне гел иблис били,
Ул тантана итә анда, җырлый, бии.
Мәҗлес ясый —
эчә, тарта, сүгенә, көлә,
Яхшылыкка бернинди дә урын бирми.

Ә кай көнне фәрештәбез өстен була,
Эчкә шәфкать һәм мәрхәмәт кереп тула.
Кулларыбыз гел игелек эшләп тора,
Андый көндә иблис телен тешләп тора.

Тартышмыйча яши алмый алар һич тә,
Бу икәүгә тар, ахры, күңел-җиһан.
Күңелнең бер почмагында, посып кына,
Кем җиңәр,
дип карап тора безнең Иман.

*1992*

## *Карт-корылар болай моңая*

Күбәйделәр эт иярткән кызлар,
Ишегалды гөрли кич саен.
Юеш борыннарын үбә-үбә,
Һәркем мактый үзенең маэмаен.

Каян алган, нинди нәселдән ул,
Нинди ризык аңа ашата.
«Һөнәр»ләрен инде әйткән дә юк —
Бетерерлек түгел санап та.

Гөрләп тора безнең ишегалды,
Этләр өрә, кызлар көлешә.
Этбикәләр, берсен-берсе ялап,
«Мәхәббәт»ен шулай бүлешә.

Карт-корылар шушы тамашаны
Читтән карап болай моңая:
«Эт иярткән кызлар арткан саен
Бала ияртәннәр азая».

*1992*

## *Йөрәккә эндәшү*

Түзеп була вакытлыча
Авырлыкка.
Нәрсәсе бар —
　　　　керден-чыктың
Янган утка.

Боз өстеннән йөреп була
Яланаяк —
Суык кала табаныңны
Тик бер ялап.

Су астында торып була
Суламыйча.
Әз кайгыга түзеп була
Еламыйча.

Гомер дә бит вакытлыча
Тигән бүләк.
Шуңа күрә һәммәсенә
Түзү кирәк.
Түзик, йөрәк!
Түзик, йөрәк!

*1991*

* * *

Балачак хыялы — очар кош,
Тартыла биеккә-биеккә.
Туктауны белми ул очыштан,
Канаты кояшка тиеп тә.
Яшьлекнең хыялы — агымсу,
Ашкына еракка, еракка.
Бара ул барачак җиренә
Туры да, тауларны урап та.
Картлыкның хыялы — авыр таш,
Өстери тирәнгә, тирәнгә.
...Биеклек, ераклык, тирәнлек —
Яшисең шуларны сөйгәнгә.

*1991*

# *Юнәлеше үзгәрүчән җил*

Синоптиклар хәбәр итә еш кына:
«Юнәлеше үзгәрүчән көчле җил!»
Кайсы яктан ышыкларга соң өйне,
Җилләр шулай борылгалап торгач гел?!
Әллә барлык тәрәзәсен кадаклап,
Качаргамы башны алып өйләрдән?
Бик арыдык, бик алҗыдык бит инде
Юнәлеше үзгәрүчән җилләрдән.
Кайчан әйтер синоптиклар безгә:
«Алда матур, аяз көннәр көтелә»?
Ә хәзергә тотырыксыз салкын җил
Тузан сибә кешеләрнең битенә.

*1991*

# *Әйтегез, әгәр белсәгез*

Әйтегез, әгәр белсәгез,
Әйтсәгез — сезгә рәхмәт,
Кайларда йөри каңгырап
Җаннан куылган шәфкать?

Чырайлар шундый караңгы,
Елмаюны югалттык.
Кайсы елгаларга акты
Йөздән юылган шатлык?

Әйтегез, кайда югалды
Инсафлы гореф-гадәт?
Кемнәр почмагында үлде
Өйдән куылган әдәп?

Тәннәр керле, җаннар керле,
Пычракка тәмам баттык.
Нинди юллар тузанында
Күмелеп калды пакьлек?

Һәрбер түрә каршысында
Йөзләрне җиргә ордык.
Нинди учакларда янды
Безнең Горурлык, Зурлык?

Көн тудымы — күңелләрдә
Сораулар тора артып:
Ник бу болгавыр дөньяда
Бердәнбер Вөждан артык?
Бердәнбер Намус артык?

*1991*

## *Ирек туа җирдә тукмалып*

Халык булып түгел, сарык булып
Туган булсак әгәр дөньяга,
Болыннарда үлән утлар идек,
Сулар эчәр идек елгада.

Һәр яз саен кыркып торсалар да,
Үсеп торыр иде йонybыз.
Кирәк булмас иде кием-салым,
Өстә булыр иде тунybыз.

Безне көткән көтүчеләргә дә
Калмас иде артык эш-мазар:
Бер көтүгә җитә бер чыбыркы,
Бер көтүгә җитә бер абзар.

Хәер, өстә әйбәт туның булгач,
Артык хәтта абзар-курасы,
Өшегәндә шул чыбыркы белән
«Җылыткалап» кына торасы.

Бәлки, әле балык булып тусак,
Шәбрәк булыр иде тагын да —
Сарык бит ул кычкырырга мөмкин,
Һич югында суйган чагында.

Ә балыклар кычкыра да алмый,
Тончыктырдың-куйдың аларны.
Дөньяда син табып кара тагын
Балыктан да мескен җаннарны.

Телсез балык, мескен сарык түгел,
Халык булып җиргә туганбыз.

Шуңа да без көтүчеләр өчен
Мәшәкатьле, җайсыз булганбыз.

Көрәшәбез, ирек даулыйбыз гел,
Кычкырабыз һаман: без — халык!
Көтүчеләр яңа камчы үрә,
Ирек туа җирдә — тукмалып.

*1991*

## *Татарстан байрагы*

Җилфер-җилфер итә байрагыбыз,
Ниләр сөйли соң ул җилләргә?
Көрәшүче татар халкыннан ул
Сәлам әйтә азат илләргә.

Ничә гасыр изелеп яшәдек без,
Телсез, динсез, илсез, байраксыз.
Коллар кулындагы байраклар бит
Азат халык өчен яраксыз.

Өч төс балкый безнең бу байракта:
Ак төс — безнең намус төсебез.
Яшел төсе — безнең яшәү төсе,
Кызылында чагыла көчебез.

Җилфер-җилфер итә безнең байрак,
Элеп куйдык аны биеккә.
Дөнья безнең шушы байрак аша
Омтылышны күрсен ирекккә.

*1991*

## *Халыкка эндәшү*

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас:
Сабырлыкмы әллә ярсумы?
Ярсу булсаң — ярсыр вакыт җитте,
Таләп итә һәрбер җан шуны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Түбәнлекме әллә зурлыкмы?
Зур икәнсең — әйдә, тураеп бас,
Алып ташла иңнән хурлыкны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Турылыкмы әллә ялганмы?
Туры булсаң — турылыгың белән
Турайтырга кирәк заманны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Мескенлекме әллә хөрлекме?
Хөр икәнсең — дөнья белән сөйләш
Баштан салмый гына бүрекне.

*1990*

## *Каргалар күтәреп китәр*

> Телең булмаса,
> күптән карга
> күтәреп китәр иде.
>
> *Халык сүзе*

Ничә гасыр баш өстендә
Козгыннар һәм каргалар
Өер-өер очып йөри,
Каркылдашып «кар да кар!»

Көтеп йөри алар безнең
Телсез калуыбызны,
Карга өереннән куркып,
Өнсез калуыбызны.

Телсез калгач, алар бик тиз
Күтәрерләр-китәрләр.
Аннары безне дә шулай
Кара карга итәрләр.

Очарбыз без дә каркылдап,
Онтып кемлегебезне.
Йолкырлар туган җирләрдән
Шулай кендегебезне,
Җуйсак без телебезне.

*1990*

## *Халык бар*

Горурлыгы, җыры булса,
Җырлап атлар юлы булса —
Димәк, әле халык исән!

Тураерга биле булса,
Күтәрергә иңе булса,
Авызында теле булса —
Димәк, әле халык исән!

*1990*

## * * *

Тау ватты, таш кисте кеше,
Арымады.
Тимер бөкте, янды-пеште,
Арымады.
Сазлыкларны киптерде ул,
Арымады.
Чүлләргә су китерде ул,
Арымады.
Иртә торды, гел соң ятты,
Арымады.
Ә бервакыт кинәт аның
Бетте эше.
Менә шунда бик нык ару
Сизде кеше.

*1977*

* * *

Урман — колак,
                        кыр — күз,
Шулай булган элек.
Урман-кырлар барсын
Торган ишетеп-күреп.

Бермәлне без кинәт
Иркенлеккә чыктык:
Урман колагына
Балта белән суктык.

Чукракланды урман,
Ишетмәде берни.
Бульдозерлар анда
Йөрде бии-бии.

Химиябез белән
Сукырайттык кырны,
Соңгы тургай белән
Җиргә күмдек җырны.

Сукыр, чукрак иткәч
Урман-кырыбызны,
Сагына башладык без
Күмгән җырыбызны.

Күмелгән җыр, белмим,
Шытар микән кабат?
Ыңгыраша урман
Безнең күзгә карап.

*1989*

## *Җир өстендә җиз кыңгырау*

Җир өстендә җиз кыңгырау,
Чың-чың итә тавышы.
Анда җирнең шатлыгы һәм
Анда җирнең сагышы.

Аңа тия җил иссә дә,
Күкләр куйса да күкрәп.
Һәр тавышка сискәнә ул
Һәм китә тетрәп-тетрәп.

Тоташкан аның теленә
Дөньяның бар җепләре —
Юллар, сулар,
урман, кырлар,
Ай йолдызлы күкләре.

Сизә йолдыз атылса да,
Көне-төне ул уяу.
Җир өстендә мәңге сакта
Кеше — сизгер кыңгырау.

*1986*

## *Мәрхәмәт*

Теткәләнә, туза бик тиз,
Мишень бит безнең йөрәк.
Тузмас иде, бер-беребезгә
Булсак мәрхәмәтлерәк.
Елмайсак, куллар кысышсак,
Йөрешсәк әгәр күбрәк,
Булыр иде бу дөньялар
Тагы да мәхәббәтлерәк.
Җирдә күпме кешеләргә
Кирәк таяныч, терәк.
Мәрхәмәтебез белән без
Булыйк мәһабәтрәк.

*1986*

## * * *

Ай-яй, көннәр озын инде,
Берсен бишкә бүләрлек.
Кулларыңда эш булмаса,
Саргаюдан үләрлек.
Ай-яй, төннәр озын инде,
Таңнар атмый йөдәтә;
Мең төрле уй туа башта,
Мең төрле хис йөрәктә.
Язлар озын, көзләр озын,
Чамасыз озын кыш та.
...Күренми үтә дә китә —
Гомер генә бик кыска.

*1974*

## *Алмагач һәм кабак*

Бакчабызда безнең кабак үсте
Алма агачына уралып.
Ботаклардан ботакларга сикереп
Үрләде ул тиз-тиз югары.

Һәм, ниһаять, менеп җитте дә ул
Алмагачның иң-иң очына,
Карап торды яфракларын җилпеп,
Кош шикелле очына-очына.

Биеклекне бик яратты кабак,
Эреләнде күзгә күренеп.
Хәзер инде миңа беркемнең дә
Буе җитмәс, диде үрелеп.

Тик беркөнне һич тә көтмәгәндә
Шартлап сынды гүзәл алмагач.
Тәгәрәде кабак һәм ярылды,
Тотынырга агач калмагач.

Тәгәрәргә тиеш иде кабак,
Бөтенесе монда ап-ачык:
Озак барып буламыни соң ул,
Башкаларның иңенә басып?

Кызганыч, тик алмагачым гына
Сынды гөрләп үскән җиреннән.
Кабаклар
 шул сындырмыйча төшми
Тотынып үскән агач иңеннән.

*1985*

## *Безне соң кем дәвалар?*

Әзмени кеше күңелендә
Сөйләнелмәгән зарлар.
Әзме, җылы сүз ишетми,
Таш булып каткан җаннар.

Әзмени, кемдер рәнҗетеп,
Нурын сүндергән күзләр.
Әзме, утлы күмер булып,
Бәгырьне өткән сүзләр.

Әзмени беркем белмәгән,
Йөзне кызарткан эшләр.
Әзме, докторга күрсәтми,
Яшерен йөрткән шешләр.

Әзме, никадәр бәйләп тә,
Саркып яткан яралар.
Кешелексезлек чиреннән
Безне соң кем дәвалар?

*1982*

## *Арифметиканың дүрт гамәле*

Берле санын шулай
Җидегә бүлү серен
Әни каян белгән?
Бер сыныкны ул бит,
Һәрчак тигез итеп,
Җиде өлешкә бүлгән.
Кушу-алуны да
Укытучыдан түгел,
Өйрәнгән тормыштан.
Безгә җитми икән —
Үз өлешеннән алган,
Безнекенә кушкан.
Тапкырлау гамәле
Һәркайсыбыз өчен
Җиңел түгел, беләм.
Тик аның да серен
Безгә караганда
Әни яхшы белгән.
Без бер эш эшләсәк,
Әни аны эчтә
Яшереп яткырмаган —
Безнең эшебезне
Кешегә сөйләгәндә,
Унга тапкырлаган.

*1982*

## *Һәркемгә үз өлеше*

Теләде шундый бер теләк
Дан, шөһрәт сөйгән бәндә:
«Тау кадәрле дәрәҗә бир,
Кодрәтле ходабәндә».
Теләге кабул булды бит,
Сорагач ертып йөзен.
Тик дәрәҗә авырлыгы
Сытты мескеннең үзен.

Ә байлыкка табынучы
Теләде берөзлексез:
«Байлыгым булсын диңгез».
Теләген ишетте күкләр,
Ул кабул булып кайтты.
Байлыгы зур диңгез булды,
Һәм үзе шуңа батты.

Теләде өченче берәү,
Хәер, уйлады эчтән:
«Кирәкми дан да, байлык та,
Аерма гына эштән».
Һәркөн саен җиң сызганып
Тотынды ул эшенә —
Иң бай кеше дә ул булды,
Иң шөһрәтле кеше дә.

*1977 – 1981*

## *Сорау һәм җавап*

Кабатлыйм бер сорауны
Өнемдә һәм төшемдә:
«Кеше булып яшәргә
Нәрсә кирәк кешегә?»
Диңгез әйтә: — Тирәнлек.
Урман әйтә: — Бердәмлек.
Таулар әйтә: — Горурлык.
Юллар әйтә: — Турылык.
Җир эндәшә: — Юмартлык.
Чык суы әйтә: — Кыюлык.
Ипи әйтә: — Олылык.
— Гүзәллек,— диләр Гөлләр.
— Ireклек,— диләр Җилләр.
— Нык канат,— ди Бөркетләр.
— Биеклек,— диләр Күкләр.
Һәм шушылар өстенә
Кирәк тагын иң элек,
Кешене кеше иткән
Бер нәрсә — кешелеклелек!

*1981*

## *Ипигә мәдхия*

Авыр чирдән сыкрап яткан чакта
Тик бер кабым ипи капса кеше,
Терелүгә ышана башлый тагын —
Ипидә бар ышандыру көче.

Тормышында күңелсезлек туып,
Кырыслыктан ямьсезләнсә төсе,
Елмая ул, кулына ипи алса —
Ипидә бар елмайттыру көче.

Юктан гына дошманлашса әгәр,
Булмаганда кичермәслек үче,
Бер телемне бүлеп дуслашалар —
Ипидә бар дуслаштыру көче.

Ерак галәмнәргә очканда да,
Иң беренче ипи ала кеше,
Исән-имин шул кайтара җиргә —
Ипидә бар бөек тарту көче.

Таянырга нокта булып шулай
Тудыра ул бер олылык хисе.
Табынында ипи торса гына
Үзен иркен, горур сизә кеше.

*1978*

# *Әнкәбезгә үз идек*

Без, без, без идек,
Без алты пар күз идек:
Алтыбыз да дөньяга
Әйтелмәгән сүз идек.

Без, без, без идек,
Без алты пар кул идек:
Эшләнмәгән эш идек,
Башланмаган юл идек.

Без, без, без идек,
Без бит алты җан идек:
Тормыш дигән офыкта
Яктырмаган таң идек.

Таң булып атмасак та,
Дан булып кайтмасак та,
Без барыбер без идек,
Әнкәбезгә үз идек.

*1977*

## *Туган ягы кирәк кешегә*

Читтә йөргән чакта, сагындырып
Керер өчен төнлә төшенә,
Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле
Туган ягы кирәк кешегә.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,
Шатлыкларын ишеттерер өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Йөри-йөри күңеле тупасланса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,
Бер сафланып алыр өчен тагын
Туган ягы кирәк кешегә.

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм дә кечегә,
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

*1976*

# *Урамда ыгы-зыгы*

Һәркем каядыр ашыга,
Урамда ыгы-зыгы.
Юл күрсәтеп өлгералмый
Светофорларның угы.

Автобуслар, троллейбуслар,
Таксилар чабып тора.
Җәяүлеләр тротуардан
Туктаусыз агып тора.

Берәүләр эшкә баралар,
Берәүләр өйгә кайта.
Йөзләгән табан берьюлы
Таш юлны тукылдата.

Иртә, кич тә, көндез дә —
Гел хәрәкәт урамда.
Үзе бит ул олы бәхет —
Ашыгыр җирең булганда.

*1974*

## *Сиртмәле кое монологы*

Мин — кое, сиртмәле кое,
Яшем йөздән дә өстә.
Гомрем буе кешеләргә
Су бирәм иртә, кич тә.
Сабыйлар ана күкрәген
Иммичә тора алмый,
Ә зурлар минем яныма
Килмичә тора алмый.
Тагын йөз ел эчсәләр дә,
Бетәрлек түгел суым.
Ләкин бераз картаелды,
Менә шунысы кыен.
Хәзер машина заманы,
Бөтен нәрсә яңара.
Мине тарткан киленнәрнең
Һаман кулы кабара.
Космоска оча кешеләр:
Уйласаң искитмәле.
Ә мин һаман шыгыр-шыгыр,
Ә мин һаман сиртмәле.
Иелүләрдән, бөгелүләрдән
Талса да бил һәм муен.
Зарланмыймын, эшли бирәм,
Бетмәсен генә суым.

*1965*

# *Ак үлем*

(Поэма)

## 1

Соңгы укол бүген, соңгы укол!
Тәнем буйлап шуыша корыч энә.
Әйтерсең лә салкын тәнле елан
Якынлашып килә йөрәгемә.

Менә чагам, менә чагам, диеп
Үрмәли ул алга салмак кына.
Тамырларга ул кагылган чакта
Калтыранып куя бармак кына.

Ничә еллар аның авызыннан
Сихри тамчы канга тамып торды.
Менә сүнәм-сүнәм дигән учак
Шуның белән генә янып торды.

Шәфкатьсезлек җиле йөзләремә
Килеп бәрелгәндә, тынны өтеп —
Мине бары шул коткарып килде,
Кайнар дулкыннарны читкә этеп.

Тормышымның ерып чыгалмаслык
Кара төннәрендә калган чакта,
Гамьсезлекнең каты диварларын
Йодрык белән кыйнап арган чакта;

Гаделсезлек, күзләремә карап,
Тиленәрчә шыр-шыр көлгән чакта,

Дөньяларның бөтен авырлыгы
Аждаһадай өскә килгән чакта —

Мин тартылдым аңа, чөнки бик күп
Алданылган иде дөньясыннан.
Бер тамчы су харам булмас, дидем,
Эчсәм әгәр ләззәт елгасыннан.

Бу тамчыны авыз ит кенә син,
Аерылып булмый аннан кабат.
Ләззәт елгасының дулкыннары
Ялкын кебек ала сине ялмап.

Онытыла барлык газапларың,
Еракларак чигенә гаделсезлек.
Матурая дөнья, әйтерсең лә
Кигерәләр сиңа яшел күзлек.

Чын бәхете җирдә булмаганнар
Ялган бәхет эзләп таба шулай.
Ялган бәхет сине җитәкли дә
Упкыннарга таба чаба шулай.

Мин дә чаптым сулуларым кабып,
— Тукта! — диеп дәште җилләр генә.
Йөзләремне күреп шул чагында
Елап калды бары гөлләр генә.

Туктамадым. Хәтта гөлләрнең дә
Карамадым яшьле күзләренә.
Чаптым, чаптым! Яшьлек энҗеләре
Сибелеп калды минем эзләремә.

Ә бит мин дә якты дөньяларга
Туган идем бәхет өмет итеп.
Ләкин минем гомер офыгымда
Күгем кара булды, аем — китек.

Әгәр җирдә мин гаепле булсам,
Гаепледер тууым белән генә...
Янып беткән гомер учагымның
Карап торам соңгы көлләренә.

**2**

Мин кем? Белмим. Үзеңә
Бәя бирү читен эш.
Гомер җебем чуалган,
Көтеп тора чишелеш.

Балачагым офыгы
Булды гел-гел болытлы.
Күңелем тулы гамь булды,
Кояш дисәм — шәм булды.

Ипи сорап кул сузсам,
Таш тоттырды язмышым.
Саф су, диеп үрелсәм,
Яшь йоттырды язмышым.

Тук заманда ач булдым,
Бик кадерсез баш булдым.
Әнкәемнең күзендә
Мәңге кипмәс яшь булдым.

Исемем дә онытылды,
Кушаматым Ярканат.
Хәтта минем иңнәргә
Үсалмады пар канат.

Яшем күпме? Егерме?
Бәлки инде җитмештер?
Мин бик яшьли өзелеп
Кимерелгән җимештер.

Бәлки, язгы ташуда
Язда калган боздыр мин.
Ә бәлки, каенынннан
Каезланган туздыр мин.

Тик күләгә ясаучы,
Бәлки, мин бу болыттыр.
Бәлки, тешләп ташланган
Чүплектәге сыныктыр.

Тудым, үстем, яшәдем
Хәрабәләр иләндә.
Күз яшенең тәме бар
Һаман минем телемдә.

Иң беренче ул тәмне
Татыганым исемдә...
Әти китте, без калдык
Кышкы көннең кичендә.

Әй суык көн, буранлы!
Тәрәзәләр бозланган.
Әниемнең күзләре
Сөртә-сөртә кызарган.

Буран улый, мин елыйм,
Әти йөзе сагышлы.
Сыйпый мине башымнан,
Калтырап чыга тавышы:

«Әй җаннарым, җаннарым,
Шикәрләрем, балларым!
Каргамагыз, аңлагыз,
Миңа рәнҗеп калмагыз.

Бәхеткә күп омтылдым,
Һәр саламга тотындым.
Әмма бәхет килмәде,
Тартылдым да йолкындым.

Иркен сулый алмадым —
Тыным кысты тар подвал.
Иркен уйлый алмадым —
Уем кысты тар подвал.

Көчем бетте көрәшеп,
Җылым бетте өләшеп.
Бәлки, бәхет бу йортка
Килеп керер мин юкта».

Әти китте өйләрнең
Бар булган нурын алып:
Оядагы кошчыкның
Җырласы җырын алып.

Күрми идем подвалның
Ямьсезлеген, тарлыгын.
Күрдем, белә башлагач
Башка дөнья барлыгын.

Әйттек: бездә гаделлек!
Әйттек: бездә тигезлек!
Ләкин, никтер, буш булды
Безнең генә имезлек.

Әйттек: бездә һәр кеше
Бер-берсенә дус, туган!
Тик берәүләр подвалда,
Берәү сарайда туган.

Берәүләрнең эте дә
Яши җылы өйләрдә.
Берәүләрнең урыны юк
Хәтта бишек эләргә.

Менә шундый «туганлык».
Менә шундый «тигезлек».
Гомер үтте подвалда
Кандалалар «имезеп».

Артык аста булганда,
Безне беркем күрмәде.
Өебезгә бер тапкыр
Кояш нуры кермәде.

Хәтта гөлләр үсмәде,
Утыртсак та һәр язны.
Күңелемнән ничә кат
«Шартлаттым» мин бу базны.

Яктыртып та карадым,
Кояш рәсеме ясап.
Ләкин минем кояшны
Барды кара төн ашап.

Булмады кул бирүче,
Елап — яшьне күрүче.
Яшьләр — җиргә сеңделәр,
Сүзләр — телдә үлделәр.

Дөнья өчен, ил өчен
Без гомумән юк идек.
Без — мәңгегә сүнсен, дип,
Көлгә күмгән ут идек.

Ә бит килде безнең дә
Кабынасы, янасы.
Бездә дә җан тырпылдый,
Без дә адәм баласы.

Кай ишекне каксак та,
Төртелдек гел ялганга.
Оеша килде олы таш
Безнең керсез җаннарда.

Ташлар аттым ачудан
Биек-биек йортларга.
Кизәндем дә селтәндем
Тәрәздәге утларга.

Тук җаннардан үч алдым,
Күз яшеннән көч алдым.
Көрәшеп тән талчыкты,
Яман кыз, дип, дан чыкты.

Юк, рәнҗетми кешене
Кием, ризык кытлыгы.
Рәнҗетәдер кешене
Гаделлекнең юклыгы.

Иң авыры шул тагын —
Күрү әнкәм күзләрен.
Сыйгандыр ул күзләргә
Яңгыры мең көзләрнең.

Күрмәдем мин аларның
Бер генә дә кипкәнен.
Хәтерләмим шатлыктан
Балкып нурлар сипкәнен.

Әй ул күзләр, ул күзләр!
Рәнҗүдән тулган күзләр;
Мең кайгы сыйган күзләр,
Вакытсыз сулган күзләр.

Ул күзләрдә мең сорау,
Алар — телсез кыңгырау.
Тама яшь, чыкмый тавыш,
Түгелә бары сагыш.

Күрсәм гамьсез күзләрне,
Тук, канәгать йөзләрне,
Искә төште әнкәмнең
Рәнҗү тулы күзләре.

Шул күзләрне шатлыктан
Тик бер кабызыр өчен,
Кайгыларны боз итеп,
Тик бер агызыр өчен;

Күңелендәге җырларны
Тик бер тергезер өчен;
Аккош итеп өметен
Күккә менгезер өчен —

Әй килде бу дөньяны
Үзгәртәсе нигездән.
Ярга сикереп карадым
Тамчы булып диңгездән;

Дулкын булып карадым,
Ишалмадым ярларны.
Ялкын булып карадым,
Эретә алмадым карларны.

Гөл булып үсим, дидем,
Тик җитмәде яктылык.
Бөгелеп бетте сабагым,
Яктылыкка тартылып.

Кош булып очыйм, дидем,
Былбыл идем хыялда.
Үсә алмады канатлар
Оям кысан булганга.

Туып торды хыяллар,
Үлеп торды хыяллар.
Көч җитмәде менәргә —
Биек булды кыялар.

**3**

Беркөн миңа Мәхәббәттән
Хәбәр килде.
Хәбәрчесе — язның сайрар
Кошы иде.

Сайрады ул, дөнья бик тә
Гүзәл, диде.
Ышанырсың сүзләремә
Тиздән, диде.

Шул көнне мин көзге алдым
Кулларыма.
Яз гөлләре кададым чәч
Юлларыма.

Таңнан буяу алып яктым
Йөзләремә.
Кояш нурын сиптем күпләп
Күзләремә.

Иң матурын сайлап кидем
Күлмәгемнең.
Күрдем шунда нәзеклеген
Билләремнең.

Белсәм дә мин гүзәл аккош
Түгеллекне.
Күрдем мин дә җирдә ят кош
Түгеллекне.

Шатлык җырым күкрәгемә
Сыялмады.
Йөрәгемә гүя былбыл
Оялады.

Бу былбылның җыры бик тә
Тансык иде.
Җан капкасы бәхет өчен
Ачык иде.

Ләкин язмыш бу юлы да
Көлде миннән:
Кош очырып чыгарды да
Күңелемнән —

Атты аны упкыннарның
Тирәненә.
Кая барыйм, ничек чыдыйм
Йөрәгемә?

Кем яратсын, кем сөйсен соң
«Подвал кошын»?!
Нәләт сиңа, мең-мең нәләт,
Хур язмышым!

Бетте, бетте, бар да бетте,
Үлде яшьлек.
Юатмачы, якты кояш,
Нурың чәчеп.

Җырламагыз, яз кошлары,
Сөю җырын:
Йөрәгемдә мәхәббәткә
Бетте урын.

Утка ягам өметләрнең
Бүген барсын.
Янсын алар, дөрләп-дөрләп,
Әйдә янсын.

Яндырамын хыялларны
Өеп-өеп.
Ятмасыннар йөрәгемдә
Кара көеп.

Ут төртәмен җырланмаган
Җырларыма.
Үрләсен ул урылмаган
Кырларыма.

Өеп ягам төшләремне,
Өннәремне.
Кызганмыймын көннәремне,
Төннәремне.

Янсын бар да кара төндә,
Учак булып.
Күккә кадалсын ялкыны,
Пычак булып.

### 4

Шушы көннән ак үлемнең
Миңа җиле кагылды.
Ул җил шундый рәхәт иде,
Ул җил шундый ягымлы.

Әнкәм кулыннан назлырак
Иде аның куллары.
Әнкәм җырыннан моңлырак
Иде аның моңнары.

Канатлар үсеп чыктылар
Шулчак минем иңнәргә.
Алар өчен яшьлек белән
Туры килде түләргә.

Очтым, очтым язларыма,
Табармын дип язны мин.
Йөземнең аклыгын түләп
Алдым һәрбер назны мин.

Очтым, очтым алсыз-ялсыз,
Очтым офыклар аша.
Очтым «ярамый» диелгән
Кара сызыклар аша.

Очтым, очтым, бәхет дигән
Тауларны эзләп очтым.
Очтым, очтым, башым куяр
Ярларны эзләп очтым.

Очтым, очтым, дөньяларның
Эзләдем ямен генә.
Очыш бәясен беләдер
Хурланган тәнем генә.

Очтым, очтым җәйләремә,
Очтым ярсып, ашкынып.
Җәйләремнең ал гөлләре
Калды артта яшь коеп.

Очтым, очтым, үз-үземнән
Теләп биек менәргә —
Биек менеп, язмышымнан
Бер шашынып көләргә.

Очтым, очтым туктамыйча,
Очтым мин көзләремә.
Сары яфраклар түшәлде
Үтелгән эзләремә.

Очтым, очтым кышларыма,
Байдыр, диеп, кышларым.
Китеп барган иде ләкин
Мин эзләгән кошларым.

Очтым, очтым белә торып,
Очтым һәлакәтемә.
Оча торгач, барып җиттем
Җимерек мәмләкәтемә.

Тирә-юнем хәзер минем
Шыксыз хәрабә генә.
Барыр юлым дөм караңгы —
Утсыз мәгарә генә.

Тик җанымда үкенү юк,
Тыныч мин, шундый тыныч:
Кеше гомере — бер тотам,
Кеше гомере — бер уч.

Кайгысы, сагышы шунда,
Рәнҗешләре, каргышы.
Йөрәкләр учка сыя, тик
Учка сыймый язмышы.

Бу үлемне нигә ак дигәннәр,
Агы буламыни үлемнең?
Калды микән берәр ак урыны
Теткәләнеп беткән күңелнең!

Төшләргә дә хәзер аклык керми,
Төшләрем дә инде караңгы.
Әкрен-әкрен һәркөн үлеп килдем,
Мин яралы идем, яралы.

Гомеремне ягып бетердем мин,
Булмый инде җанны дәвалап.
Һәлакәткә таба йөгергәндә
Алмадыгыз нигә аралап?

Инде китәм, мәңгелеккә китәм,
Көрәшмәдем түгел, көрәштем.
Үз бәхетен таба алганнардан
Мин көнләштем, үлеп көнләштем.

Китәм, дуслар, ләкин җанымдагы
Рәнҗүләрне китәм калдырып.
Яшьлегемә кушып күпме яктым,
Бетерә алмадым аны яндырып.

Яндырыгыз хәзер аларны сез,
Әверелсен көлгә каргышлар.
Минекенә һич тә охшамасын,
Якты булсын сезнең язмышлар.

Кала әле, кала күз яшьләрем,
Юллар тузанына сибелеп.
Мөмкин булса,
мин шуларны җирдән
Җыеп чыгар идем иң элек.

Тапталмасын иде алар бер дә,
Юккамыни алар түгелгән.
Ә бит җиргә күз яшьләре булып,
Саф энҗеләр коела күңелдән.

Йә, хушыгыз! Инде корыч энә
Зур тамырга килеп туктады.
Мин үземчә яшәп, гомеремә
Үзем куям соңгы ноктаны.

Соңгы сүзем әйтәм әле сезгә,
Булсагыз да бик зур, көчлеләр:
Үксезләрнең төп терәге — шәфкать,
Шәфкатьлерәк булыгыз, кешеләр.

*1990*

## *Эчтәлек*

**Син**

«Бу дөньяның бар кызыгы...» . . . . . . . . . . . . . 6
«Кар йомарлап аттым...» . . . . . . . . . . . . . . . 6
Бүләк итә алам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Кояшка җитми кулым . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Көзнең бер күңелсез көнендә...» . . . . . . . . . 9
Үзенә йотып иң зур хәбәрен... . . . . . . . . . . . 10
Вәгъдә бирми генә . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кызыл кар яуган булыр . . . . . . . . . . . . . . 12
Күләгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Болан кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Бер чәчәк алачакмын . . . . . . . . . . . . . . . 15
Адашты башкайларым . . . . . . . . . . . . . . . 16
Тоткын йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Һәм шаккаттым... . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Коеныйм бер серле күлеңдә . . . . . . . . . . . . 18
Йә, нәрсә дип әйтим? . . . . . . . . . . . . . . . 19
Мине яратмаган кызга . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Кояш чыга, кояш бата...» . . . . . . . . . . . . 21
«Һаваларда очкан кошларның...» . . . . . . . . . 21
Кульяулык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Ычкынырмын димә . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
«Ул» булыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Изүләрне ачып бара идем...» . . . . . . . . . . . 24
Сагынасыңмы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Нидер булды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
«Күзләреңне нигә яшерден соң...» . . . . . . . . 27
Аңлый гына алам . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
«Һәр агачта утын гына күрсәң...» . . . . . . . . . 28
Мәхәббәт һәм сагыну турында . . . . . . . . . . 29

Яңа кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Шуны бел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Син барлыкны тоеп . . . . . . . . . . . . . . . 31
«Аллар булам әле бер...» . . . . . . . . . . . . 31
Үкенмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
«Син әле кабынмаган ут...» . . . . . . . . . . 33
Фәнис-Нурсөя кебек . . . . . . . . . . . . . . 34
Безнең ара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Мәхәббәт маҗарасы . . . . . . . . . . . . . . 35
Югарыда гына кал идең . . . . . . . . . . . . 36
«Суындың, дип әйтәсең син...» . . . . . . . . 36
«Боз өстендә ике гашыйк...» . . . . . . . . . . 37
Әллә төш бу, әллә өн булды . . . . . . . . . 38
«Сине кемгә тиңлим икән...» . . . . . . . . . 39
«Яратам» дип әйтмичә тор...» . . . . . . . . . 40
«Сафлыкка шундый нык сусалган...» . . . . . 41
«Яз килмәсәң, миңа күзләрең кил...» . . . . 42
Күзге яшен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
«Хатлар язам сиңа...» . . . . . . . . . . . . . 44
«Язмыш бүләк иткән бер кешемме...» . . . . 44
Оялчан гөл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Сәбәп тап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Бетте дөнья гамьнәре . . . . . . . . . . . . . 47
«Сиңа булган сөюемне...» . . . . . . . . . . . 48
Әй кара каш! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Соңгы чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Кыюсыз парлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Таш диварлы крепость *(баллада)* . . . . . . 51
Калсын җирдә безнең сөю . . . . . . . . . . . 52
Бул хуҗа! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Сызгыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Мәхәббәткә ялвару . . . . . . . . . . . . . . . 55
Бирмә мине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Умырзая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Кайда ул? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Үлчәү юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Синең яктылык . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Алмаштырмыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Ике алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Бер-беребезгә...» . . . . . . . . . . . . . . . 63

Минем өчен саклагансың . . . . . . . . . . . 64
Теләмим . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Карадым да кара күзләреңә...» . . . . . . . . 66
«Мин сине хыялда тудырдым...» . . . . . . . . 67
«Арттан килеп, минем күзләремне...» . . . . . . 68
Бер тәлгәш . . . . . . . . . . . . . . . . 69
«Чаганның тик бер яфрагы калган...» . . . . . . 69
Очрашырга тиешбез . . . . . . . . . . . . . 70
Әйтәм, әйтәм . . . . . . . . . . . . . . . 71
Сиңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Шушы ышаныч . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Күптән инде әйтешкән юк...» . . . . . . . . . 74
Сөюче һәм сөелүчеләргә . . . . . . . . . . . 75
Беләсе иде . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Узган көннәр — өзгән гөлләр икән...» . . . . . . 77
Беркем сизмәде . . . . . . . . . . . . . . 78
«Урам буйлап атлап барам...» . . . . . . . . . 79
«Беребез кызып китүчән...» . . . . . . . . . . 79
«Әйттең миңа уңганым, дип...» . . . . . . . . 80
«Гел шулай керәсең төшемә...» . . . . . . . . 81
«Очрашырга чакыр мине...» . . . . . . . . . . 82
«Әбәү, мәхәббәтсез! — дидең...» . . . . . . . . 83
Син бар . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
«Әллә күктә яшен гөлт итте...» . . . . . . . . 84
«Ярларда ялгыз калдырмам...» . . . . . . . . . 85
«Әгәр йөрәгең таш булса...» . . . . . . . . . 85
Үпкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
«Гөнаһсызга кәефең кырсам...» . . . . . . . . 87
Булды инде . . . . . . . . . . . . . . . . 88

**Мин**

Матур күренеш . . . . . . . . . . . . . . . 90
Кара сакал . . . . . . . . . . . . . . . . 91
«Түзә алмый пычрагына...» . . . . . . . . . . 92
Картлык . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Хәтер аланнары . . . . . . . . . . . . . . 93
Яралы кош тавышы чыгарып . . . . . . . . . 94
Күңелемдә ныгый шул нәрсә . . . . . . . . . 95
«Йөрәгемне вак-вак кисәкләргә...» . . . . . . . 96

Кайсы зуррак . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Соңгы яшь тә кипкән инде . . . . . . . . . 98
Күзге мизгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Сорау белән җавап арасы . . . . . . . . . . 100
Гел сакта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Бар әле, бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
«Хозурланып карап ята идем...» . . . . . . 103
Үпкәләмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Кояш баеганда . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Ак кәгазьдә — ак уйлар . . . . . . . . . . . 105
Мин юклыкны, бәлки, беркем сизмәс . . . . . 106
Кем матурлар дөньяны? . . . . . . . . . . . 107
Телем-телем телмәс иде . . . . . . . . . . . 108
«Язам-сызам...» . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Иске машина . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Яктылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Алар да бит һәрчак очышта . . . . . . . . . 111
Бөтенләйгә ташлап китмәдең . . . . . . . . 112
Егылыр ул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Егерме яшьлек булып . . . . . . . . . . . . . 114
Киек Каз Юлларыннан . . . . . . . . . . . . 115
«Мине хәзер, никтер, күкләр тарта...» . . . . 116
Йокысыз сәгатьләр . . . . . . . . . . . . . . 117
Гомер үтә тора . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Рәхмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
«Айкый-айкый йөргәндә дә...» . . . . . . . 119
Күкләр дәшми . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Үз оян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Ак болытлар булып агыла күктән . . . . . . 123
«Бәхет өчен, шатлык өчен...» . . . . . . . . 123
«Эшләр өчен әле эшем бар...» . . . . . . . . 124
Күз нурларым . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Яз кошы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
«Сыгылган чаклар була...» . . . . . . . . . 127
Яшьлек эликсиры . . . . . . . . . . . . . . . 128
«Ачык иде пәрдәләрем...» . . . . . . . . . . 129
«Мин кыр казы нәселеннән, ахры...» . . . . . 130
Мин бары тик... . . . . . . . . . . . . . . . . 131

«Керми киттем каен урманына...» . . . . . . . . . 132
Кызлар үтеп киткәч кенә . . . . . . . . . . . . . 133
Яшәп ятам моң-зар белми генә. . . . . . . . . . . 134
Була . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Җаваплы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Тыныч кына яшим . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Илаһи мизгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
«Һәр яз саен яңа гөлләр...» . . . . . . . . . . . . 138
Эчтем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
«Язмыш миңа бик күп бирде...» . . . . . . . . . . 140
«Тәгәри китте йомгагым...» . . . . . . . . . . . . 141
Кошлар юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Никтер, төшми әле убылып . . . . . . . . . . . . 143
«Күпме юллар уздым җирдә...» . . . . . . . . . . . 144
«Әй, бар иде яшь чаклар...» . . . . . . . . . . . . 144
Таулар аша үтә юлларым . . . . . . . . . . . . . . 145
Ни эзлим? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Яңа дәфтәр ачканда . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Алдану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Җиңелү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Уйлыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Җыр калдырыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
«Матур кызга гашыйк булу саваптыр...» . . . . . . 151
«Төшләремдә, никтер, атлар күрәм...» . . . . . . . 152
«Күкрәгемнән җырлар бәреп чыга...» . . . . . . . . 153
Сагынып сөйләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Шушы килеш яратыгыз . . . . . . . . . . . . . . . 156
Хаҗга барган кебек саваплы . . . . . . . . . . . . 157
«Зур дәрьялар кичтем...» . . . . . . . . . . . . . 158
Утлы корал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Шундый-шундый төшләр керә . . . . . . . . . . . . 159
Бирим, диеп, яктылык . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Мин халкымның баласы...» . . . . . . . . . . . . 161
«Китәсе килә кайвакыт...» . . . . . . . . . . . . . 161
Курай иткән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
«Син дә хәлсезләндең, йөрәк...» . . . . . . . . . . 163
«Яндырамын хәтер учагында...» . . . . . . . . . . 163
Дошманнарым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Каләм эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Көттермә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

«Моңлы күңелем...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Кара урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
«Тукта, тукта, кем елый соң...» . . . . . . . . . . 169
Рәхмәт укыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Елый белмәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
«Язмыш, язмыш...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Соңгы сулышыма кадәр . . . . . . . . . . . . . . . 174
Ишекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Ару турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Әнкәй тирбәтә бишек . . . . . . . . . . . . . . . . 177
«Ялгышмам дип уйлый идем...» . . . . . . . . . . . 178
«Мин бер агач — җиргә егылып үскән агач...» . . . . 179
Өйрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Күңел күзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
«Күңел һәрчак кайнап торды...» . . . . . . . . . . 182
Гомернең һәрбер көнендә . . . . . . . . . . . . . . 183
Сагышларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
«Юл буенда бер чәчәк...» . . . . . . . . . . . . . . 185
«Калганда караңгы төннәрдә...» . . . . . . . . . . . 186
«Малай чагым шул минем...» . . . . . . . . . . . . 187
Тугры дус . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Аерылмасам әгәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Каз кычкыра . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
«Җир әйләнә, диделәр...» . . . . . . . . . . . . . . 191
«Дөньяда мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
«Беренче кат кайгыны...» . . . . . . . . . . . . . . 192
Әткәм төсе тыныч көннәрдә *(туплам)* . . . . . . . 193
Яшьсез генә елый йөрәгем *(туплам)* . . . . . . . 199

**Без**

Мактау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Гөл тамыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
Иске ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Кабырга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Көч кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Поши . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Йолкыш эт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
«Аерылганны аю ашар...» . . . . . . . . . . . . . . 218
Тора-бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219

Ярлыка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
«Газраилгә эш кимеде бугай...» . . . . . . . . . . 221
Шул бер сүз инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
Өй эте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Теләсә ничек алдый . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
Күзге бакча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
Нигә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Намусыңа күз ташла бер . . . . . . . . . . . . . . 226
Һәрвакытта янәшә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Агач ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Таш гасыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Каеннар иртәрәк уяна . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Дөнья, ахры, шулай төзелгән . . . . . . . . . . . . 230
Могҗизалар арта . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Эшкә керәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Юл калмас иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Яшь килен төшәсе өй кебек . . . . . . . . . . . . . 234
Зур уңышлар яуладык . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Яңа таяк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Шәфәкъ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Җан тартышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Кышкы уйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
Таулар белән иңдәш булган кеше . . . . . . . . . 240
«Туган якны сайлап алып булмый...» . . . . . . . 241
Халыклар язмышы бар . . . . . . . . . . . . . . . 242
«Сөенәләрдер бакалар...» . . . . . . . . . . . . . 243
Газаплы яшәү бара . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
«Бу дөньяның хикмәтләрен... . . . . . . . . . . . 245
Кыйблаң кайда? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Фасил Әхмәткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
Бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Бишек җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
«Таралыр, диделәр...» . . . . . . . . . . . . . . . 250
Ай белән сөйләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
«Беткән инде туган якта...» . . . . . . . . . . . . 252
Туганнарга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Тик шуларда яшәү дәвамы . . . . . . . . . . . . . 254
«Шагыйрьлек тә пәйгамбәрлек кебек...» . . . . . . 254
Ике фикер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
«Дан яраткан кеше өчен...» . . . . . . . . . . . . . 255

Рәхәтләнеп коена дөнья . . . . . . . . . 256
Бәреп чыга бит ул йөзләргә . . . . . . . . 257
Бу дөньялар фани . . . . . . . . . . . . 258
Батырлар бер үлә . . . . . . . . . . . . 259
Нинди серләр ята? . . . . . . . . . . . . 260
Моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
Амнистия көткән тоткындай . . . . . . . 262
«Күкләр була җиде катлы...» . . . . . . . 264
«Күктә йолдызлар шундый күп...» . . . . 264
Калҗа һәм чыбык . . . . . . . . . . . . 265
Шуңа горурлар без . . . . . . . . . . . 266
Кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
Күкләр юлы кирәк кешегә . . . . . . . . 268
Эш көйләнде . . . . . . . . . . . . . . 270
Казаным . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Айлар якты . . . . . . . . . . . . . . . 272
Югала . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Этюд . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Каз өмәсе . . . . . . . . . . . . . . . 275
«Берәүләр үз кирәкләрен...» . . . . . . . 276
Гүзәл гамь . . . . . . . . . . . . . . . 277
Кыюлык . . . . . . . . . . . . . . . . 277
Сәвиягә . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Бар да бер кулланышлы . . . . . . . . . 279
«Җир — тәгәрмәч...» . . . . . . . . . . 280
Тора икән килешеп . . . . . . . . . . . 280
Аккош булып оча һавада . . . . . . . . 281
«Тал бөгелә, тал бөгелә...» . . . . . . . 282
Ләйлә һәм Мәҗнүн . . . . . . . . . . . 283
Нәрсә калыр? . . . . . . . . . . . . . 284
Исмә, җил . . . . . . . . . . . . . . . 285
Башка төшә каргышы . . . . . . . . . . 286
Кемнәр бирер кульяулык? . . . . . . . . 287
Игезәкләр . . . . . . . . . . . . . . . 287
«Һәрнәрсәнең чын сурәтен...» . . . . . . 288
Моңсу шигырь . . . . . . . . . . . . . 289
Йөрәк белән янәшә . . . . . . . . . . . 290
«Кошлар китә, кошлар кайта...» . . . . . 291
«Күзләр күзгә охшамаган...» . . . . . . . 292
«Кайный, ярсый, бәргәләнә...» . . . . . . 293

Дачада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Бер нәтиҗә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Аерма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Бетмәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Илдә әле ирләр бар . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
«Күккә ук атсаң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Сине җиңәр өчен мин бар җирдә . . . . . . . . . . 298
Эт гадәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Шундый без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Тәхет һәм бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 301
Калмагыз соңга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
Яңа елга иске теләк . . . . . . . . . . . . . . . . 303
«Бу дөньяның ние бар?..» . . . . . . . . . . . . . 304
Бары бер генә булса да . . . . . . . . . . . . . . 305
Өметсезлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 306
Иң матур кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 307
Озак-озак яначак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
«Бу дөньяның бик еш кына...» . . . . . . . . . . 309
Уйнаучылар һәм уйлаучылар . . . . . . . . . . . . 310
Ташлар авыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 310
Бер үк бишмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
Сандугач тыйнаклыгы . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Бай кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 312
Ызгышырга нигез юк . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Сузылган куллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Дөнья бик тә катлаулы . . . . . . . . . . . . . . . 315
«Кайларда йөртми кешене...» . . . . . . . . . . . 316
Агымсу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 317
Бөркет булмый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Яралы җанвар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
Безнең җаннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 320
Болай барса . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321
Ялганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
«Һәркем патша була алмый...» . . . . . . . . . . 323
«Дөнья — камыт...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
«Кычкырасы килә кайчак...» . . . . . . . . . . . 324
Мәңгегә ат бәйләүче юк . . . . . . . . . . . . . . 325
Дөнья бетәр иде күптәннән . . . . . . . . . . . . 326
Оялчан халык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
Парадокслар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328

Түбәтәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Ташлар һәм башлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Онытып куйсак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Өч нәрсә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
«Кешеләр бик вакланды, дип...» . . . . . . . . . . . 330
Чарасызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Көрәшчеләр булдык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332
Манаралар, айлы манаралар . . . . . . . . . . . . . . 333
Сабырлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Кабатлана һаман бер үк сүз . . . . . . . . . . . . . . 335
Мәңгелек тартыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 336
Карт-корылар болай моңая . . . . . . . . . . . . . . . 337
Йөрәккә эндәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 338
«Балачак хыялы — очар кош...» . . . . . . . . . . . 339
Юнәлеше үзгәрүчән җил . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
Әйтегез, әгәр белсәгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Ирек туа җирдә тукмалып . . . . . . . . . . . . . . . . 341
Татарстан байрагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Халыкка эндәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343
Каргалар күтәреп китәр . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Халык бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 345
«Тау ватты, тау кисте кеше...» . . . . . . . . . . . . 345
«Урман — колак, кыр — күз...» . . . . . . . . . . . . 346
Җир өстендә җиз кыңгырау . . . . . . . . . . . . . . . 347
Мәрхәмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
«Ай-яй, көннәр озын инде...» . . . . . . . . . . . . . 348
Алмагач һәм кабак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 349
Безне соң кем дәвалар? . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
Арифметиканың дүрт гамәле . . . . . . . . . . . . . . 351
Һәркемгә үз өлеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 352
Сорау һәм җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 353
Ипигә мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 354
Әнкәбезгә үз идек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 355
Туган ягы кирәк кешегә . . . . . . . . . . . . . . . . . 356
Урамда ыгы-зыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 357
Сиртмәле кое монологы . . . . . . . . . . . . . . . . . 358
Ак үлем *(поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 359

Литературно-художественное издание

*Фанис Яруллин*
*(Яруллин Фанис Гатауллович)*

СВЕТ ДУШИ

*Стихи, поэма*

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Х.К.Ибраһимов, И.Г.Ногманов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 0418 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 22.01.2003.
Форматы $70 \times 90^1/_{32}$. 65 гр. офсет кәгазе. «Т.Таймс» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 14,04+форз. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 14,48.
Нәшер-хисап табагы 12,08+форз.0,26.
Тиражы 2000. Заказ Б-738.

Татарстан китап нәшрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия дәүләт унитар
предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.